ӘЛФИЯ ЮСУПОВА

# ТАТАР ТЕЛЕ СҮЗЛЕКЛӘРДӘ

**ТАТАР ТЕЛЕ СҮЗЛЕКЛӘРДӘ**
**ӘЛФИЯ ЮСУПОВА**

*İmtiyaz Sahibi*
**Sadettin Bayrak**

*Yayın Koordinatörü*
**Rekin Ertem**

*Yayın Editörü*
**Ercan Alkaya**

*Kapak Tasarımı*
**Hüseyin Özkan**

*İç Tasarım*
**Özlem Özkan**

*Baskı ve Cilt*
**Çalış Ofset**
Davutpaşa Caddesi Yılanlı Ayazma Sokak
No : 8 Örme İşhanı Topkapı/İstanbul
Tel : 0212 493 11 06

*Birinci Baskı*
**Aralık 2020**

ISBN: 978-625-7698-01-6
T.C. Kültür Bakanlığı Yayıncılık Sertifika No: 11805

KESİT YAYINLARI
Ankara Caddesi No: 15 Konak Han Kat: 1
Hobyar Mahallesi Cağaloğlu/İstanbul
Tel : 0212 512 56 33 / 0212 511 68 28
Faks : 0212 512 56 63
web : www.kesityayinlari.com
e-mail : kesit@kesityayinlari.com
© KESİT YAYINLARI
Tüm Hakları Saklıdır. Yayınevinin izni olmadan kopyalanamaz ve çoğaltılamaz.
**KESİT YAYINLARI,** Karbey Yayıncılık Eğitim ve Dan. Hiz. San. Tic. Ltd. Şti. kuruluşudur.

**ӘЛФИЯ ЮСУПОВА**

# ТАТАР ТЕЛЕ  СҮЗЛЕКЛӘРДӘ

İstanbul, 2020

KESİT

**УДК 80 / 81**
**ББК 81.2 Тат.я.2**
**Ю**

КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Гыйльми советы карары белән басыла

Фәнни редактор – филология фәннәре докторы
профессор Р.Р.Җамалетдинов

Рецензентлар: фиология фәннәре докторы,
профессор Ф.Г.Хисамитдинова;
фиология фәннәре докторы,
профессор Г.Р.Галиуллина

Монография XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча и русча-татарча сүзлекләрдә теркәлгән лексик берәмлекләрне тикшерүгә багышлана. Сүзлекләргә кыскача тасвирлама анализ ясала. Сүзлекләрдә урын алган сүзләргә лингвистик аңлатмалар бирелә, диалекларда кулланылган берәмлекләр аерым алып тикшерелә. Синонимик рәтләргә берләшкән, сүзлекара синонимнар тәшкил иткән сүзләр карала.

Китап укытучылар, аспирантлар, студентлар һәм татар теле белән кызыксынучылар өчен кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

# ЭЧТӘЛЕК


КЕРЕШ ........................................................................................ 9

XIX гасырда татар халкының социаль-икътисади
һәм мәдәни-әдәби тормышы ........................................................ 11

XIX гасырда татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзелүнең алшартлары ................................................................................ 15

И.Гигановның татарча-русча сүзлеге ........................................ 20

И.Гигановның русча - татарча сүзлеге ...................................... 24

А. Троянский сүзлегенә тарихи-лингвистик анализ .................. 28

С.Кукляшевнең «Словарь к татарской хрестоматии» сүзлеге .................. 37

Н.Остроумов сүзлекләре ........................................................... 44

К. Насыйриның «Татарча-русча лөгать китабы» ........................ 51

К. Насыйриның «Русча-татарча» сүзлеге .................................... 54

Миссионерлар җәмгыяте сүзлекләре .......................................... 58

Шиһабетдин Габделгазиз сүзлеге .............................................. 64

А.Воскресенский сүзлеге ........................................................... 83

М.Юнысов сүзлеге ..................................................................... 86

Башка төрки телләргә караган ике телле сүзлекләр .................... 94

XIX гасыр татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрдә теркәлгән диалекталь сүзләр ................................................................... 100

XIX гасыр сүзлекләрендә сүзләрне тәрҗемә итү алымнары .................... 118

XIX гасыр сүзлекләрендә сүзләрне синонимнар кулланып тәрҗемә итү алымы ............................................................................... 124

XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрдә сүзләрнең үзара синонимлыгы ...................... 129
Сүзлекләрдә семантик юл белән ясалган синонимнар........................... 129
Синонимнарның фонетик юл белән ясалышы....................................... 140
Төрки сүзләр һәм гарәп – фарсы алынмалары синонимлыгы.............. 149
Гарәп – фарсы алынмалары һәм рус теленнән кергән сүзләр арасында синонимлык...................................................................................................... 157
Сүзлекләрдәге төрки сүзләр синонимиясе............................................... 160
Сүзлекләрдә объективлык һәм субъективлык ........................................... 164
Йомгак ............................................................................................................. 169
ӘДӘБИЯТ ЧЫГАНАКЛАР........................................................................ 175

# КЕРЕШ

Әдәби тел тарихында яңа баскыч булып милли әдәби тел формалашу чоры санала. Бу вакытта элеккеге традицияләргә, диалекталь үзенчәлекләргә нигезләнеп, төрле төбәкләрдә яшәүче татар халкы өчен уртак булган тел нормалары тагын да ныгый һәм халык тарафыннан актив үзләштерелә башлый. Әдәби тел тарихындагы һәр этап теге яки бу этник төркемнең иҗтимагый- тарихи үсеш процессындагы вакыйгалар белән тыгыз элемтәдә тора. Җәмгыятьтәге вакыйгалар телгә билгеле бер күләмдә йогынты ясауга карамастан, тел үзенең эчке кануннары нигезендә үсә. Халык сөйләме һәм язма тел кинәт кенә тумаган, гасырлар буе үсеп килгән. Аларга, формалашу өчен, төп җирлекнең күптән әзерләнгән һәм тарихи шартларның өлгергән булып җитүе мәҗбүри [Хаков, 2003:81]. Әлеге үсешне шул гасырның лексик составына карап та билгеләп була.

Бу монографиядә XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләргә тарихи-лингвистик анализ ясау максаты куела. Шулай ук авторлар турында мәгълүмат бирү, сүзлекләрнең төзелү тарихын күзәтү, аларда теркәлгән лексик байлыкны килеп чыгышы, кулланылыш сферасы ягыннан тикшерү хезмәтнең бурычы булып тора. XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрне тикшереп, татар лексикографиясендә басма сүзлекләр барлыка килүне, аларның үсүен һәм камилләшүен күрсәтү, татар тел белемендә әлегә кадәр монографик планда тикшерелмәгән икетелле сүзлекләрнең әһәмиятен билгеләү дә күздә тотыла.

Казан дәүләт университеты китапханәсендә, Татарстан Милли китапханәсендә, Мәскәүдәге Россия китапханәсе һәм Берлинның үзәк китапханәләре фондларында XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр барланды. Казан һәм Мәскәү китапханәләрендә

барлык сүзлекләр сакланса, Берлинның үзәк китапханәсендә Н.Остроумов һәм К.Насыйри сүзлекләре барлыгы ачыкланды.

Бу сүзлекләр, нигездә, русларга татар телен өйрәтү максатыннан чыгып төзелгән. Шуңа күрә аларның күләмнәре бик зур түгел: 75 биттән 140 биткә кадәр һәм анда якынча 900 - 4000 лексик берәмлек теркәлгән. Әмма XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр арасында И.Гиганов (11 меңнән артык), А. Троянский сүзлеге (10 меңнән артык сүз), К.Насыйри (1892) 18 меңнән артык, А.Воскресенский сүзлегендә 12 меңнән артык сүз урын алган. Бу сүзлекләр сүз байлыгының тулылыгы белән башка лексикографик хезмәтләрдән аерылып торалар.

XIX йөздә татар әдәби теленең сүзлек составында зур үзгәрешләр күзәтелә. Бу заман таләпләре, җанлы сөйләм теленең әдәби телгә үтеп керүе белән аңлатыла. Шул сәбәпле әдәби телнең лексик нормалары үсүенә җирлек ачыла. Мондый үзгәрешләр сүзлекләрдә дә үз урынын ала һәм андагы лексик берәмлекләрне өйрәнү телебезнең бер гасыр дәвамында үсеш-үзгәрешен күзәтергә ярдәм итә.

XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрнең структурасын, төзелеш принципларын өйрәнү хәзерге тел гыйлеме, лексикография фәне өчен дә кызыклы һәм кирәкле гамәл булып тора.

## XIX гасырда татар халкының социаль-икътисади һәм мәдәни-әдәби тормышы

XIX гасырда ил тормышында әһәмиятле вакыйгалар күп була. Шулардан иң мөһиме итеп феодаль-крепостной тәртипләрнең таркалуын, яңа капиталистик мөнәсәбәтләр формалаша башлауны күрсәтергә кирәк. Бу үзгәрешләр Казан губернасы тормышына да тәэсир итми калмый. Беренче чиратта, губернада халык саны үзгәрә: 1,8 мәртәбә артып, 1,5 миллионга җитә. Бигрәк тә авыл халкы – крестьяннар сан ягыннан күпчелекне тәшкил итәләр. Ә шәһәр халкы исә бик әкрен үсә. Гасыр башында шәһәрләрдә губерна халкының 4,5 % яшәсә, 50 нче еллар ахырында бу сан бик азга гына арта һәм 6,1 % ка җитә.

Казан губернасы күпмилләтле төбәк булып кала бирә. Биредә татарлар, руслар, чувашлар, марилар, мордвалар бергә яшиләр. Татарлар барлык халыкның 29,6 % тәшкил итәләр.

Халык арасында иң таралган диннәр булып ислам һәм православие диннәре санала. Татарлар, нигездә, ислам динен тота.

XIX гасырда Казан губернасында сәнәгать зур үзгәрешләр кичерә. Ул үзгәрешләр XIX гасырның беренче яртысында ил икътисадында яңа капиталистик мөнәсәбәтләр формалашуга бәйле була. Бу чорда яңа предприятиеләр төзелә, элекке эшләп килгәннәре эреләнә, беренче фабрика һәм заводлар эшли башлау мөһим нәтиҗәләр бирә. Казанның Татар бистәсендәге сәнәгать оешмалары 1800-1810 нчы елларда икътисад үсешенең иң югары үрендә булалар. Бу чорда салым салына торган капиталның күләме 910.526 сумга җитә. 50 нче еллар ахырына 263 предприятие чама белән 5 миллион сумлык продукция эшләп чыгара.

50 нче еллар ахырына төбәк сәнәгатенең 90%ка якыны татар эшмәкәрләре кулында була.

Сәнәгать, су, тимер юл транспорты үсеше сәүдә эшенең җанлануына китерә. XIX гасыр башыннан сәүдә әйләнеше ике мәртәбә арта һәм 1837 нче елга 25 миллион сум тәшкил итә.

XIX гасырда Урта Азия белән сәүдә элемтәләре урнаша. Татар сәүдәгәрләре монда да төп рольне уйныйлар. А.Дж.Рибер исәпләүләренә караганда, Идел буе-Урал төбәгендә мөселман сәүдәгәрләренең саны бик күпкә арта. Төбәкләр буенча караганда, саннар түбәндәгечә: Пенза губернасында 189 (11,6%), Самара губернасында 608 (12%), Вятка губернасында 123 (0,6%), Казан губернасында 762 (34%), Оренбург губернасында 1752 (57%), Тобольск губернасында 87 (9%). Күргәнебезчә, 50% артыгы Оренбург губернасына туры килә [Хабутдинов, 2001: 50].

XIX гасырның беренче яртысында мәдәният үсеше сизелерлек алга китә. 1804нче елда Идел буенда беренче һәм Россиядә икенче булган Казан университеты ачыла. Иделдән алып Ерак Көнчыгышка кадәр сузылган уку-укыту округына җитәкчелек итү яшь университетка йөкләнә. Университет Казан губернасы һәм, гомумән, Казан уку-укыту округында училищелар, гимназияләр ачуга, мәктәпләр төзетүгә, аларның матди базасын ныгытуга, методик әдәбият булдыруга, укытучылар әзерләүгә зур көч куя.

Казан университетының рус булмаган халыкларны белемгә тартырга омтылышы аеруча игътибарга лаек. 1818 нче елда университет профессоры П.С.Кондыров һәм көнчыгыш телләр бүлеге адъюнкты И.И.Хәлфин "фәкать салым түләргә тиешле сословие" балалары өчен Казанда Үзәк татар училищесы оештырырга тәкъдим итәләр. Университет профессорлары Ф.Эрдман, К.Фойгт Көнчыгыш институтын ачу идеясен күтәреп чыгалар.

С.М.Михайлова билгеләп үткәнчә, Казан университетында 1840-1860 нчы елларда барлыгы 36 мөселман белем алган. Алар барысы да медицина факультетында укыганнар һәм университетны тәмамлаганнан соң, хәрби гаскәрләрдә табиб булып хезмәт иткәннәр [Михайлова, 1991:336-337 ].

Татар мәгърифәтчелегенең, алдынгы иҗтимагый фикернең формалашуы, үсеше Казан университеты эшчәнлеге белән тыгыз

бәйләнгән була. Татар мәктәпләренең саны арта. XIX гасырның беренче яртысында төбәктә якынча 500 авыл мәктәбе һәм мәдрәсә эшли.

Төбәк мәдәнияте үсешендә нәшерлек эше һәм вакытлы матбугат зур роль уйный. 1801нче елда Азия типографиясе ачыла һәм бу типографиядә гарәп шрифты белән басылган беренче китаплар дөнья күрә.

1802 нче елдан Казанда мөселман әдәбияты даими рәвештә басыла башлый. 1801-1829 нчы еллар аралыгында 93 китап дөнья күрә. Бу китаплар арасында мәдрәсә дәреслекләре, төрки әдәбиятның классик үрнәкләре Кол Галиның “Кыйссаи Йосыф”, Таҗетдин Ялчыголның “Рисаләи-Газизә”, “Бәдәвам китабы” һ.б. була. XIX гасырның беренче яртысында җәмгысе 401 китап нәшер ителә. Беренче китаплар дини, дини-дидактик һәм башлангыч мәктәп дәреслекләре булса, соңрак хокук, фәлсәфә, иҗат эшенә багышланган фәнни хезмәтләр басылып чыга.

1829 нчы елга кадәр Азия типографиясе дә татар китаплары бастыруны дәвам итә. Монда нәшер ителгән китаплар татар халкы арасында мәдәният һәм дөньяви мәгариф эшен киңәйтүгә катнашалар. Биредә 150 басма сүзлек, әлифбалар, татар халкы тарихы, лингвистик хезмәтләр, әдәби әсәрләр чыга. XIX гасырның икенче яртысында 1415 данә татарча китап басыла һәм бер китапның уртача тиражы 8000 нөсхәгә җитә.

Казан университеты типографиясе ачылгач, 1829 елдан Азия типографиясе аның составына керә. Бу чорда нәшер ителгән китапларның гомуми саны буенча Казан Россиядә өченче урында тора. Басма китаплар арасында русларга татар телен һәм татарларга рус телен өйрәтүне күздә тотып төзелгән татарча-русча сүзлекләр дә шактый күп була.

Татар әдәбияты да үсеш ала. XIX гасырда татар язучылары һәм шагыйрьләре киң халык массаларына аңлаешлы телдә яңа әсәрләр язалар. Татар милли әдәби теленең беренче үрнәкләре Г.Кандалый, К.Насыйри, Я.Емельянов, Г.Ильяси, Ф.Халиди иҗатында күренә.

XIX гасырның икенче яртысында Россия тарихында яңа чор башлана. 60-70 елларда илдә тирәнлеге, масштаблыгы, нәтиҗәләре буенча Россия тарихында моңа кадәр булмаган реформалар ясала. Реформалар чоры

тарихта шәһәрләр һәм сәүдә үсеше белән характерлы. Бу чорда шәһәр халкы бик тиз арта. 1897 нче елда шәһәрдә 184 мең кеше яши һәм бу төбәктә яшәгән халыкның

8,5 % тәшкил итә.

Сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүнең үсүе, шәһәр халкы саны артуга бәйле рәвештә сәүдә дә алга китә. Реформа елларында сәүдә әйләнеше ике мәртәбә арта.

Татар пролетариаты әһәмиятле социаль төркем булып формалаша. Татар эшчеләре вак предприятиеләрдә генә түгел, эре, техник яктан яхшы җиһазланган завод-фабрикаларда эшли.

XIX гасырның икенче яртысында татар милли хәрәкәте формалаша һәм үсеш ала. Гасыр ахырында Казан губернасында 675,4 татар, шуларның 35 меңнән артыгы шәһәрдә, 640 мең кеше өязләрдә яши. Россия империясендә татарларның саны 2,6 миллионга җитә.

Татарлар иң күп тупланып яшәгән төбәк Казан губернасы була. Татар милләте формалашуда Казан губернасының хәлиткеч роле шуның белән аңлатыла.

XIX гасыр уртасында эш бүленешенең үсүе эшләп чыгарган әйберләрнең тизрәк алмашуына китерә, эчке базар барлыкка килә, халык үзара нык аралаша башлый, үзен башкалардан аерылып торган аерым милләт кебек хис итә.

Үзара тыгыз аралашуны иске татар әдәби теле тулысынча тәэмин итеп җиткерә алмый, чөнки махсус өйрәнмәгән кешеләргә ул аңлашылып бетми. Тыгыз аралашу иске татар әдәби телен гомумхалык сөйләмә теленә теленә якынайтуны, ягъни татар милләтенең һәммәсенә аңлашылырлык әдәби тел төзүне таләп итә. Иске татар әдәби телен гомумхалык сөйләмә теленә якынайтып кулланырга туры килә, һәм шул процесста татар милли әдәби теле формалаша [Зәкиев,1998: 552-553].

XIX гасырның икенче яртысында хөкүмәт милләтләрне руслаштыруга юнәлеш тота. 1842 нче елда ачылган Казан рухани академиясендә махсус миссионерлар бүлеге булдырыла. Бу бүлектә

мөселманнарга каршы бүлекчә дә төзелә һәм монда студентларны рус булмаган халыклар теленә, шул исәптән татар теленә дә бик яхшылап өйрәтәләр, күпләп православие әдәбияты, дин белеме китаплары укытыла.

Бу сәясәт нигезендә Н.Ильминский системасы ята. Н.Ильминский Казанда рус булмаган халыклар өчен укытучылар семинариясе оештыра. Семинария татар, мордва, мари, чуваш һәм удмурт мәктәпләре өчен укытучы-миссионерлар әзерли. Моннан кала, изге Гурий җәмгыяте катнашы белән күп санлы миссионер мәктәпләре дә ачыла.

XIX гасырның икенче яртысында татар мәгърифәтчелеге тагын да үсә төшә. Мәгърифәтчеләр татарлар арасында мәгариф, фәнни һәм техник белемнәр тарату эшен ныклап җайга салырга, халыкны рус һәм Европа мәдәниятенә тартырга, тормышны Европадагы кебек корырга, искергән традицияләрдән арындырырга омтылалар.

80 нче еллардан башлап иске мәктәпләргә яңа ысул белән эшләүче мәктәпләр алмашка килә. XIX гасыр ахырында аларның саны берничә дистәгә җитә.

Татар яшьләренә башлангыч һәм урта белем бирү, нигездә, мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә алып барыла. XIX – XX гасыр чигендә Казан губернасында яшәүчеләрнең 80% ана телендә укый-яза белә.

Реформа елларында Казан университетында укучы студентлар арасында татарлар саны арта. Татарлар Петербург, Томск, Мәскәү университетларында белем алалар башлыйлар.

## XIX гасырда татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзелүнең алшартлары

Татар халкының рус халкы белән күптәнге иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни, сәүдә, көнкүреш бәйләнешләре, халкыбызның Европа һәм Азия чигендә урнашуы, рус дәүләтендә татар теленең башка төрки

халыклар белән бәйләнештә арадашчы булуы татар лексикографиясенең шактый иртә барлыкка килүенең сәбәпләрен аңлата.

Казан ханлыгы рус дәүләтенә кушылганнан соң, бу мөнәсәбәтләр тагын да киңрәк җәелә. Шуның нәтиҗәсендә руслар арасында татар теле белән кызыксыну арта. Аерым һәвәскәрләр өчен практик кулланмалар, сөйләүлекләр, сүзлекләр төзиләр.

XV – XVII гасырларга караган тел материаллары рус галиме «Памятники старинной русской лексикографии по рукописям XV – XVII веков» (1908) хезмәтендә урын ала. Монда славян хәрефләре белән язылган 40 ка якын татар сүзе алфавит тәртибендә урнаштырылып, русча аңлатма бирелгән.

«Сборник рукописей конца XVII и начала XVIII века» исемле икенче кульязма җыентык эчендә тагын бер глоссарий бар. Ул «Наука языку туркскому» дип атала һәм 15 битлек кульязмадан тора. Практик максатны күздә тотып эшләнгән бу сүзлек сәүдә һәм көнкүрешкә караган 300 гә якын иң кирәкле рус сүзен үз эченә ала, аларга татарча аңлатма бирелә [Ногман, 1969:26-27].

XVII – XVIII гасырларда дәүләтара мөнәсәбәтләрдә дә татар теле кулланыла. Рус дәүләте мәнфәгатьләрен яклау өчен дә, татарча белә торган чиновниклар, хәрби кадрлар әзерләү кирәк була. Инде бу чорда ук җирле телләрне өйрәнә торган мәктәпләр ачыла [Ногман, 1969:15].

Екатерина II татар телен яхшы белгән чиновниклар хәзерләү теләге белән 1769 нчы елда Казан губернаторына, татар теле укыту өчен, гимназия каршында махсус класс оештыру турында боерык бирә.

Татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ яңадан-яңа сүзлекчәләр, кулланма материаллар таләп итә. С.Хәлфин 1778 нче елда «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов» исемле кулланма яза һәм ул татар телен укыту буенча төзелгән беренче басма дәреслек була.

1785 нче елда С.Хәлфин 2 томлык русча-татарча сүзлек төзи. Хезмәтнең титул битендә «Татарский словарь и краткая татарская грамматика в пользу обучающегося при Казанских гимназиях юношества татарскому языку, сочиненный при оных же гимназиях. 1 часть, Казани

1785 года» дип язылган. Сүзлектә башта рус сүзләре, аннары рус хәрефләре белән язылган татарча сүзләр бирелә. Шул ук сүзләрнең гарәп хәрефләре белән язылышы да күрсәтелә. Беренче том 653, икенче том 874 биттән гыйбарәт. Сүзлеккә якынса 25 мең сүз кергән. Сүзлек үзенең системалы булуы, рус сүзләренең мәгънәләрен тулырак, төгәлрәк күрсәтүе белән аерылып тора.

С.Хәлфин сүзлеге татар лексикографиясенең иң күренекле казанышларыннан берсе булып санала [Сафиуллина,1999:190-191].

Русча-татарча сүзлекләрнең иң беренче төркеме В.Н.Татищев җитәкчелегендә туплана. Сенатка язган докладларының берсендә ул Россиядә яшәүче халыкларның телләре буенча чагыштырма «Лексикон» төзергә тәкъдим итә. Төрле өлкәләрдән, төрле күләмдәге русча-татарча сүзлекчәләр рәвешендә җаваплар алына. Шулар арасында Себер, Казан, Тобол татарларының да сүзлекчәләре бар.

1733 нче елда Россия Фәннәр Академиясе, җирле халыкларны өйрәнү өчен, махсус экспедицияләр оештыра. Шулардан Г.Ф.Миллер җитәкчелегендәгесе Казан губернасында, Урал, Себер якларында була. Ул үзе белән әзер лөгатьлек алып барып, җирле телләрнең кыскача глоссарийларын төзи.1733 нче елда төзелгән бер сүзлекне Сенатка җибәрә. Сүзлек рус теленнән башка 7 тел сүзләрен үз эченә ала: анда татар, чирмеш, чуваш, удмурт, мордва, пермяк һәм зырян телләрендәге билгеле бер сүзләр теркәлгән. Бу сүзлек 1758-1759 нчы елларда немец телендә басылып чыга һәм ул «Россия тарихын өйрәнү өчен татар телен дә белү кирәк» дигән гыйльми максат белән төзелгән сүзлекләрнең башлангычы була [Ногман, 1969:19].

Татар халкы тарихында XIX гасыр фәнни идеяләрнең үсүе, мәктәпләрдә белем бирү киңәю, телдә, әдәбиятта яңарыш билгеләренең арта баруы белән билгеле. Бу бөтен Россия масштабындагы социаль-икътисади, сәяси сәбәпләргә барып тоташа.

XIX гасырда татар әдәби теле тарихында гаять күп яңарыш һәм үзгәрешләр барлыкка килә. Бу – телебез үсешендә бик бай, гаять үзенчәлекле, катлаулы чор. Телдәге үзгәрешләргә иҗтимагый

мөнәсәбәтләр, милли күтәрелеш, җәмгыятьтәге тарихи вакыйгалар тәэсир итә. Әдәби телне халыкның җанлы сөйләм теленә якынайту һәм шул нигездә нормалаштыру мәсьәләсе куела. Яңа чор әдәби телнең эшкәртелүен, норматив грамматикаларның төзелүен, сүзлек хәзинәсен һәм тел байлыгын барлауны таләп итә.

XIX гасыр татар әдәби теленең иҗтимагый функцияләре киңәя, җанлы сөйләмгә нигезләнгән хәлдә, ул бөтенләй яңа юнәлештә үсә башлый. Гасырлар буе килгән традицион язма тел сөйләм теле үзенчәлекләре белән тыгыз рәвештә кушыла бара [Хаков, 1993:209-210].

Россиядә татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ артканнан арта бара. 1803 нче елда Россия Фәннәр академиясендә гуманитар бүлек яңадан торгызыла. Мәскәү, Казан, Харьков университетларында көнчыгыш телләре кафедралары ачыла. 1812 нче елдан татар теле Казан университетының уку программасына кертелә һәм укытучы итеп Ибраһим Хәлфин билгеләнә. Шулай ук университетның татар-төрек телләре кафедрасында А.Казем-Бек, И.Н.Березин, М.Мәхмүтов кебек күренекле галимнәр эшли.

XIX гасырда төрле типтагы уку йортларында татар теле фән буларак укытыла башлый. Тобол, Томск, Оренбург, Саратов, Әстерхан, Ставрополь, Симферополь гимназияләрендә татар теле барлык милләт вәкилләренә дә өйрәтелә.

Патша Россиясенең көнчыгыш сәясәте татар телен белгән тәрҗемәчеләр, канцелярия хезмәткәрләре булуны таләп итә. Якын Көнчыгыш илләреннән килгән делегацияләрне Россия буйлап татарча белгән тәрҗемәчеләр озатып йөри. Оренбургтагы Неплюев кадет корпусы укытучысы М.Бекчурин, мәсәлән, шушы өлкәдәге тырыш хезмәте өчен патша Россиясенең югары бүләкләренә, орден-медальләргә лаек була.

XIX гасырда Россия территориясендә киң җәелгән миссионерлык хәрәкәте дә татар телен белүне сорый. Казан рухани академиясендә һәм семинариядә А.Троянский, Н.Ильминский, Е.Малов татар теленнән дәрес бирәләр, укыту тәҗрибәсенә таянып дәреслекләр, грамматикалар, сүзлекләр төзиләр.

Рус һәм татар халкы арасында үзара сәүдә-икътисади, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни бәйләнешләрнең яшәп килүе дә һәр ике телгә ихтыяҗ тудыра. Шул сәбәпле ике тел байлыгын туплаган сүзлекләр дөнья күрә башлый.

Иң күп таралган сүзлекләрдән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрне күрсәтергә кирәк. Мондый сүзлекләрнең күпләп чыгуы XVI гасырда рус дәүләте составына керү, рус әдәбияты һәм мәдәнияте белән якыннан танышу, руслар белән аралашу өчен, уртак тел зарурлыгы, татар телен өйрәнеп, рус һәм татар халкы арасында сәүдә-икътисади бәйләнешләрне ныгыту, рус дәүләтенең җирле идарәләрендә эшләргә татарча белгән чиновниклар әзерләү, Россия тарихын өйрәнгәндә, татар телендә язылган тарихи чыганаклардан файдалана алу, самодержавиенең христианлаштыру сәясәтен уздырганда, татар телен белгән миссионерлар әзерләү һ.б. белән бәйле була. Бу сәбәпләр XIX гасырда ике телле сүзлекләрнең барлыкка килүенә җирлек булып торалар.

Татар тел белемендә лексикография мәсьәләләренә багышланган өч монографик хезмәтне атап үтәргә кирәк. Беренче хезмәт - М.Ногманның «XVII-XVIII йөзләрдәге русча-татарча кульязма сүзлекләр» (Казан,1969) китабы. Монда автор төп игътибарны русча-татарча кульязма сүзлекләрнең төзелү тарихларына, барлыкка килү сәбәпләренә, структурасына, лексик составына юнәлтә.

Р.Нурмөхәммәтовның »дигән кандидатлык диссертациясендә (Казан, 2005) XX гасырның беренче яртысында дөнья күргән татарча-русча сүзлекләр тикшерелә. Сүзлекләргә тасвирлама характеристика бирелә, сүзлек составына җентекле анализ ясала.

Ә. Юсупованың «Двуязычная лексикография татарского языка XIX века» монографиясендә XIX гасырда чыккан ике телле сүзлеклә анализлана, аларны барлыкка китергән алшартлар, чыганаклар, традицилләр ачыклана, сүзлек корпусы анализлана.

XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр бүгенге көнгә кадәр монографик өйрәнү объекты булмады. В.Хангилдин, Ф.С.Сафиуллина, Ф.Ә.Ганиев, Ш.Ханбикова, Г.Якупова хезмәтләрендә бу сүзлекләр турында таныштыру рәвешендә мәгълүмат бирелә.

Без бу хезмәттә XIX гасырда дөнья күргән татарча – русча һәм русча-татарча сүзлекләргә киңрәк тукталырга, аларда теркәлгән лексик берәмлекләрне төрле яклап анализларга, сүзләрнең активлыгына, кулланылыш даирәсенә, килеп чыгышына игътибар итәргә тырышырбыз.

## И.Гигановның татарча-русча сүзлеге



Иосиф Иванович Гиганов [? – 7.IX.1800] – беренче рус тюркологы. Ул диндар гаиләдә туа. XVIII гасыр ахырында Тобольскидагы София соборында рухани булып эшли һәм шул ук вакытта Тобольскиның халык училищесында татар теле укыта. И.Гиганов үз заманында татар телен иң яхшы белгән шәхесләрнең берсе булып санала, һәм аның укыту эшенә тартылуын да шуның белән бәйләп аңлатырга мөмкин.

И.Гиганов Европа тюркологлары арасында иң беренче татар теле грамматикасын төзи. Хезмәт 1798 нче елда язылып бетә, ләкин 1801нче елда гына, автор үлгәннән соң басылып чыга. М.Казем-Бек грамматикасына язылган рецензиясендә В.В.Григорьев әлеге хезмәтне искә ала һәм аны югары бәяли.

Грамматикадан тыш, И.Гигановның тагын ике лексикографик хезмәте билгеле. Болар «Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарского языка И.Гигановым и Юртовскими муллами свидетельствованные» (СПб, 1801) һәм «Словарь российско-татарский» (СПб, 1804) дигән сүзлекләр. Шушы хезмәтләр Тубыл төбәгендә яшәгән татарларның телен өйрәнүгә нигез салганнар һәм тюркологлар өчен зур файда китерә алганнар.

С.М.Михайлова, гипотеза рәвешендә, И.Гиганов сүзлегенең зур өлеше оригинал түгел, аның нигезендә Сәгыйт Хәлфиннең сүзлеге ята [Михайлова, 1972:100] дигән фикер әйтә. Ләкин бу карашны А.Кононов кире кага һәм, үз фикерен дәлилләп, И.Гигановның татар телен бик яхшы белүен һәм, шуңа өстәп, Сәгыйт Хәлфин сүзлегенең бары тик 3 нөсхәсе генә билгеле булуын искәртә [Кононов, 1982. б.260], ягъни И.Гигановның С.Хәлфин сүзлегеннән файдалануы зур шик астында кала.

Шуны да әйтергә кирәк, В.С.Сопиков «Опыт российской библиографии» хезмәтендә И.Гигановның «Грамматика турецкого и арабского языка, со словарем, сочиненная Тобольской главной школой учителем, священником Иосифом Гигановым, СПб, 1801» [Сопиков, 1904. б.266] дигән кулланмасын күрсәтә. Ләкин билгеле булган китапханәләрнең берсендә дә мондый китап сакланмаган.


СЛОВА НУЖНѢЙШІЯ
КЪ СВѢДЕНІЮ ЯЗЫКА,
КОРЕННЫЯ.

ЧАСТЬ ПЕРВАЯ.

I.

Область и его части съ принадлежностями.

| | | |
|---|---|---|
| ولايت | вилятъ | страна. |
| يورت | юртъ | владѣніе. |
| شهر | шагаръ, тура | городъ. |
| قلعه | кала | крѣпость, замокъ. |
| آول | аулъ | деревня. |
| ايل | иль | селеніе. |
| مناره | монара | башня. |
| ديواره | дивара, кала | стѣна. |
| دروازه | дарваза | городскія ворота. |
| كوبور | кюбюрь | мостъ. |
| اورام | урамъ | улица. |
| مسجد | масцидъ | храмъ. |
| مناصر كليسه | монасиръ, калися | церковь. |

I

چارشو

И. Гигановның «Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе учителем татарского языка И.Гигановым и Юртовскими муллами свидетельствованные» (СПб, 1801, 75 с.) сүзлеге авторның татар грамматикасына кушымта рәвешендә тәкъдим ителә. Сүзлектә урын алган 1800 лексик берәмлек төрле тематик төркемнәргә бүленеп бирелгән. Төркемнәрнең исемнәре рус телендә генә тәкъдим ителгән: «Область и его части с принадлежностями», «Дом и его части», «Разные вещи», «Конский прибор», «Вещи, принадлежащие к одеянию», «Школа со школьными пособиями», «О стихиях и других естественных вещах», «О человеке, его возрастах и его частях», «О родстве», «О различных состояниях людей», «Месяцы с зодиакальными созвездиями», «О промыслах», «О животных», «О рыбах», «О деревьях и плодах», « О птицах», «О насекомых», «Об огородных растениях», «О луговой зелени» «О камнях и металлах», «Об именах, встречающихся в других книгах», «О времени», «О добродетелях и пророках», «Имена, означающие качества».

Сүзлектә сүзләрнең бирелеше бик гади. Башта гарәп графикасында татар сүзе, икенче баганада шул чорда кабул ителгән орфографик нормаларга буйсындырылып, сүзнең кирилл хәрефләре белән язылышы һәм өченче баганада – рус сүзе. Мәсәлән,

| | | |
|---|---|---|
| دروازه | дарваза городскія | ворота [б.1] |
| اوچ | уцъ | конецъ [б.2] |

Сүзлектә теркәлгән лексик берәмлекләрнең бер өлешен Себер татарлары, ягъни көнчыгыш диалект вәкилләре теленә генә хас булган сүзләр тәшкил итә. Теркәлгән сүзләрнең күбесе телебездә хәзер дә актив кулланыла, ләкин алар көнчыгыш диалектларга хас булган фонетик закончалыкларга буйсынган рәвештә бирелгәннәр. Алар арасында ашамлык атамаларын, тормыш-көнкүреш предметларын, табигать күренешләрен белдерә торган сүзләр бар. Мәсәлән, ياصدوغاج я**стугачъ** [б.7] колак мендәре, кечкенә мендәр дигәнне белдерә [Тумашева, 1992: 72], سرة **сәртә** [14] кыздырып, аш өстенә салынган май [Тумашева, 1992: 168] мәгънәсендә кулланыла, ә **شيشبر** **шешбәрә** [б.15] сүзенең тәрҗемәсе итеп автор “пилмән” сүзен бирә. Әлеге сүзнең төрле фонетик вариантлары бар (чүчпәрә, сүсбәрә, дюшбере, чүпчара) һәм алар татар теленең төрле сөйләшләрендә, һәм кайбер төрки телләрдә кулланылалар.

Табигать күренешләрен белдергән сүзләрдән شعله **шааля** [б.22], **يلدرم** **илдрумъ** [б.22] кебек берәмлекләрне күрсәтеп була. **Шөглә** – гарәп алынмасы [ГТРАС,1965:71]. Ул «ялкын» дигән мәгънә белдерә. Ләкин И.Гиганов сүзлегендә аның мәгънәсе тарайган һәм **луч** дип тәрҗемә ителгән. **Йылдырым** себер татарлары сөйләшләрендә күк күкрәү дигән мәгънәне белдерә [Тумашева,1992: 103]. Татар теленең урта диалект сөйләшләрендә йылдырым сүзе яшен мәгънәсендә дә кулланыла.

Сүзлекнең безнең өчен тагын бер кызыклы ягы – анда теркәлгән тарихи сүзләр. دوان **диванъ** – сенат [б.33], يو **яу** – война [б.33], بى **би** – князь [б.33], يوچي **явцъ** – воин [б.34], لهشكه ر **ләшкәр** ,چهريك **чәрик** – войска [б.34], باذاركاب **базаргян** – купец [б.34] , اسلامچي **асламцы** – ростовщик [б.33], يومش **юмушъ** – служба [б.34] һ.с. دوان **диван** сүзе «сенат» мәгънәседә теркәлгән. Хәзерге татар телендә ул «йомшак урындык» булса, Казан ханлыгында дәүләт киңәше –**диван**, спикер – **диван башы** дип аталган. М.Әхмәтьянов фикеренчә, бу сүз татар теленә фарсы теленнән кергән, ә тамырлары белән **дәүүана** [язу] сүзенә барып тоташа [Әхмәтьянов, 2001: 84]. چهريك **чәрик** – чирү сүзенең иң борынгы формасы. Соңга таба бу сүз фонетик үзгәрешләр кичереп, чирүгә әйләнгән. Чирү сүзе XVIII йөздә бик актив кулланыла, ә XIX йөздә кулланылыштан төшеп кала һәм аның урынына гаскәр сүзе керә [Ногман,1069: 103]. بي **би** сүзенең этимологиясенә килгәндә исә, бу сүз һуннар заманыннан ук билгеле була. Ул төрки телләрдән күп кенә башка телләргә, шул исәптән, гарәп теленә дә үтеп кергән [Әхмәтьянов, 2001: 99] дип аңлатыла.

И.Гигановның 75 биттән торган сүзлеге – XIX гасыр башында дөнья күргән беренче ике телле сүзлек. Төзелеше ягыннан ул XVIII гасыр кулъязма сүзлекләренә һәм сөйләүлекләренә бик якын. Моңа төп дәлил итеп сүзлекнең тематик принципта төзелүен һәм хезмәттә телдә иң актив кулланылышта булган берәмлекләрнең генә теркәлүен күрсәтергә була.

Гомумән алганда, И. Гигановның тел белеме өлкәсендәге хезмәтләре, үз вакытында татар телен өйрәнү өчен, гаять файдалы кулланмалар булып саналган. Алар төрки телләрне өйрәнүдә мөһим урын билиләр. Хәзерге вакытта исә, әлеге хезмәтләр шул чор теленең лексик составын өйрәнү, бигрәк тә көнчыгыш диалектларны тикшерү өчен, бай чыганак булып торалар.

## И.Гигановның русча - татарча сүзлеге


СЛОВАРЬ
РОССІЙСКО-ТАТАРСКІЙ,
собранный
Въ Тобольскомъ главномъ народномъ училищѣ,
Учителемъ Татарскаго языка
Священникомъ Іосифомъ Гигановымъ
и
Муллами Юртовскими Свидѣтельствованный.

Печатано по ВЫСОЧАЙШЕМУ повелѣнію.

ВЪ САНКТПЕТЕРБУРГѢ,
при Императорской Академіи Наукъ
1804 года.

И.Гигановның икенче сүзлеге «Словарь российско-татарский, собранный Тобольском главном народном училище учителем татарского языка И.Гигановым и муллами Юртовскими» дип атала. Ул 1804 нче елда Санкт-Петербургта басылган. Сүзлек 672 биттән гыйбарәт. Рус сүзләренә сүзгә-сүз җыйнак һәм аңлаешлы тәрҗемә бирелгән. Сүзлекнең төзелеше безнең заманда камилләшкән сүзлек төзү принципларына якын тора. Сүзләр, рус алфавиты тәртибендә урнаштырылып, күп очракта бу тәртип сүзнең беренче хәрефенә генә түгел, аннан соң килгәннәренә дә карый. Сүзлекнең һәр битендә сүзләр өч графага бүленгәннәр. Беренчесендә алфавит тәртибен саклап, рус сүзе бирелә; икенчесендә, әйтелеш дөреслеген сакларга тырышып, рус хәрефләре белән сүзнең татарча укылышы языла; өченче графада гарәп графикасында татар сүзе бирелә:

Аллебарда *айбалта* ائبالطا
Алтынъ *учъ теиньликъ* اوچ تینلک
Аптека *дару ханясъ* داروخاناسی



Ныклы алфавит тәртибе  авторның сүзлек төзү принциплары белән якыннан таныш булуы турында сөйли. Ул сүзлек белән кулланучылар өчен дә билгеле бер уңайлылык бирә. Кайбер очракта бирелгән сүздән соң бер тамырдан ясалган, яисә мәгънәдәш сүзләр күрсәтелә. Бу вакытта алфавит тәртибе бозыла. Мондый алым сүзлек белән эшләүне җиңеләйтә һәм татар теле лексикасын тиз истә калдыруда зур роль уйный.

Әйтергә кирәк, сүзлек синонимнарга бай. Автор сүзләрнең мөмкин булган барлык синонимнарын  бирергә тырышкан, хәтта рус телендәге бер фигыльне берничә грамматик формаларда тәрҗемә итеп күрсәткән.

Сөйләм телендә кулланыла торган ымлыклар һәм модаль сүзләр, аерым сүзтезмәләр, гыйбарәләр, хәтта җөмләләр дә автор игътибарыннан читтә калмаган.           Ул укучыларның татар теле лексикасын үзләштереп калуны гына түгел, ә җиңел аралашырга һәм аңлашырга өйрәтүне төп максат итеп куйган.

Сүзлектә шактый күп урын алган сүз төркеме – фигыль. Фигыльнең -мын, -мен формасы, ягъни хәзерге заман хикәя фигыль, I зат, берлек сан төп форма итеп алынган. Кайбер фигыльләр хәзерге заман хикәя фигыль III зат берлек сан формасында теркәлгәннәр. Бу очракта -ай, - әй яисә -а, -ә кушымчалары саклана һәм аларга -ды, -де кушымчалары өстәлә: بورله نه دي **бүрләнәде** [бөреләнә], سوعاتي **сугате** [суга], قيجقرادي **кычкырады** [кычкыра], اللاناتي **алланаты** [аллана].

Автор һәр фигыльнең диярлек гади һәм кушма формаларын теркәп барган. Аналитик форма *ала* я *бара* ярдәмче фигыльләре белән ясалган. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| اعارامن агарамын | اعاروب بارامن агарып барамын |
| سوعامن сугамын | سوعب الامن сугып аламын |

Сүзлектә киләчәк заман мәгънәсе зат кушымчалары алган - ыр, - ер, -р формалы фигыль ярдәмендә бирелә. Хикәя фигыльнең I зат берлек санын кыскартылган формада куллану очраклары бар, ул - ыр, - ер, - р формалы сыйфат фигыльгә -ым, -ем кушымчалары ялганып ясала:يته رم йетәрем [җитәчәкмен]; киләчәк заман хикәя фигыльнең III зат берлек саны сүз нигезенә -ыр, -ер, [-ур, -үр] кушымчалары ялганып ясала:بولور булур [булачак],كيلور килүр [киләчәк].

Сүзлектәге исемнәрнең ясалышында, аларның килеш һәм тартым белән төрләнешендә татар әдәби теленнән нык аерылып торган үзенчәлекләр күп түгел. Үзенчәлек итеп түбәндәгеләрне күрсәтеп була: -***цак, -цәк*** иркәләү кушымчасы Себер татарлары диалектларында актив кулланыла. Бу кушымча кеше исемнәре һәм туганлык терминнарына гына түгел, йорт хайваннары, җансыз һәм абстракт предметларны белдергән исемнәргә дә ялгана. Бу очракта предмет мәгънәсенең кечерәйтелүе күзәтелә, эмоциональ-экспрессив төсмер бирелә: اولجعاج аулцыгац [кечкенә авыл],ايعورجق айгурцак [яшь айгыр], قولونعاج колынгац [бер яшьле колын], قويتنجعاجкоянцыгац [куян баласы],طامجعاج тамцыгац [тамчы сүзенә кечерәйтү, иркәләү төсмерен өсти.

Кулланылышта шулай ук актив булган -гына, -генә кушымчалары да нәкъ шундый ук мәгънә белдерәләр:اويكنه өйгенә [кече өй], كونكنه көнгенә [көнгә кечерәйтү төсмерен бирү].

Алмашлыкларга килгәндә, әдәби телдәге вариантлардан алар әллә ни аерылмыйлар. Тик мин, син, ул зат алмашлыклары урын-вакыт килешендә сирәк кенә مينكده минендә سينيكده синендә, انيكدا анында формасында әйтеләләр. Мондый форманың уйгур теле белән уртаклыгы бар. Мәсәлән, уйгур телендә зат алмашлыкларын чыгыш, урын-вакыт килешләрендә иялек килешенә нигезләнеп төрләндерү үзенчәлекле: мен + иң + дин; сен + иң + дин; у + ның + дин; мен + иң + дә; ан + иң + да; у + ның + да [Юсупов, 1979:120].

Күрсәтү алмашлыкларыннан **бу** алмашлыгы үзенең борынгы формасы وشبو **ошбу** белән янәшә күрсәтелгән.

И.Гиганов сүзлекләрендә урын алган гарәп-фарсы алынмаларының күбесе татар теленә бик нык үтеп кереп, телнең үз сүзләре кебек үк актив кулланылышта йөриләр. Алар һәркемгә аңлашыла, хәтта аларның алынма икәнлеген белгечләр генә белә.

«Словарь Российско-татарский» хезмәтендәге лексик байлыкның төп өлешен шул чор татар халык сөйләм һәм язма теленә хас булган, шулай ук Себер татарлары сөйләмендә кулланыла торган сүзләр тәшкил итә. Шуларның бер өлеше хәзерге татар әдәби теленең һәм көнчыгыш диалектының сүзлек фондына керәләр.

Сүзлектә теркәлгән сүзләрнең тагын бер үзенчәлеге итеп аларда чагылыш тапкан аваз күчешләрен һәм аваз тәңгәллекләрен күрсәтергә була. Сузык авазлар өлкәседә Себер татарлары диалектлары өчен авазларның киң һәм тар артикуляциясе хас. Бу очракта киң артикуляцияле [а] һәм [ә] тар артикуляцияле [ы], [е] авазына күчә: اژداها аждагы [аждаһа], ياني йаны [яңа], قاعز кагыз [кәгазь], قاذغانام казганам [кызганам]; и ~ ә күчеше очрагында йомшак, тар [и] киң сузык [ә] алмашына:كه شته кәштә [киштә],كه ره ك кәрәк [кирәк], به ك бәк [бик],كه به ن кәбән [кибән], انه анә [әни]; о ~ у күчеше вакытында урта күтәрелешле кыска [о] сузыгы озын [у] сузыгына күчә: سونك суң [соң],تول тул [тол]; кайбер сүзләрдә у ~ о күчеше күзәтелә, димәк [у] сузыгы [о] авазына күчә: اونونچى онунце [унынчы], قويان койан [куян],توقاز токаз [тугыз], توقسان токсан [туксан], قوزغالوкозгалу [кузгалу], ماتور матор [матур], ساتاشوچى суташоцы [су

ташучы]; шулай ук сүзләрдә ү ~ ө күчешен дә күрергә мөмкин. Иренләшкән озын [ү] авазы азрак иренләшкән [ө] авазына күчә:پوکه ن пөгөн [бүген],نوکه ل төгөл [түгел], کونکل көңөл [күңел]; сүзлектә теркәлгән сүзләрдә кирегә күчеш, ягъни ө ~ ү күчеше дә чагылыш таба:توس түс [төс], موشکول мүшкүл [мөшкел], یوذوم йүзүм [йөзем],مه نکو мәнгү [мәңге] һ.б.

И.Гиганов сүзлекләре лексик берәмлекләрнең күләме ягыннан да, структур яктан да бер берсеннән аерылып торалар. Беренче сүзлек телне башлап өйрәнүчеләр өчен төзелгән булса, икенче сүзлек академик басма рәвешендә эшләнгән. Тагын шуны да ассызыкларга кирәк: И.Гигановның сүзлекләре диалектологик сүзлекләрнең башлангычы булып саналалар. Соңрак алар үрнәгендә татар теленең яңа диалектологик сүзлекләре дөнья күргән.

Гомумән алганда, И. Гигановның тел белеме өлкәсендәге хезмәтләре үз вакытында, татар телен өйрәнү өчен, гаять файдалы кулланмалар булып саналган. Алар төрки телләрне өйрәнүдә мөһим урын билиләр. Хәзерге вакытта исә, әлеге хезмәтләр шул чор теленең лексик составын өйрәнү, бигрәк тә көнчыгыш диалектларны тикшерү өчен, бай чыганак булып торалар.

## А. Троянский сүзлегенә тарихи-лингвистик анализ

XIX гасырда татар тел белеменә, бигрәк тә, лексикографиягә зур өлеш керткән тюркологларның берсе – Александр Алексеевич Троянский. Ул 1779 нчы елда Казан өязе Апаз авылында туа. Әтисе рухани була. 1799 нчы елда Казан рухани академиясен тәмамлый һәм Казан губернасы Сотнуры авылында рухани хезмәтен башкара. 1800 нче елдан А.Троянский гомерен педагогик эшчәнлек белән бәйли һәм төрле типтагы уку йортларында татар теле укыта. Аның Казан рухани академиясендә татар теле укытучысы булып эшләве билгеле. Татар телен яшьтән белсә дә, фәнни яктан ул аны үзлегеннән өйрәнә, чөнки А.Троянский Казан рухани академиясендә укыган елларда анда татар теле укытылмый. Шуңа да карамастан, А. Кононов әйтүенчә, А.Троянский – татар теленең иң зур белгечләренең берсе, иң беренче грамматикаларның һәм күләмле сүзлекләрнең авторы була [Кононов, 1972: 272].

А.Троянский – үзенең грамматикалары һәм сүзлеге белән танылган галим. Аның «Краткая татарская грамматика, в пользу учащегося юношества, сочинение священника Александра Троянского» хезмәте 1814 нче елда Санкт – Петербургта, ә шушы ук грамматиканың икенче басмасы 1824 нче елда Казанда басылып чыга. Авторның тагын бер грамматик хезмәте «Краткая грамматика татарского языка» дип атала. Ул 1860 нчы елда, галимнең вафатынан соң, Казанда дөнья күрә.

А.Троянскийның татар лексикографиясенә керткән өлеше бик зур, ләкин бүгенге көнгә кадәр галимнең гаять күләмле сүзлеге тиешенчә тикшерелмәгән һәм үзенә лаеклы бәяне алмаган. Хезмәтнең исеме – «Словарь татарского языка и некоторыхъ употребительныхъ въ немъ реченiй арабскихъ и персидскихъ, собранный трудами и тщанiемъ учителя татарского языка въ Казанской семинарiи священника Александра Троянского и напечатанный съ дозволенiя комиссiи духовныхъ училищъ».

Беренче томы 1833 нче елда Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Ул 629 биттән тора, анда якынча 6490 сүз теркәлгән. Ә икенче томы 1835 елда басыла, ул 340 биттән гыйбарәт. Бу томда якынча 3400 сүз бар. Сүзлекнең форматы – 26*25.

Сүзлекне бастыруга рөхсәт 1829 нчы елның 31нче декабрендә бирелә. Беренче биттә мондый юллар бар: «По журналу Комиссiи Духовных училищъ 31- го декабря 1829 года состоявшемуся, печатать дозволяется для употребленiя въ подведомоственныхъ оной Комиссiи учебныхъ заведенiяхъ. Казанской Семинарiй Ректоръ, Архимандритъ и Кавалеръ Өеофанъ»


Словарь татарскаго языка и нѣкоторыхъ употребительныхъ въ немъ реченій арабскихъ и персидскихъ, собранный трудами и тщаніемъ учителя татарскаго языка въ Казанской семинаріи священника Александра Троянскаго и напечатанный съ дозволенія Коммиссіи Духовныхъ Училищъ. Томъ первый.

Казань. Печатано въ Университетской Типографіи. 1833.



А.Троянский сүзлегенең титул бите                А.Троянский сүзлегенең бер бите

Сүзлекнең төзелешенә, структурасына килгәндә, бу – алфавит тәртибендә төзелгән татарча-русча сүзлек. Сүзләрнең фонетик вариантлары аерым лексик берәмлек буларак теркәлгәннәр.

اتچ   Пътухъ, пътелъ, кочатъ [т.1:6]

اتش   Огонь, (пер. сл.) [т.1:6]

وله ن  Трава, мурава, зелень [т.1:131 ],

اوي   Дом, изба, покой [т.1:139],

اويرمه   Вихарь, буря, сильный ветер [т.1:139]

ايسلي   Душистый, вонючий, угарный, или: имеющий запах, дух, вонь, угар [т.1:153].

Географик атамаларны, милләт атамаларын теркәү сүзлекне тагын да кызыклырак итә.  Бу атамалар укучының дөньяга карашын киңәйтә, аның белемен арттыра. Хәзерге телдә бары рус варианты гына кулланылган географик атамаларның гарәп-фарсы, төрки вариантлары теркәлү сүзлекнең кыйммәтен арттыра, бәясен күтәрә.

А.Троянскийның татарча-русча сүзлеге башка милләт вәкилләрен татар теленә өйрәтү максатын күздә тотып төзелгән. Бу татар сүзләрен рус теленә тәрҗемә итүдә ачык чагыла. Татарча бирелгән һәр сүзнең рус

телендәге тәрҗемәсе, тәрҗемәнең барлык синонимнары, вариантлары күрсәтелә.

Автор сүзләрнең килеп чыгышына да игътибар итә һәм һәр сүзнең кайсы телдән керүен күрсәтеп барырга тырыша. Мәсәлән, сүзләр янында «араб.», «перс.» дигән искәрмәләр бар. Мисал өчен,پیشه пишә [перс.] – рукоделье, художество [т.1:259], تحسین тәхсин[1] [араб.] – хвала, похвала, одобрение [т.1:281], تفراج тәфәрреҗ [араб.] – веселье, забава, утешение, восхищение, увеселение [т.1:331], تفرق тәфәррык [араб.] — развод, разведение, разлука, отдел, отделение [т.1:331], چشم чишм [перс.] – глаз [т.1:467], اته ش атәш [ перс.] – огонь [т.1:9], جفت җефет [араб.] – жена, супруга [т.1:401]. Автор татар телендә пассив булган, сирәк кулланылган алынмаларны аеруча ассызыклый. Шул рәвешле, беренче томда - 374 гарәп, 162 фарсы сүзе, икенче томда 283 гарәп, 23 фарсы сүзе бирелә. Ләкин сүзлектә теркәлгән гарәп-фарсы алынмалары моның белән генә чикләнми.

Автор кайбер сүзләр янына җәяләр эчендә «трава», «дерево», «платье», «плод», «зверек», «растение», «рыба», «болезень», «грамматический термин» дип, сүзләрнең лексик мәгънәсен ачып бара, кайсы тематик төркемгә мөнәсәбәтле булуларын күрсәтеп үтә. Ләкин бу искәрмәләр һәрвакытта да куелмый. Автор укучы өчен бик үк таныш булмаган, пассив кулланылган сүзләрне шулай билгеләгәндер дип гөман кылырга мөмкинлек бар.

Сүзлектә фигыльләр -мак формасында теркәлгәннәр. Төрле юнәлешләрдәге фигыльләр аерым берәмлек итеп күрсәтелгәннәр. Берничә мисал китереп үтик: جرطماق җыртмак – драть, раздирать, разодрать, изодрать, рвать, разорвать, изорвать [т.1:393];جرطدرماق җыртдырмак – велеть драть, раздирать, изодрать, рвать, разрывать, разорвать, изорвать [т.1:393];جرطشماق җыртышмак – взаимно с кем драть, раздирать, издирать [т.1:393]; جرطلماق җыртылмак - драться, раздираться, изодраться, рваться, разрываться, разорваться, изорваться, или быть раздираему, издираему, разрываему [т.1:394].

[1] А.Троянский сүзлегендә гарәп алынмалары диокритик билгеләр белән тәкъдим ителә. Техник сәбәпләр аркасында бу билгеләр текста күрсәтелми.

Исемнән исем, исемнән сыйфат, сыйфаттан исем, исемнән рәвеш ясау күренеше дә сүзлектә киң яктыртылган. Мәсәлән, اوطون утын – дрова [т.1:115], اوطونلق утынлык – на дрова что [т.1:115], اوطنلي утынлы – дровяный [т.1:115]; ارق арык – худой [т.1:30], ارقلق арыклык – истощение [т.1:30], ارقلمق арыкламак – худеть [т.1:30], ارقلاماقلق арыкламаклык – истощение [т.1:30], خطن хатын – жена, супруга, женщина; خطنلق хатынлык – супружество; خطنلي хатынлы – женатый; хатынча – поженски, خطبلايхатынлай – женщиною [т.1:517-518], اولاو олау - подвода, اولاولقолаулык – на подводу что, اولاوجي олаучы – вощик, извощик [т.1:127].

Сүзлектә теркәлгән сүзләрнең күпчелеге хәзерге татар әдәби теленә бик якын. Алар бернинди лексик-семантик үзгәрешсез бүгенге көнгә килеп җиткән һәм телдәге лексик берәмлекләрнең төп өлешен, нигезен тәшкил итәләр. Ләкин бу сүзлек дөнья күрүгә 190 елга якын вакыт үткән, димәк, монда татар телендә шул еллар дәвамында булган үзгәрешләр дә чагылыш тапкан. Шуңа күрә сүзлектә иске татар язма әдәби теле традицияләре үрнәкләре, фонетик үзгәрешләр еш очрый. Мәсәлән, بوعداي бугдай – пшеница [т.1:219],اعذ агыз - рот, уста [т.1:52]. Сүзлектә иске традицияне саклаган چيراع чыраг – лучина [т.1:466], قاپوع капуг – ворота [ т.2:65] сүзләре теркәлеп калган. XIX-XX гасыр башында сүзнең уртасында [г] авазының төшеп калуы татар теле өчен әдәби норма булып карала башласа да, күрсәтелгән мисалларда традициянең саклануы чагыла. Хәзерге татар телендә, иске татар теленнән аермалы буларак, сүз азагында [ г] авазы төшеп кала. Бу кыпчак телләрен, шул исәптән татар телен башка төрки телләрдән аерып тора торган үзенчәлек булып санала [Хаков, 1965: 111-112].

Сүз башы позициясендә җ ~ й килүгә карата тюркологиядә төрле фикерләр бар. М.Кашгари үзенең мәгълүм сүзлегендә: «Угызлар һәм кыпчаклар й белән башланган исем һәм фигыльләрнең баш хәрефен әлифкә яки җ га әйләндерәләр»,– дип яза. В. Радлов, В. Богородицкий, Л. Җәләй [й] авазының киң кулланылуын кыпчак телләре өчен хас дип аңлаталар [Хаков,1965: 114].

Татар әдәби теле төрле кабилә телләре үзенчәлекләре җирлегендә формалашкан. Аерым диалектларда җ-ләштерү һәм й-ләштерү күренешенең

булуы шуны раслый. Бу факт А.Троянский сүзлегендә дә бар. Сүз башы позициясендә **й** ~ **җ** нормалашып җитмәвен, параллель кулланылуын түбәндәге мисаллар ачык күрсәтә:يتمك **йетмәк** – достигать [т.2:278], يتن **йетен** – ленъ [т.2:278], يتمش **йетмеш** – семьдесятъ [т.2:278], ير **йер** – земля [т.2:286],ير **йыр** – песня [т.2:286], يلكه ن **йелкән** – парусъ [т.2:318], يره ن **йерән** – рыжій [т.2:287], يلم **йелем** – клей [т.2:314];جدره **җәдрә** – пуля [т.1:392], جار **җар** – берегъ [т.1:393],جاو **җау** – война [т.1:418], جرطقج **җырткыч** – хищный [т.1:394], جورغان**җурган** – одеяло [т.1:395].

Сүзлектә теркәлгән сүзләрне хәзерге тел берәмлекләре белән чагыштырып караганда, төрле аваз тәңгәллекләрен күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, **м~б** тәңгәллеге: موز **муз** [т.2:214] – боз; **д~т** тәңгәллеге:درسه ك **дерсәк** [т.1:526] – терсәк,دز **дез** [т.1, с.529] – тез, دير **дир** [т.1:529] – тир, دزكين **дезген** [т.1:529] – тезген,داسطمال **дастымал** [т.1:530] - тастымал һ.б.; **т~д** тәңгәллеге: طولقن **тулкын** – дулкын [т.2: 20.]; **п** ~ **ф** тәңгәллеге: ياپراق **япрак** – яфрак, قرپک **керпек** – керфек; **г~w** тәңгәллеге:**باغر** **багыр** – бавыр [т.1:214 ]; نولغار تاولاري **Болгар таглары** – Болгар таwлары [т.1:233]; **с** ~ **ч** тәңгәллеге: **сач** – чәч [т.1:568]; **р~й** тәңгәллеге:اربير **әрбир** – әйбер [т.1:21]; **б** ~ **м** тәңгәллеге: **بنك** **бең** – мең [т.1: 222]; **х** ~ **к** тәңгәллеге: خمر **хамыр** – камыр [т.1:522]. Автор сумала сүзен سوملا **сулама** [т.1:610] дип, абзар сүзен اذبار **азбар** [т.1:31] дип бирә. Монда аваз үзгәрешенең бер төре – метатеза күзәтелә.

Сүзләр арасында гарәп-фарсы алынмалары да шактый зур урын алып тора. Мәсәлән, باحر **бахыр** – весна [т.1:244],پەدر **падр** – отец [т.1:254], پره**парә** – кусок [т.1:254], پيز **пиз** – сыр [т.1:262], تيمساح **тимсах** – крокодил [т.1:369], جلد **җилд** – экземпляр [т.1:408], لعال **ләгаль** - брилиант [т.2:202], حردال **хәрдәл** – горчица [т.1:519], پهلوان **пәһлеван** – герой [т.1:262], جاداو **җадау** - волшебник [т.1:392], حكم **хөкем** - суд [т.1:510], رسقال **рыскал** – счастье [т.1:548], روشان **рушан** –светлый [т.1:549], طالعة **талига** – счастье [ т.2:19], عاجم **гаҗәм** – персиянин [т.2:33] һ.с. Бу сүзләр янында автор берниди искәрмә дә бирми.

А.Троянский хезмәтендә хәзерге татар телендә булмаган, ләкин хәзерге төрек телендә сакланып, актив кулланылышта булган лексик берәмлекләр дә очрый. Мәсәлән,اناحطار **анахтар** – ключь [т.1:72], ياغ **йаг** –

масло [т.2:301], تميذ **тәмиз** – чистый [т.1:369], پنجره **пәнҗәрә** – окно [т.1:262], به بر **бәбер** – перецъ [т.1:174], بارداق **бардак** – кувшинъ [т.1:182], الدوان**әлдәвән** – перчатки [т.1:65], اقرب **акраб** – ближній [т.1:54].

Алынмалар арасында рус яки рус теле аша башка телләрдән кергән сүзләр дә бар. Мисал итеп түбәндәге берәмлекләрне китерергә мөмкин: كوسله **күслә** – гусли [т.2:171], كوشنه **күәшнә** – квашня [т.2:196], مديه **медия** - морская раковина [т.2:211], دكت **дегет** - смола [т.1:531], سكومبريا**скумбрія** – сельдь [т.1:36],ايشله به **эшләпә** – шляпа [т.1:42], پليس **плис** – плис [т.1:216],فنار **фонар** - фонарь [т.1:262], تولان **тулан** – тюлень [т.1:361], بورام **буром** – паром [т.1:189] һ. б. Югарыда күрсәтелгән сүзләр, нигездә, татар теленә хас булган фонетик закончалыкларга буйсынганнар. Димәк, алар телдә актив кулланылышта булганнар һәм телебезгә бик күптәннән кабул ителгәннәр.

Сүзлекнең үзенчәлекле ягы – лексик берәмлекләр арасында географик атамаларның теркәлүе: بيچ **Бич** – Вена, بحر حاذاي **Бахыр Хазар** – Каспій, سويس دينكز **Суес диңгез -** Красное море [т.1:578], اعي طاعي **Агы тагы** - Араратские горы [т.1:52], قاذاق ولاياتي **Казак вилаяте** – Украина [т.2:94], چين ما چين **Чин ма чин** – Китайъ [т.1:490], روسيا مملهكتي **Русия мәмләкәте** – Россія [т.1:549], جنويذ ولاياتي **Җануез вилаяте** – Генуа [т.1:418], جزاير**Җазаир** – Алжиръ [т.1:396], تاتار ولاياتي **Татар вилаяте** –Татарія [т.1:270], يانا دونيا **Яңа дөнья** – Америка [ т.2:312], باعدان **Багдан** – Молдавія [т.1:217], پاريز شهه ري **Париз шәһәре** – Парижъ [т.1:255], ارمه ني كبير **Әрмәния Кәбир** – Великая Арменія [т.1, с.27], ارمه ني سغير **Әрмәния Сагыйрь** – Малая Арменія [т.1:27], طونا **Туна** – Дунайъ [т.2:26], فلامينغ ولاياتي **Фламинг вилаяте** – Голландія [т.2:55] һ. с.

Вакытлар үтү белән, сүзләрнең бер өлеше әдәби телдән төшеп калып, бары диалектларда гына сакланганнар. Мәсәлән,پەرەچە **чәрәчә** – крыльцо [т.1:463] хәзерге телдә юк, ул бары урта диалектның минзәлә сөйләше Әгерҗе урынчылыгында гына сакланган һәм “мунча өй алды” дигән мәгънә белдерә. Ул диалектологик сүзлекләрдә дә теркәлмәгән. Бу бик борынгы сүз, Мәхмүт Кашгарый сүзлегендә үк булган һәм өй алды мәгънәсен белдергән. Бу хакта М.Ногман болай дип яза: «Элек лампа урынына чыра яндырганнар. Алдан әзерләп куелган чыралар өй алдында сакланган.

Шуннан өй алды – чырача дип аталган булырга тиеш ». XIX гасыр сүзлекләреннән бу сүз Л.Будагов сүзлегендә урын алган [Ногман, 1969:103]. Диалекталь сүзләргә كرچمه **керчемә** – мед варенный, сладкий [т.2:154], كونه سوي **күнә суы** – ртуть [т.2:188], لواش **ләвәш** – сладкий пирог [т.2:202], بارماقجا **бармакча** – перчатки [т.1:182],تره ك **тирәк** – узор [т.1, с.303], چمهک **чемәк** – гвоздь бочечный, مقسما **максыма** – пиво [т.2:224], يلدرم **йылдырым** – гром [т.2, с.339],يارقا **ярка** – плаха [т.2:314], اران **аран** – едва [т.1:20],جور **җәүер** – род, поколение [т.1:395], أچتقي **ачыткы** – квас [т.1:12], الچاق **алчак** – ласковый [т.1:64] һ. с. берәмлекләр керә. Югарыда китерелгән мисаллар татар теленең төрле диалектларында, сөйләшләрендә хәзер дә актив кулланылалар. Мәсәлән, چمهك **чемәк** сүзе тау ягы, мәләкәс, чүпрәле сөйләшләрендә агач бөке, мичкә, сыра чүлмәге кебек мәгънәләрдә [ТТДС, 1969:480], يارقا **ярка** – гәй татарлары, минзәлә сөйләшләрендә ярган агач [ТТДС, 1969: 167], كونه سوي **күнә суы** – казан арты, тау ягы сөйләшләрендә терекөмеш [ТТДС, 1969: 285 ],لواش **ләвәш** – казан арты, каргалы сөйләшләрендә пирог [ТТДС, 1969: 293] дигәнне белдерә, يلدرم **йылдырым** сүзе себер татарлары сөйләшләрендә яшен [Тумашева,1992: 90],مقسما **максыма** – казан арты-лаеш, тау ягы сөйләшләрендә өйдә кайнатылган сыра [ТТДС,1969: 298],كرچمه **керчемә** – чүпрәле сөйләшендә ачы бал [ТТДС,1969:239] мәгънәсендә кулланыла. **Керчемә** сүзенең тамыры, Р.Әхмәтьянов фикеренчә, борынгы алтай телендәге **кор** – «ачы, әчегән» сүзенә барып тоташа [Әхмәтьянов, 2001: 99]. Бу сүз рус телендәге **корчма – трактир** сүзе белән бер тамырдан булырга мөмкин. Н.Шанский исә корчма сүзнең этимологиясен билгесез дип күрсәтә [Шанский:214].

Сүзлектәге кайсыбер сүзләрнең мәгънәләре үзгәргән. Мәсәлән, طوطاش **туташ** сүзенә А.Троянский «сестра большая или тетка, сестрица, тетушка» дигән аңлатма бирә, хәзерге телдә бу сүз буйга җиткән кыз дигән мәгънәдә кулланыла. Конфет сүзе сүзлектә хәлвә дип бирелә. Әлеге мәгънәдә бу сүз XIX гасырда чыккан башка сүзлекләрдә һәм үзөйрәткечләрдә дә очрый. Хәзерге телдә хәлвә аерым бер ризык төрен генә белдерә,چهبرچك **чәберчек – синица** [т.1: 426] сүзендә дә мәгънә үзгәрү күзәтелә. Хәзерге татар телендә чәберчек «кош басып утырганда, бала чыкмыйча бозылган йомырка» дигән мәгънә белдерә [ТТАС, т.3: 465].

А.Троянский сүзлегендә хәзерге чорда телебездән төшеп калган, сакланмаган, югалган сүзләр дә бар.جالاو **җалау** – завязка у платья [т.1:407], طو **ту** – знамя [т.1:379],تنكه حانه **тәңкәханә** – монетный дворъ [т.1:377],باغبان **багбан** – виноградарь [т.1:214], اركن اجمق **иркен ачмак** – гулять, прогуливаться, делать прогулку [т.1:149], برادر **брадәр** – братъ [т.1:185], بورلي **бурлы** – чалыйъ [т.1:193],يالاو **ялау** – флагъ [т.2:314],ماعدانوس **магданус** – петрушка [ т.2:221],محمان حانه **михманханә** - гостиница [т.2:240],يامن **ямин** – присяга [т.2:326],ياس **яс** – трауръ [т.2:295], لشكه ر**ләшкәр** – войско [т.2:201], كن چهچهگى **көн чәчәге** – ноготки [т.2:192], كمنهش سوي**көмшән суы** – ртуть [ т.2:194], رحيم قوشي **рәхим кошы** – пеликанъ [т.1:543], ساذ اعاجي **саз агачы** - ива [т. 1:575], ايشق بالق **ышык балык** – треска [т.1:42],قوين اعاجي **кавын агачы** – цитронное дерево [т.1:49],قويرعا بالق **кавырга балык** – кит [т.2, с.73], قورط **корт** – волкъ [т.2:87], قيسي **кыйсы** – абрикосъ [т.2:100], تلده ك **телдәк** – говорокъ [т.1:358], اطالق **аталык** – отечество [т.1:9], اق دكه ن **ак дикән** –крыжовникъ [т.1:57], دفنه اعا جي **дәфнә агачы** – лавровое дерево [т.1:533], سيمه له ك **симәләк** – овчарка [т.1:586], قان **кан** – руда [ т.2:121],قوا **куа** – бурый [т.2:125], كوكنار **күкнар** – макъ [ т.2:178], منزل **мәнзил** – почтамтъ [ т.2, с.234]. Мөгаен, бу сүзләр XIX гасырда актив кулланылышта булгандыр, чөнки аларның бер өлеше جالاو **җалау** [Вагапов,1881:59], بورلي **бурлы** [Салихов,1885:35], قيسي **кыйсы** [Вагапов,1881:5], **магданус** [Вагапов, 1881:7] һ.б. берәмлекләр шул чорда дөнья күргән татар теле үзөйрәткечләрендә дә урын алган. Ә үзөйрәткечләргә, мәгълүм булганча, иң актив, иң еш кулланыла торган сүзләр генә кертелгән. Югарыда китерелгән кайбер сүзләр татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «иск. » искәрмәсе белән теркәлгәннәр. Мәсәлән, **ялау** иск. байрак [ТТАС, т.3:632], **ямин** иск. кит. ант [ТТАС, т.3:638], **брадәр** иск. кит. ир туган [ТТАС, т.1:184]. Әлеге сүзләрнең бер өлеше татар телендә сакланмаса да, башка төрки телләрдә хәзер дә кулланылалар. Мәсәлән, **кыйсы** сүзе кумык, төрек, караим телләрендә актив [Мусаев:192]. Ә берничәсе ялгызлык исемнәре составында сакланганнар. Мәсәлән, Башкортостан сүзе составында **корт** сүзе бар, ә **мәнзил** сүзе Мәнзил дигән ир-ат исеме буларак кулланыла [Саттаров:176].

Сүзлек турында гомуми нәтиҗә ясап әйткәндә, А.Троянский сүзлеге – XIX гасырның беренче яртысында дөнья күргән иң зур татарча-русча

сүзлек булуын искәртү зарур. Ул алда каралган И.Гиганов сүзлекләреннән лексик берәмлекләрнең составы, байлыгы ягыннан аерылып тора. Анда 22 меңнән артык сүз һәм сүз формасы тупланган. Сүзләр тормышның төрле өлкәләренә карый һәм һәр сүзнең синонимнары, диалекталь вариантлары аерым сүзлек мәкаләсе итеп формалаштырылган. Бу искиткеч зур лексик байлык аерым монографик өйрәнүгә лаек.

## С.Кукляшевнең «Словарь к татарской хрестоматии» сүзлеге

XIX гасырда Россиядә көнчыгыш телләре, татар теле укыту белән Оренбург Неплюев кадет корпусы дан тота. Бу уку йортында М.Иванов, М.Бекчурин, С.Кукляшев кебек укытучы- галимнәр эшли. Аларның һәрберсе, үз тәҗрибәләренә таянып, дәреслекләр, сүзлекләр, үзөйрәткечләр, хрестоматияләр язып бастыралар. Шуларның берсе – С. Кукляшевның «Словарь к татарской хрестоматии» (Казань, 1859. – 106 с.) хезмәте.

С. Кукляшевның тормышы турында берничә мәгълүмат китереп үтик. Аның туган елы төгәл билгеле түгел. 1825 нче елдан ул Оренбург Неплюев хәрби училищесында укый башлый. Училищены тәмамлагач, Оренбург чик буе комиссиясендә тылмач булып эшли. Ә берничә ай үткәч, Казанга укырга җибәрелә. Башта медицина факультетында укый, ләкин авыру сәбәпле, филология факультетына күчерелә. Филология факультетында Салихҗан гарәп, фарсы, төрек, татар телләрен өйрәнә. Университет программасы таләп иткән күләмдә латин, немец, француз, рус телен үзләштерә. 1836 нчы елда ул университетны кандидат дәрәҗәсендә тәмамлый һәм үзе тәмамлаган Неплюев хәрби училищесына эшкә чакырыла. 1858 нче елда аның 20 еллык хезмәт контракты тәмамлана һәм ул пенсиягә китә. 1864 нче елда вафат була [Миңнегулов, Садретдинов, 1982:67 ].

С.Михайлова үз хезмәтендә С.Кукляшевны татар мәдәниятен һәм иҗтимагый фикерен үстерүгә үзеннән кыйммәтле өлеш керткән мәгърифәтче дип атый һәм аның күренекле татар педагоглары,

мәгърифәтчеләре, фольклорчылары арасында лаеклы урын алып торырга хаклы булуын күрсәтә [Михайлова, 1972:175-183].

А.Н. Кононов редакциясендә басылган «Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов» дигән хезмәттә С.Кукляшевның «Диване хикәяте татар» исемле 124 битлек хрестоматиясе 1870, 1895 нче елларда кабат нәшер ителүе күрсәтелә [Кононов, 1974:201].

Салихҗан Кукляшевның хрестоматиясе «Диване хикәяте татар», ягъни «Татар хикәятләре җыентыгы» дип аталган. Бу хезмәт бик югары дәрәҗәдә булган. Дәреслек өч төп өлештән гыйбарәт: кереш мәкалә (1-3 б.), текстлар «Гыйса углы Амәт», «Ширзад вә Гөлшаджан», «Искәндәрнамә» һ.с. (3-124 б.) һәм сүзлек.

С.Кукляшевның «**Словарь къ татарской хрестоматии**» хезмәте 1859 нчы елда Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Сүзлекне бастырырга цензор И.Готвальд рөхсәт бирә. Титул битендә «Печать дозваляется съ темъ, чтобы по напечатаніі представлено было въ цензурный Комитетъ указанное число экземпляровъ. Казань, 19 мая 1859 г.» дип язылган. Хәзерге вакытта сүзлекнең берничә нөсхәсе Казан дәүләт университеты китапханәсенең сирәк китаплар бүлегендә Готвальд фондында саклана. Сүзлекнең форматы – 16*22.

Салихҗан Кукляшевның сүзлеге башка сүзлекләрдән аерылып тора. Ул хрестоматиягә кушымта итеп төзелгән һәм, иң беренче чиратта, татар булмаган укучыларга адресланган. Сүзлекнең максаты –хрестоматиядә урын алган һәр сүзгә, ягъни 3546 лексик берәмлеккә русча аңлатма бирү, тәрҗемә итү.


СЛОВАРЬ
КЪ
ТАТАРСКОЙ ХРЕСТОМАТІИ,
СОСТАВЛЕННОЙ
С. КУКЛЯШЕВЫМЪ.
КАЗАНЬ.
Въ Университетской типографіи
1859.



С.Кукляшев сүзлегенең титул бите — С.Кукляшев сүзлегенең бер бите

Сүзлек алфавит тәртибендә төзелгән: башта гарәп шрифты белән язылган татар сүзләре теркәлгән һәм каршысында русча тәрҗемәсе дә бирелгән. С.Кукляшев сүзләргә аңлатмаларны, контекстка нисбәтле рәвештә, мөмкин кадәр тулырак бирергә омтыла:

*а.* امر **әмер** – приказаніе [б.14]
بالچق **балчык** – грязь, глина [б.23]
*а.* امان **аман** – безопасность, миръ, пощада, покой [б.14]
اومچ **умач** – мучной бульонъ [б.19]
دلدل **дөлдел** – конь Алія, 4 арабскаго халифа [б.49]

Шунысы мөһим: Салихҗан Кукляшев, А.Троянский үрнәгендә, шартлы билгеләр ярдәмендә гарәп, фарсы, кыргыз (казах), иске татар һәм төрек сүзләрен дә билгеләп бара. Мәсәлән, **а**. – значить арабскія слова, **п**. – персид, **к**. – киргизскія, **т**.– турецкая или старыя татарскія слова, вышедшія изъ употребленія, **с**. – значитъ слово составленныя изъ арабскихъ или персидскихъ словъ съ прибавлением на конце оныхъ татарскихъ частицъ или глаголовъ [Кукляшев, 1859:3]. Әгәр дә башка сүзлекләрдә татарча сүзләр я хәрәкәләр, я янәшәдә рус хәрефләре белән бирелгән булса, бу

сүзлектә исә андый ысул күзәтелми. Шуның нәтиҗәсендә аерым сүзләрне уку авырая, аларны төрлечә уку ихтималлыгы барлыкка килә.

Күп сүзләр бернинди фонетик үзгәреш тә кичермәгәннәр һәм хәзерге татар телендә шундый ук формада кулланылалар: انت **ант** – клятва, присяга [б.14 ]; امر **әмер** – приказание [б.12] , او **ау** – охота, ловля [б.15], اوچی **аучы** – охотник [б.16], بسقچ **баскыч** – лестница [б.23], بالچق **балчык** – грязь, глина [б.23], بورك **бүрек** – шапка [б.26 ], طبان **табан** – подошова [б.30 ], طاج **таҗ** – корона [б.30 ], طبوط **табут** – гроб, гробница [б.30 ], تن **тән** – тело [б.34 ], یاز **яз** – весна [б.102 ], قایدان **кайдан** – откуда [б.74 ].

Сүзләрнең күп өлеше үзгәрешсез булса да, әлбәттә, кайбер фонетик тәңгәллекләр, чиратлашулар чагылыш таба. Мәсәлән, хәзерге татар әдәби теле белән чагыштырганда, сүзләрдә **г– к** чиратлашуы күзәтелә: تکرمچ **тәкәрмәч** – колесо [б.33 ], تکرمك **тәкәрәмәк** – катиться [б.33 ], تکرب تشمك **тәкәрәп – тешмәк** – скатиться [б.33], تقن **такын** – еще [36 ], تکرکلك **түкәрәклек** – круглость, круглота [б.36 ], تکز тикез – ровный [б.36 ], سقش **сукыш** – война [б.62] һ.б.

Чиратлашу **г– к** авазлары белән генә чикләнми, шулай ук **д–т** ترت **түрт** – четыре [ б.34] **с – ч** سچ **сач** – волосы [ б.54 ], **п – б** کبکا **кабка** – ворота [б.72], **й – ж** یلد **йилде** – семь [б.103 , جمرد **жумард** – шедрый [б.39], **м – б** کب **күб** – много [б.81] , **м – н** چغن **чыгын** – расход [б.40] чиратлашуы да күзәтелә.

Сүзлектә XIX гасыр теленә хас орфографик нормалар теркәлгән: صغر **сыгыр** – корова [б.61], طغمق **тугмак** – родиться [б.11], اغلمق **агламакъ** – плакать [б.11], چرق **чырагъ** – свеча [б.40]. Бу берәмлекләр шуңа дәлил булып торалар.

Фонетик үзенчәлекләр белән беррәттән, кайбер морфологик үзенчәлекләргә дә игътибар ителде. Фигыльнең инфинитив формасы –мак кушымчасы ярдәмендә ясалган. Моңа мисал итеп: طبمق **табмак** – найти, рождать [б.65], ترمق **турамак** – крошить [б. 66], قچقرمق **кычкырмак** – кричать [б.73 ], یرالامق **яраламак** – ранить [б.101], سومق **саумак** – доить [б.62]; ایسنلشمك **исәнләшмәк** [б.16], کرشمك **күрешмәк** – здороваться, прощаться [б.81]; قچمق **ачмак** – проголодаться [б. 6 ], قچمق **ачмак** – отпирать, открывать [б.6] сүзләрен китереп була Фигыльнең юнәлеш

формалары да бирелә һәм һәр форма аерым лексик берәмлек буларак теркәлә: قچلمق **ачылмак** – отпираться [б.6 ] – кайтым юнәлеше кушымчасы -л, -ыл; اطلمق **атылмак** – застрелиться [б.10], **буятмак** – заставить красить [б.27], سلدرمق **салдырмак** – заставить налить [б.62] – йөкләтү юнәлеше; سيلشمك **сөйләшмәк** – разговаривать [б.60] фигылен уртаклык юнәлешенә мисал итеп күрсәтергә мөмкин.

Сыйфатлар бернинди үзгәрешсез бирелгәннәр:ايسكي **иске** – старый [б. 19], ر, قچ **ач** – голодный [б.10 ], نچار **начар** – плохой, дрянной [б. 95], احمق **ахмак** – глупый [б.12], اذد **азад** – свободный [б.13], اچق **ачык** – открытый [б.10 ]. Салихҗан Кукляшев -лы, -ле кушымчаларына аңлатма биреп, «... *частица прибавляемая к имени существительному для составления имени прилагательного* » – ди [Кукляшев,1859:68]. Димәк, ул чорда да сыйфат ясаучы иң продуктив кушымча “-лы, -ле” кушымчалары булган: ططليтатлы – сладкий, вкусный, акыллы – умный [ б.68 ]сыйфатлары моңа ачык мисал булып тора.

Сүзлек бик үзенчәлекле. Бу хезмәттә С.Кукляшев хрестоматиясендә урын алган текстлардагы лексик берәмлекләр сүзлек формасына китереп, тәрҗемә ителгән. Монда телдә актив кулланылышта булган сүзләрне дә, шулай ук кулланылышы чикле, пассив булган берәмлекләрне дә күрергә мөмкин.

Хрестоматиядәге төрки-татар телендә язылган үрнәкләр дә бар. Ләкин текстлар, нигездә, гарәп, фарсы теленнән тәрҗемә ителгән һәм шуңа күрә сүзлектә бу телләрдән кергән берәмлекләр аеруча күп.

Сүзлек, иң беренче чиратта, рус яки башка милләт вәкилләре өчен төзелгән, шуңа күрә сүзләрне тәрҗемә итү алымнары бигрәк тә игътибарга лаек дип уйлыйбыз. Сүзгә сүз, ягъни эквивалент тәрҗемә сүзлектә төп урынны алып тора: امر әмер – приказание [б.14 ], اطا ата – отец [б.5 ], بوريбүре – волкъ [б.26 ], بلبل былбыл – соловей [б.26]. Ләкин автор сүзнең бер тәрҗемәсе белән генә чикләнеп калмый, булган синонимнарны да теркәп бара. Мәсәлән: ايمام **имам** – имам, мулла, священник [б.14], اماн**аман** – безопасность, мир, пощада, покой [б.14 ], انط **ант** – присяга, клятва [б.14 ], وچ **оч** – вершина, конец, край [б.16 ], اول **авыл** – деревня, селение, край [б.18 ], ايش **иш** – другъ, товарищъ, подруга, чадо, подобте,

подобный [б.21]. Бу алым бер телдәге сүзнең мәгънәсен икенче тел вәкиле өчен тулырак, төгәлрәк аңлату мөмкинлеген ача.

Кайбер сүзләргә автор аңлатмалар, иллюстрацияләр бирә. Бу сүзләр – я халык атамасы, я дини термин, я милли үзенчәлеккә ия берәмлек. Мәсәлән, ومچ **умач** – мучной бульон [б.19 с.], دلدل **дөлдел** – конь Алия, 4 арабского халифа [б.49 ], ايبالتا **айбалта** – топор с длиннымъ топорищем, которымъ киргизы бьютъ волков [б.24], تبتر **типтәр** – типтярь, название народа, которой проживаетъ в Оренбургской губернии [б.31], ايسطرشنا**эстаршина** – начальник юрты или нескольких деревень [б.21], صور بازاري **сур базары** – базаръ, торгъ сурками в мае месяце при г. Оренбурге [б.62 ].

Автор бер үк мәгънәле сүзнең төрлечә язылуына да игътибар итә: اچو «ачу» или اچغ «ачигъ» – гнев [б.6], الس «алыс» или الوس «алус» – далекий [б.13с], омонимик эчтәлекле сүзләрне дә күз уңыннан ычкындырмый:اوط **ут** – огонь, трава[б.17], اياق **аяк** – чаша, нога [б.20], جوان **жуан** – юноша, толстый [б.39],اوق **ук** – уже, стрела [ б.25 ], بابا **баба** – дедушка, отец [б.26].

Бүгенге көндә дә кулланылышта йөргән сүзләр, ягъни актив лексика арасында архаизмнар да очрый: باقي **бакы** – остальной, оставшийся [б.27], بدن **бәдән** – тело [ б.24 ], بوي **буй** – запах [хуш – буй] [б. 27 ], بينك **бинәк** – тысяча [б.26 ], طنمق **танмак** – запираться, отпираться [б.31 ], ادق **адак** – нога [б. 13], بادا **бада** – вино [б.22 ], اشباذ **ашбаз** – повар [б.10 ], تحتپاى **тәхетпай** – столица [б.32].

С. Кукляшев сүзлегендә сүзләрне килеп чыгышы ягыннан анализларга да бик уңай. Югарыда әйтелгәнчә, автор гарәп теленнән кергән сүзләр алдына **а.**, جرحت **җәрәхәт** **–** рана [б. 38 ], фарсы – **п.**,بها **бәһә** – цена [б.27],احتر **әхтәр** – звезда [б.6], төрек сүзе булса **т.** چوق **чук –** много [б.41], казах сүзе булса **к.** اوط **ут** – трава [б.17 ], تنته ك **тинтәк** – глупый, безумный [б.34] хәрефләре куя. Мәсәлән, алфавит буенча **х, ф , р, д** хәрефләренә килеп җиткәч, анда бары тик гарәп һәм фарсы сүзләре генә теркәлгән булуы күренә. Димәк, бу хәрефләргә башланган сүзләр алынма икәнен бик тиз ачыклап була:حيلة **хәйлә** – хитрость [б.44 ], خيوان **хайван** – животное, зверь, скот [б.44], حان **хан** – царь [б.44], حانه **ханә** – дом [б.44], حطا**хата** – ошибка [б.43], حيال **хыял** – мечта, воображение [б.43], حليفة

**хәлифәт** – халифатство [б.46], حوش хуш – приятный [б.46], روح **рух** – дух[б.52].

Сүзлектә теркәлгән сүзләрнең хрестоматиядәге текстлардан алынуын әйтеп үттек. Шуңа нисбәтле рәвештә, сүзлектә төрле телләрдән кергән сүзләр теркәлеп, үзара синонимик рәт хасил итәләр. Мәсәлән, مشاق мушак – кошка [б.90]مچى , мачы – кошка [б.85 ], ذه ر зәр – золото[б.54],الطن алтын – золото[б.12],بعر бәгырь– сердце [б.25], حتر хәтер – сердце[ б.46].

Сүзлектә ай исемнәренең Иран кояш календаре вариантлары теркәлгән. حمل хәмәл – март [б.46], حط хут – февраль[б.43], مذان мизан – октябрь [б.90] һ.б. Айларның шул рәвешчә бирелеше И.Гиганов сүзлегендә (1801), М.Бекчурин үзөйрәткечендә (1856) дә бар.

С. Кукляшев тарафыннан төзелгән сүзлектә ил, шәһәр атамалары да урын алган. Бу хрестоматиядә бирелгән текстлар белән дә бәйле. Мәсәлән, زوي Зөя – Свияжск [б. 53 ], جايق Җаек – Урал [б. 37], روم Рум – Греция [б.52], تشكند Ташкенд – Ташкент [б.31], قزان Казан – г.Казань [б.76], منزله Минзәлә – Мензелинск [с.93]һ.с.

Шулай итеп, С.Кукляшев сүзлеге бу чорда дөнья күргән сүзлекләрдән үзенең эчтәлеге белән аерыла. Сүзлекнең төзелү максаты да төгәл билгеләнгән. Ул хрестоматиягә кушымта итеп төзелгән, шуңа күрә сүзләр составы бик үзенчәлекле. Сүзлектә хрестоматиядә урын алган хикәяләрдәге сүзләр генә теркәлгән һәм шул сүзләргә аңлатма бирелгән.

Гомумән, сүзлек уңай тәэсир калдыра. Ул, бер яктан, текстларны аңларга, төшенергә мөмкинлек бирсә, икенче яктан, тел һәм лексикография тарихын өйрәнүдә мөһим чыганак булып тора. Бу сүзлекнең XIX гасыр татар әдәби теле үрнәге итеп саналырга тулы хокукы бар. Кызганычка каршы, практикада һәм лингвистик тикшеренүләрдә бу сүзлек әлегә бөтенләй диярлек искә алынмый.

## Н.Остроумов сүзлекләре

XIX гасыр ахырында миссионерлар җәмгыяте тарафыннан христиан динен пропагандалаган китаплар бастырыла. Рус булмаган халыкларга христиан дине тәгълиматларын өйрәтү шул халыкның милли телен яхшы белүне таләп итә. Шул максаттан христиан миссионерлары төрле телләрне, шул исәптән татар телен дә бик җентекләп өйрәнәләр. Җәмгыять ике телле сүзлекләр бастырып чыгара башлый. Шушы басмалар арасында Н.Остроумовның 1876 нчы елда чыккан «Первый опыт словаря Остроумова народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии», һәм 1892 нче елда дөнья күргән “Татарско-русский словарь» дигән хезмәтләре бар.



Н.Остроумов 1846 нчы елның унбишенче ноябрендә Тамбов губернасының Сосаво Елат авылында дворяннар гаиләсендә туа. 1866 – 1870 нче елларда Тамбов өлкәсендәге семинариядә, аннан соң Казан рухани академиясендә белем ала. Н.Остроумов анда «Мөселманнарга каршы миссионерлар» бүлегендә укый һәм Н.И. Ильминский, Е.А. Малов, В.Т. Темофеев кебек укытучылардан белем ала.

1870 нче елда Н.И. Ильминский тәкъдиме белән Н.Остроумовны, ике сынау лекциясеннән соң, мөселманнарга каршы көрәшкән миссионерлар

кафедрасына сайлыйлар һәм Казан рухани академиясендә татар теле укытучысы итеп билгелиләр. Н.Остроумов 1871 нче елда магистр дәрәҗәсенә лаек була. Шушы ук елны аңа доцент исеме бирелә һәм ул Казан рухани академиясендә татар теле укытуны дәвам итә. 1872 нче елның беренче ноябреннән алып 1874 нче елның егерменче июленә кадәр тарих, география кебек фәннәрне укыта.

1877 нче елның беренче июленнән башлап, Н.Остроумов Төркмәнстанда халык училищесы инспекторы итеп билгеләнә. 1879 нче елда семинария директоры, 1883 елда ирләр гимназиясенең директоры булып эшли.

Н.Остроумов үзенең кырык ел гомерен Ташкентта үткәрә. Ул Төркестан археология яратучылар түгәрәгендә вице-президенты була. Казанда «Миссионерлар җыентыгы» газетасын чыгаруда катнаша һәм газетаның икенче, өченче, алтынчы, унынчы, уникенче саннарын нәшер итүдә зур ярдәм күрсәтә.

Н.Остроумов – йөзләгән басма хезмәтләр авторы. Алар арасында




«Первый опыт словаря Н.Остроумова народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии» (1876) һәм




«Татарско-русский словарь» (1892) аеруча игътибарга лаек.

Беренче сүзлек (1876) Казан император университеты типографиясендә басылган һәм керәшен мәктәпләре өчен файдалы кулланма итеп тәкъдим ителә. Бу сүзлек 145 биттән гыйбарәт. Кереш өлешендә татар теленең тарихы, грамматикасы, фонетика һәм морфологиясе турында тулы мәгълүмат бирелә.

Н.Остроумовның 1892 нче елда чыккан «Татарско-русский словарь»ын миссионерлар җәмгыяте сүзлеге дип йөрткәннәр. Сүзлек өч кеше: Н.Ильминский, Н.Остроумов һәм А.Воскресенский тарафыннан төзегән. Ләкин беренче булып бу эшне Н.Остроумов башлый. Ул сүзләрне туплый, терки, ә Н.Ильминский сүзлекне бастыра, А.Воскресенский Н.Ильминскийның ярдәмчесе була һәм аның эшен дәвам итә. Бу хезмәт 244 биттән гыйбарәт, барлыгы 1710 сүзне берләштерә.

Н.П. Остроумовның һәр сүзлегенә аерым тукталып үтик. 1876 нчы елда дөнья күргән сүзлек лексик яктан бик бай. 1892 елда чыккан сүзлектән аермалы буларак, монда искергән, диалектларда гына сакланган, яисә бөтенләй сөйләм теленнән төшеп калган сүзләр күбрәк урын алган.

Алда каралган сүзлекләрдән аермалы буларак, Н.Остроумов хезмәтләре бары тик кирилл графикасында гына язылган, ә сүзләр рус алфавиты тәртибендә урнаштырылган. Н.Остроумов, бу сүзлекләрне төзегәндә, төп максат итеп сүзлекләр ярдәмендә татар халкын христиан дине белән таныштыруны куя. Бу сүзлекләр миссионерлык максатларын тормышка ашыру һәм миссионерлар мәнфәгатен яктырту белән беррәттән, рус халкына татар телен өйрәтүдә зур эш башкаралар. Бу сүзлекләр басылуда, миссионерлар теләгеннән тыш, җәмгыяви ихтыяҗ да зур урынны алып тора.

Н.Остроумовның 1876 нчы елда чыккан хезмәте «сүзлек» дип аталса да, ул үз эченә татар халкы тарихы, татар теле, мөселманнар, миссионерлар турындагы бай материалны ала. Моннан кала, Н.Остроумов сүзләрне фонетик, морфологик яктан яктан анализларга тырыша. Авазлар күчешен, аларның бер-берсенә ничек тәэсир итүен, иренләшү-иренләшмәү, аваз өстәлү, кыскарту үрнәкләрен ачык мисаллар белән күрсәтә. Мәсәлән: сапля – цапля [О., 1876: 21], бу – быу [О., 1876: 61], китер – килтер [О., 1876: 90] һ.б.

Морфологик яктан тикшергәндә, Н.Остроумов күбрәк фигыльләргә игътибар итә. Ләкин фигыльләрне теркәүдә бертөрлелек сакланмый. Мәсәлән: булмыш [О., 1876: 61], әйтештер [О., 1876: 58 с]

Н.Остроумовның 1892 нче елгы сүзлегенең төзелешенә килгәндә, хезмәтнең кереш өлеше бик кыска язылган. Анда бары тик татар хәрефләренең язылыш тәртибе [ **а, һ, ү**] һәм тыныш билгеләре турында гына берникадәр мәгълүмат бирелгән. Ләкин төп өлеше, ягъни сүзлек – лексиканың байлыгы, сөйләшләрнең төрлелеге, искергән сүзләрнең, гарәп-фарсы алынмаларының аз булуы белән аерылып тора.

Н.Остроумовның 1892 нче елда дөнья күргән хезмәтендә түбәндәге аңлатма бирелә:

I. а) сүзләрдә рус хәрефләренең кулланылышы;
б) басым;
в) татар сүзләренең әйтелеше.

II. Татар теленең этимологиясе:

а) сузыкларның яңгыраш закончалыгы;

б) тартыкларның яңгыраш закончалыгы;

в) кушымчалар;

г) исемнәр, сыйфатларның һ.с. зат, сан, заман белән төрләнеше;

д) фигыльләрнең килеш белән төрләнеше;

е) фигыль – сүз төркеме буларак;

ж) җөмләдә сүзләр кулланылышы.

III. а) Рус хәрефләренең тәртибе;

б) русча-татарча сүзлек;

в) туганлык терминнары таблицасы.

Н.Остроумов, сүзлекләрендә диалекталь берәмлекләр, искергән һәм алынма сүзләр бар. Иң күп урынны керәшен сөйләшләренә хас булган диалекталь лексика алып тора.

XIX гасыр татарча-русча сүзлекләрнең барысына да хас булганча, Н.Остроумов хезмәтләрендә дә архаик һәм тарихи сүзләр шактый күп теркәлеп калган. Кайбер берәмлекләргә аңлатма биреп үтик. **Баскак** (бойкий) – тере мәгънәсен белдергән тарихи сүз [О., 1876: 35, О., 1892: 35]. Бу лексик берәмлек Алтын Урда ханының биләмә өлкәсендәге урынбасары, ханга ясак җыеп тапшыручы отряд башлыгы дигәнне белдерә [ТТАС, I: 128]. **Асламчы** –разносчик мәгънәсен белдереп килә [О., 1876: 51, О., 1892: 23]. Иске татар телендә актив кулланылышта йөргән. Татар телендә асу сүзе «файда» мәгънәсендә йөргән, монгол телендә ашы сүзе шулай ук «выгода» мәгънәсен аңлата. Асламчы «асигъ» сүзеннән алынган. Хәзер ул тарихи сүз булып санала. **Жау** – войско «яу» мәгънәсен аңлата [О., 1876: 71, О., 1892: 73] XIX гасырда актив лексика составында йөргән бу берәмлек бүгенге көндә искергән сүзләр рәтендә карала. Ләкин сөйләшләрдә бу сүз төрле мәгънәдә сакланып калган. Мәсәлән, Казан арты, Әтнә сөйләшендә җау – күп кеше булган урынны белдерә [ТТДС, 1993: 568]. Әдәби телдә бу лексик берәмлекнең яу (яулады) – завоевал, заслужил дигән яңа мәгънәләре кулланылышта йөри. Димәк, иске дип каралган сүзләрнең, бүгенге әдәбиятта яңа мәгънә белдереп кулланылышта йөрү очрагы да чагылыш таба. **Инеч** – подкладка [О., 1876: 77, О., 1892:66] сүзленең сөйләшләрдә энеч, энец вариантлары кулланыла. Бу сүз хатын-кызларның һәм ирләр күлмәгенең арка һәм күкрәк турысына тиз тузудан

саклау өчен куелган икенче кат тукыма дигәнне белдерә. Инеч – калын тукымадан тегелгән тышкы кием эченә теккәндә куела торган икенче кат тукыма [Рәхимова, 1994:10]. Абыз – ученый төшенчәсен аңлата [О., 1892: 1], ә Н.Остроумовның 1876 нчы елда чыккан сүзлегендә бу сүз теркәлмәгән. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә абыз – искергән лексика дип карала [ТТАС, I: 12]. Хәзерге телдә абыз – дини сүзләр төркеменә керә. Абыстай сүзенең тамыры шулай ук, абыз сүзеннән гыйбарәт. Димәк, абыстай укымышлы хатын, гадәттә, мулла хатыны. Татартелендә һәм сөйләшләрдә татар абызы, абыз бабай, абызбикә, абыз җиңги дигән сүзләр бар.

**Адарын** «дать обед богу» дип тәрҗемә ителә [О., 1892: 5]. Аңлатмалы сүзлектә адарын сүзе «вәгъдә бирү, нәзер әйтү» мәгънәсендә йөргән искергән сүз дип күрсәтелә [ТТАС, I: 19]. Бу лексик берәмлек казан арты, тау ягы, керәшен сөйләшләрендә «нәзер әйтү» дигән мәгънәдә дә сакланган [ТТДС, 1969: 22]. Төрле бәла-каза һәм авырулардан нәзер әйтеп тә котылып калып була дип уйлаганнар. Күбрәк изге урыннарга, мәсәлән «чәчәуникка» (часовня) әйбер элү, «келәүле кое»га акча салу һ.б. файда бирә дип ышанганнар [Баязитова, 1997: 179]. **Атау** сүзе – остров, утрау мәгънәсен белдерә [О., 1876: 32, О., 1892: 24]. Атау сүзе XIX гасырда актив кулланылган булга карамастан, хәзерге әдәби телдә бу лексик берәмлек искергән сүзләр рәтенә күчкән [ТТАС, I: 82]. Атау сүзе оренбург, сыргач, касыйм сөйләшләрендә сакланган [ТТДС, 1969: 92], ә әдәби телдә бу сүзнең утрау варианты еш кулланыла. **Кырлач** – месяц, ай мәгънәсен аңлата [О., 1876: 96, О., 1892: 13]. Хәзерге әдәби телдә кырлач берәмлеге искергән сүз дип исәпләнә, ләкин минзәлә, керәшен сөйләшләрендә бу сүз саклана һәм ул суык вакыт, каты суыклар ае мәгънәсен белдереп килә [ТТДС, 1969: 219]. Аңлатмалы сүзлектә исә кырлач сүзенә «Кышның иң салкын аеннан гыйбарәт сезон (декабрь, январь)» дигән аңлатма бирелә [ТТАС, II: 227]. Армуд сүзе груша мәгънәсен белдерә [О., 1876: 5]. XX гасырның 80 нче елларына кадәр бу сүз онытылган лексика составында карала иде. Ләкин 90 нчы елларда бу лексик берәмлек телгә, матур әдәбиятка кире кайтты. **Котлы** – счастливый төшенчәсен белдерә [О., 1876: 92]. Хәзерге телдә бу сүз искергән лексика составына керә. Кот/котлы XVII-XIX гасырларда бәхет, нур, яшь, матурлык, уңыш мәгънәләрен аңлаткан [ТТАС, II: 168]. Котлы сүзенең «бәхетле» төшенчәсен белдергән мәгънәсе тагын да киңәю нәтиҗәсендә, яхшылык, теләү, тәбрик мәгънәсендә йөргән. Җан, тереклек, исән-иминлек, яхшылык, бәхет, шатлык, байлык рәвешендә борынгы төрки телдә һәм иске татар телендә Кутлук (хатын кыз исеме),

Котлыкыя исемнәре кулланылган [Саттаров, 1990: 56]. **Тимпан** – древний музыкальный инструмент [О., 1876: 122, О., 1892: 196]. Хәзерге вакытта тимпан сүзе әдәби телдә дә, диалектларда да кулланылмый. Аңлатмалы сүзлектә тимпан махсус термин итеп карала, «бизәкле фотон, бизәкле тышкы кашага» дигән мәгънәне белдерә [ТТАС, III: 100]. Атланма –мерить шагом [О., 1876: 92, О., 1892: 24] сүзе хәзерге әдәби телдә дә, диалектларда да кулланылмый. Сүзнең нигезендә атлау фигыле ята һәм адымлап үлчәү дигән мәгънә белдерә [ТТАС, I: 85]. Бутым – водяной «су анасы» мәгънәсен белдерә [О., 1876: 61 ]. Хәзерге әдәби телдә бу сүз онытылган, ләкин күп кенә сөйләшләрдә, төрле фонетик вариантларда, үзенең мәгънәсен саклый. Мәсәлән, керәшен татарлары **бутыш**, марилар **вотым, водаж, вадаш, водош**, чуашлар **вуташ, воташ, вутош** дип өй хуҗасы, урман хуҗасы, су анасы, җир анасы кебек мифологик образларны атыйлар. Бу лексик берәмлекнең борынгы варианты (оташ, утош/өташ/үтәш)борынгы төрки телдә сакланган [Ахмятьянов, 1981: 21].

Шулай ук борым – моток [О., 1876: 60 ], чубагач – чепь [О., 1876: 135 , О., 1892:229], тоң – изморозь [О., 1876: 123], туман – большое скопление людей [О., 1876:125, О., 1892: 205], кертляк – развратная женщина [О., 1876: 95, О., 1892: 143], кыярчы – продавец огурцов [О., 1876: 97 , О., 1892: 138 ], кукар – плотник [О., 1876: 93 , О., 1892: 130 ], жомган – худой [О., 1892: 68,О., 1876:69], алымсак – взяточник [О., 1876: 48, О., 1892: 11], сулым – снежный [О., 1876: 115, О., 1892: 179], жарка – бедный [О., 1876: 70], затташ – соотечественник [О., 1876: 78, О., 1892: 91], тачик – близорукий [О., 1876: 170, О., 1892: 191], жаксар – дремать [О., 1876: 74, О., 1892: 79], мылтыкчы – охотник [О., 1876:101, О., 1892: 189], эләгям – выведовать [О., 1876: 139, О., 1892: 242] сүзләре хәзерге әдәби телдә кулланылышта йөрми һәм сүзлек составыннан төшеп калган.

Н.Остроумов сүзлеге алдагы сүзлекләрдән гадилеге, җиңеллеге белән аерылып тора. Сүзлек, нигездә, халыкның җанлы сөйләменә нигезләнә. Шул сәбәпле, сүзлектә диалекталь берәмлекләр шактый зур урын алып тора.

Татар теленең бай тарихи язма әдәбиятында сүзләрнең искергән мәгънәләрен күп табарга мөмкин. Безнең телебездә югалган мәгънәләр кайбер башка төрки телләрдә яисә диалектларда, сөйләшләрдә яши. Н.Остроумов сүзлекләреннән иллегә якын искергән лексик берәмлекләрне аерып тикшердек. Бу сүзләр иҗтимагый-тарихи шартларның үсүе һәм

үзгәрүе нәтиҗәсендә актив кулланылыштан төшеп калганнар һәм шул чорга караган сүзлекләрдә генә теркәлгәннәр.

## К. Насыйриның «Татарча-русча лөгать китабы»[1]



“К. Насыйриның «Татарча-русча лөгать китабы» 1859 нчы елда ук төзелә башлый. Ләкин басылып чыгуы ни өчендер соңарган” [В. Хангилдин, 1948: 80]. Бу сүзлекнең дөнья күрүендә китап сәүдәсе белән шөгыльләнүче Фәтхулла Хәмидулла улы Амашевның ярдәме зур була. Китап 1878 нче елда басылып чыга. Сүзлек, иң беренче чиратта, ике максатны күз уңында тота: ул татарларга рус теле, русларга татар телен өйрәтүдә куллану өчен әһәмиятле гамәли кулланма хезмәтен үти. Күләме – 120 бит һәм ул үз эченә 2923 сүз ала. Хәзерге чорда галимнәр һәм

1 К.Насыйри сүзлекләренә тасвирлама анализ бирү белән генә чикләнәбез, чөнки аларга лингвистик анализ Г.Г. Насырованың кандидатлык диссертациясендә бирелә.

укытучы-практиклар әйтүенчә, 1500-3000 сүз, теге яки бу телдә иркен аралашу өчен, җитәрлек лексик база булып санала. К. Насыйри, үзенең укыту тәҗрибәсеннән чыгып, әлеге фикерне инде 140 ел элек дәлилләгән була. «Татарча-русча лөгать»нең керешендә К. Насыйри татар Һәм рус телләре фонетикасы турында кыскача мәгълүмат бирә. Кереш өлештә «Рус азбукасында хәрәкәткә йөри торган хәрефләр», «Слоглар», «Ударение бәянында» дигән бүлекләр булу шул турыда сөйли. «Урысның берничә төрле гласный хәрефләре өчен бары үземезнең шул өч хәрефемезне истигъмаль кылмак кирәк, әмма бу мөмкин түгел», – ди К. Насыйри. Рус телендә хәрефләрнең ике төрле, ягъни баш (зур) һәм юл (вак) хәрефләре булуын, сулдан-уңга язылуын да искәртеп үтә, ике телдә дә иҗек һәм басымның уртак я үзенчәлекле якларын билгели. Татар телендә басымның, гадәттә, сүз ахырында, ә рус телендә төрле иҗектә килә алуын, басымга карап мәгънә үзгәрүен ассызыклый: «Аларның бәгъзе кәлимәләре бар, бер рәвешле языла, әмма удармиесенә карап, мәгънәгә даләләт кыйладыр. Мондаен хосусларда алар ударение галәмәтен куймакны зарур күрәләр. Мәсәлән: газаб – мука, он – мука». Керешнең соңгы өлешендә «Урыс хәрефләренең кайсы хәрефләр бәрабәренә әйтелүе» дип, алфавит тәкъдим ителә. Автор укучыга сүзлекнең кереш өлеше белән танышырга һәм анда әйтелгән фикерләргә игътибар итәргә кирәклеген искәртә: «Бу лөгать китабындан бер файда хасил итим дигән адәм ошбу безнең язылмыш мөкаддимәмезне мөтәләга кыйлып (укып), үз галәмәтләренең вадигын (куелышын) белсеннәр». Күргәнебезчә, галим тарафыннан бик акыллы һәм үтемле кереш сүз язылган. Ул татар телен өйрәнергә теләүчеләргә бик файдалы методик ярдәм хезмәтен үти.


ТАТАРСКАЯ АЗБУКА

буквы въ связи съ другими буквами

абзаръ, хлѣвъ

ата, отецъ

атмакъ, бросать

ачмакъ, открыть

ачу, гнѣвъ

ачы, кислый

ачу-тамъ, квасцы

К.Насыйри сүзлегенең беренче бите

Бу сүзлек үзенең төзелеш принциплары белән хәзерге сүзлекләргә бик якын. Анда сүзләр алфавит тәртибендә урнашкан. Әлеге тәртип сүзнең беренче хәрефенә генә түгел, аннан соң килгәннәренә дә карый. Сүзләр дүрт баганага бүленеп бирелә: беренче баганада гарәп алфавиты тәртибендә, гарәп графикасында татарча сүз бирелә; икенчесендә – сүзнең рус хәрефләре белән транслитерациясе, ягъни рус хәрефләре белән язылган татар сүзе; өченче баганада – сүзнең русчага тәрҗемәсе; дүртенче баганада рус сүзе гарәп хәрефләре белән күрсәтелә. Бу алым XIX гасырда киң кулланылышта була. Шул чорда дөнья күргән татар теле үзөйрәткечләрендә бу ысулның чагылышын күрәбез. Бу алымны кулланып, автор тел өйрәнүчеләр өчен ике телнең фонетик мөмкинлекләрен, әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләрен бирергә тырышкан. Әлбәттә, бу алым телне үзләштерергә, орфографик нормаларны аңларга һәм сакларга ярдәм иткән.

## К. Насыйриның «Русча-татарча» сүзлеге

К. Насыйриның 1892 нче елда дөнья күргән русча-татарча сүзлеге XIX гасырның икенче яртысында төзелгән сүзлекләр арасында аеруча күренекле лексикографик хезмәтләрдән санала. Сүзлекнең тулы атамасы – «Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как термины». Ул 264 биттән гыйбарәт һәм иң күләмле сүзлекләрнең берсе буларак билгеле.


ПОЛНЫЙ
РУССКО-ТАТАРСКІЙ
СЛОВАРЬ,
съ
ДОПОЛНЕНІЕМЪ ИЗЪ ИНОСТРАННЫХЪ СЛОВЪ,
УПОТРЕБЛЯЕМЫХЪ ВЪ РУССКОМЪ ЯЗЫКѢ
КАКЪ НАУЧНЫЕ ТЕРМЕНА,
Составилъ
Абдулъ-Каюмъ бинъ Абду-Н-насыри-Н-насыри-и-ль-Казани.

روس حروف هجاسی اوزه مرتب
لغت کتابی
یانکا مخترعات جملەسندن بولوب لسانمز اوزه ترجمه قیلنمشدر
کوب مادەلرده
روس کلمەلرینک معناسی تفصیلا بیان قیلنوب حرف جرلی فعللرده ودخی هر بر حرف جرننک موضوع له معنالاری تفصیلا بیان قیلندی ـ ینه روس کلمەلرندن ما عدا روس تلنده مستعمل بولغوچی اجنبی لغتلر که روس تلننك فنون شتی اصطلاحلاری کوبراك اجنبی لغتلردر ذکر قیلندی ـ تصنیف قیلغوچی عبدالقیوم بن عبدالناصر الناصری

«К. Насыйри бу сүзлекне турыдан-туры татарларга рус теле өйрәтү өчен белешмәлек, кулланма итеп төзегән» [В. Хангилдин, 1948: 82]. «Русча өйрәнүчеләргә бераз нәсыйхәт» исемле кереш сүзендә автор бу хезмәтенең 35 еллык эш тәҗрибәсе икәнлеген әйтә, «бу вакытка кадәр бездә тел өйрәнү юк иде», – ди. Рус телен өйрәнүгә карата киңәшләр бирә, дүрт таләпне шарт итеп куя: 1. Аерым сүзләрне белү. Аларны, җиләк җыйганда, үзең дә сизмәстән, чиләк тутырган шикелле, әкрен-әкрен үзләштерү. 2. Авазларның

әйтелешен белү. 3. Өйрәнелә торган телнең морфология һәм синтаксисын белү. 4. Рус префиксларының үзенчәлекләрен исәпкә алу. «Телне конвертларда адрес язу өчен генә өйрәнергә ярамый, чөнки мондый максаттан чыгып өйрәнүчеләр бервакытта да теләкләренә ирешә алмыйлар», – ди К. Насыйри [Насыри, 1892: 2] һәм телне өйрәнүнең чагыштырма метод базасына корылган булырга тиешлеген дә әйтеп уза. Автор тарафыннан бирелгән бу тәкъдим-киңәшләр бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырый.



Сүзлеккә шул чор рус әдәби телендә кулланылган рус сүзләре, шулай ук алынмалар теркәлгән. Бу турыда автор үзе хезмәтенең титул битендә дә әйтә: «Рус кәлимәләренең мәгънәсе тәфсыйлән бәян кылынып, хәрфе җәрле (предлог, приставкалы) фигыльләр дә, вә дәхи һәрбер хәрфе җәрнең мәүзугы ләһ (үзенә хас) мәгънәләре дә тәфсыйлән бәян кылынды. Янә рус кәлимәләреннән башка рус телендә мөстәгъмәл булучы әҗнәби лөгатьләр (чит тел сүзләре), рус телендәге фөнүне шәтта истыйлахлары (төрле фәннәргә караган атамалар) – күбрәк чит тел сүзләредер, зикер кылынды»[Насыри, 1892: 2].

Сүзлекнең төзелеш методикасына килгәндә, автор үз хезмәтендә төрле алымнарны куллана. Сүзләрне тәрҗемә иткәндә, туры тәрҗемә, синонимнар белән тәрҗемә итү һәм аңлату юлы белән сүзләргә шәрехләү алымы киң кулланылган. Кайбер урыннарда сүзлек аңлатмалы сүзлеккә охшап китә. Әлбәттә, сүзләрнең эквивалент тәрҗемәсенә меңләгән мисаллар китерергә мөмкин, мәсәлән, аистъ – له لك لقلق [с. 5], барсъ -قبلاق [с.7] һ.б.

Күп очракларда эквивалент тәрҗемә белән беррәттән синонимнар белән тәрҗемә алымы килеп керә. Синонимик рәттә татар сүзләре белән бергә гарәп-фарсы алынмалары да теркәлеп бара. Моңа мисал итеп түбәндәге сүзләрне күрсәтә алабыз: армия –عسكر لشكر [с. 6], арбузъ – بطيخ خفر خربو زه قار بو ز [с. 6]

Аңлату юлы белән бирелгән берәмлекләр сүзлеккә теркәлгән рус я европа сүзләрен татар укучысына тирәнтен аңлау мөмкинлеген бирә. Мәсәлән, аллея – اعاج ارا سنداعي يءللار [с. 5], ампутация - ادمنهرنك بر اعضاسى كيسوب الؤ[с. 5], глазурь – تاش صاوث وحولماق كبك نهرسه كرننك طشندا بىا لا سيمان نرسهدر [с. 30], акробатъ –ارقان اوستونده اوينا و جى [с. 5], актер – ثماشا حانه ده اوينا وحي [с. 5]

Үзенчәлекле терминнар, татар теле өчен чит атамалар гарәп-фарсы алынмалары я аңлату юлы белән тәрҗемә ителәләр. Кайбер очракларда ике юл бергә кушыла. Мәсәлән, атом – ذرب جزئ لا يثجزي, барбарис عببر نار يس بر باريس, архитекторمهندس معمر

К.Насыйри сүзлегенң тагын бер үзенчәлекле, филологик кыйммәткә ия ягы бар. Автор механик тәрҗемә белән генә шөгыльләнми, ә татар телненең һәр үзенчәлеген чагылдырып барырга тырыша. Рус теле белән дә параллельләр үткәрә. Мәсәлән, брат - بثطوعان اعا اعا ي كي ايني [с.11], сүздән соң бу берәмлек төрле сүзтезмә составында бирелә: брат старший – اعا, брат младший – اني [с.11] . Рус телендәге «ваш» алмашлыгы татар теленә ике варианта «сезнең» һәм «сезнеке» дип тәрҗемә ителә. К.Насыйри ике вариантны да терки һәм сүзтезмә составында беркетеп куя: ваш – سزنينك - سزنيكي , соңыннан ваш брат –اغانكز дигән сүзтезмә беләнраслар куя [с.11]

Галим сыйфатларны тәрҗемә иткәндә дә кызыклы юллар белән эш итә. Башта К.Насыйри сыйфатның төгәл эквивалентын күрсәтә. Соңыннан

бу сүзне контекстта бирә һәм төгәл мәгънәне бары тик текстта гына аңлап була дип искәртә. Мәсәлән, конный اطلي [с.72], морской - دینکیزده کي [с.79], денежный – اقچالي[с. 35], больной - اورولي [с. 10], золотой الطونلي [с. 24.].

К.Насыйри рус телендәге җенес категориясенә бик нык игътибар итә. Рус сүзе гарәп алынмасы белән тәрҗемә ителгәндә, автор гарәп телендәге төрле җенес исемнәрен куллана. Мәсәлән, возлюбленный – معسوق, возлюбленная – معسقوقة [с. 22]. Кайбер очракта җәя эчендә аңлатма бирелә: «плясун» – بيوحي (мозәккәр) һәм «плясунья» – بيوحي( мөэннәс) [с.148]

Фигыльләрне тәрҗемә иткәндә К.Насыйри аеруча зур төгәллек күрсәтә. Бигрәк тә вид категориясе игътибар үзәгенә куела: закончить – بثورمه ك , заканчитвать ثمام بولماق [с.49], разбивать –واقلاماق وثماق , разбить – صندرماق واشماق [с.166], разглядывать – اطرافقه نظر صالماق разглядеть – کوز بلن بورثب قاراماق [с. 167]

«Русча-татарча» сүзлеккә 18 меңгә якын берәмлек алынган. Лөгатьлектә сүзләр рус алфавиты тәртибендә урнаштырылып, шул чор орфографиясе буенча эшләнгән. Татар телендәге сүзләр гарәп графикасында бирелгән. Китапның соңгы битендә һәр хәреф буенча сүзләр башланган бит саны күрсәтелгән таблица урнаштырылган. Шулай итеп К. Насыйри сүзлекнең техник төзелешен дә заманындагы алдынгы үрнәкләр нигезендә, рус сүзлекләре төзелеше кебек формалаштырган.

«Русча-татарча сүзлек»нең ахырында К. Насыйри «Әлфаз әҗнәбия», ягъни «Чит сүзләр» дигән баш астында рус теленә башка телләрдән кергән сүзләр Һәм терминнар сүзлекчәсе урнаштыра. Биредә *артиллерия, антропология, барометр, бисквит, вентилятор, дидактика, консул, ланцет, манускрипт, ландшафт, микрография, неврология, орфография, планета, рейд, реформа, риторика, система, текст, темперамент, хронография, фотография, эксперт, этикет, эфир, цилиндр, юбиляр* кебек 1700 гә якын иҗтимагый-сәяси, фәнни-техник терминнар урын ала. Рус телендәге бу алынмаларга татар телендә аңлатмалар бирү, тәрҗемә итү сүзлекнең кыйммәтен тагын да арттыра һәм бу күренеш үз чоры өчен зур яңалык булып тора.

1939 нчы елда «Совет әдәбияты» журналында дөнья күргән бер мәкаләдә автор М. Гали, сүзлеккә тискәре бәя биреп: «Каюм Насыйриның русча-татарча сүзлегенең эчтәлеге хәзерге чор өчен шулкадәр ярлы, ул хәзерге чорда газета, журнал һәм әдәбият укып баручы эшче һәм колхозчы крестьяннарның кирәген дә үтәрлек түгел», – дип язып чыга [М. Гали, 1939: 82-83]. Сүзлектә радио, трактор, комбайн, поезд кебек яңа сүзләр табып булмауда, булганнарын да көлкеле мәгънәдә бирүдә, бер сүз белән аңлатырлык кәлимәләрне озын җөмләләр белән аңлатуда гаепли.

Әмма үз чорында К. Насыйриның бу сүзлеге теркәлгән сүзләренең саны һәм төрлелеге ягыннан, сүзләрне тәрҗемә итүдә кулланган алымнар һәм ысуллары белән башкалардан аерылып тора. Рус һәм татар телләрен чагыштырып бирү, аларның үзенчәлекләрен күрсәтү рус телен өйрәнүчеләргә ярдәм итә. Бу сүзлек үз эченә кирәкле белешмәләрне алган мөһим лексикографик хезмәт була.

## Миссионерлар җәмгыяте сүзлекләре

XIX гасырда төрки халыкларның телләрен, фольклорын һәм этнографиясен өйрәнүдә православ миссионерлар зур роль уйнаганнар. Христиан рухани уку йортларының татар теле укытучылары да әлеге хәрәкәт тарафдарлары булганнар. Алар камил татар теле дип керәшен сөйләшләрен санаганнар һәм шул шивәләрдә дәрес биргәннәр, татар телен шул җирлектә өйрәткәннәр.

Православ миссионерлар татар лексикографиясе өлкәсендә дә зур эз калдырганнар. Миссионерлар җәмгыяте төзегән «Краткий татарско – русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом» сүзлеге биш тапкыр басылып чыга [Казань, 1880. – 55 с.; 1882. – 55 с.; 1886. – 96 с.; 1888. – 96 с.; 1891. – 96 с.], ләкин алар өйрәнелмәгән, теркәлгән лексик берәмлекләр тикшерелмәгән.



В-30625 Проверено 1949 г. РЕКАТ.
A.T.S.S.R.-T.M.X.K. MƏRKƏZ QILMI həm PUBLIKA KƏTPXANƏSE
Центральная Научная и Публичная Библиотека
Инв. В-30625
г. Казань—Qazan

КРАТКІЙ
ТАТАРСКО-РУССКІЙ
СЛОВАРЬ
съ прибавленіемъ
НѢКОТОРЫХЪ СЛАВЯНСКИХЪ СЛОВЪ
СЪ ТАТАРСКИМЪ ПЕРЕВОДОМЪ.

ИЗДАНІЕ
Православнаго Миссіонерскаго Общества.

КАЗАНЬ.
Типогр. М. А. Гладышевой, Николаев. пл., д. Курманаева;
1880.

Миссионерлар сүзлегенең тышлыгы

Сүзлекнең ике басмасы М.А.Гладышева, ә 1886 нче елда чыккан басмасы М.А.Чиркова типографиясендә басыла, ә соңгы ике басманың типографиясе күрсәтелми.

Алда әйтелгәнчә, сүзлекнең биш басмасы дөнья күрә. Аларның форматы – 10 х 17,5, структур яктан тематик принципка нигезләнеп төзелгән. Өч басма бер-берсеннән аерылмый, дүртенче, бишенче басмаларның күләме зуррак. Авторлар соңгы басмаларга яңа сүзләр, яңа тематик төркемнәр, грамматик материал өстиләр.


КРАТКІЙ
ТАРСКО-РУССКІЙ
И
СЛАВЯНО-ТАТАРСКІЙ
СЛОВАРЬ
съ прибавленіемъ
ОСНОВАНІЙ РУССКОЙ ГРАММАТИКИ.

ИЗДАНІЕ ЧЕТВЕРТОЕ
Православнаго Миссіонерскаго Общества.

КАЗАНЬ
Типографія М. А. Чирковой.
1888

«Краткій татарско-русскій словарь съ прибавленіемъ некоторыхъ славянскихъ словъ съ татарскимъ переводомъ» дип аталган сүзлеккә киңрәк тукталырбыз, анда теркәлгән сүзләргә лингвистик күзәтү ясарбыз.

Сүзлек Казанда М.А.Гладышева типографиясендә 1880 нче елда басылып чыга. 55 биттән тора. Сүзлек тематик принципка нигезләнеп төзелгән: барлыгы 43 төркем бар. Анда 983 сүз теркәлгән.

Төркемнәрнең исемнәре татарча һәм русча бирелгән: *ишек* **алдындагы каралдылар** – строенія на дворе, **ашамлыклар** – съедобное, **жорт кошлары** – домашнія прицы, **сугыш кораллары** – оружія, **кейемняр** – одежды, **агач атлары** – названія деревьевъ, **донья жаклары** – страны света, **багыт** – время, **акча исабе** – денежный счетъ, **улчяуляр** – весы, **буйга улчяу** – меры

Миссионерлар сүзлегенең титул бите

протяженія, **сыйык нястяне улчяу** – меры жидкости, **ой** – домъ, **ой эчендяге настяляр** – вещи въ доме, **жимешляр** – плоды, **гомбяляр**–

грибы, **куренмей торган нястяляр** – предметы отвлеченные, **уйынчыклар** – игрушки, **чиркяу айберляре** – церковныя вещи, **укыту нястяляре** – учебныя вещи, **тешлей торган ыуак жяннекляр** – насекомыя, **кейекляр** – звери, **жирянгеч жяннекляр** – гады, **жорт терлекларе** – домашнія животныя, **эчемнекляр** – напитки, **кеше тяненен саннары** – состав человеческаго тела, **ындырдагы нястяляр** – вещи на гумне, **кыр кошлары** – дикія птица, **урман кошлары** – лесныя птица, **ауадагы нястяляр** – предметы небесные, **бакча** – огородъ, **мунча** – баня, **жир** – земля, **тосляр** – цвета, **балчык эчендяге нярсяляр** – металлы, **ташлар** – камни, **нястянен ничеклеге** – качества, **ден сюзляре** – слова веры, **балта остасынын кораллары** – плотничьи инструменты, **тимерче** – кузнецъ, **ашлыклар** – хлеба, **улямняр** – растенія, **кыйлану сюзляре** – глаголы. Сүзләрнең язылышы нәкъ сүзлектәгечә бирелде. Бу сүзлекләрне төзүчеләр, Казан университеты профессоры миссионер Николай Ильминский алфавитын кулланып эш иткәннәр.

Без караган барлык сүзлекләрдәге кебек үк, бу хезмәттә теркәлгән берәмлекләрдә дә сүз башы позициясендә җ–й параллель кулланыла. Бу хакта тюркологиядә төрле фикерләр бар. М.Кашгари үзенең атаклы сүзлегендә: «Угызлар һәм кыпчаклар **й** белән башланган исем һәм фигыльләренең баш хәрефен әлифкә яки **җ** га әйләндерәләр»,– дип яза. В. Радлов, В. Богородицкий, Л. Җәләй **й** авазының киң кулланылуын кыпчак телләре өчен хас дип аңлаталар [Хаков, 2003: 114].

Татар әдәби теле төрле кабилә телләре үзенчәлекләре җирлегендә формалашкан. Аерым диалектларда **җ**-ләштерү һәм **й**-ләштерү күренешенең булуы шуны раслый. Бу күренеш без тикшергән сүзлектә дә зур урын алып тора. Сүз башы позициясендә **й - җ** ның нормалашып җитмәвен, параллель кулланылуын сүзлектән алынган мисаллар ачык күрсәтә: **жорт** [с.1], **жядря** [с.3], **жепяк** с.6], **жаулык** [с.6], **жапырак** [с.7], **жомочка** [с.7], **жыл** [с.8], **жылан** [с.18], **жоряк** [с.20], **жяшен** [с.23] һ.б. Сүзлектә **й** хәрефенә башланган бер сүз дә юк. Моның бер сәбәбе итеп авторларның Казан арты керәшен сөйләшләренә хас булган фонетик вариантларны гына теркәвен ассызыклап әйтергә кирәк. Ә миссионер авторлар, аңлы рәвештә, татар теле сүзлекләренә керәшерн татарлары сөйләменә хас булган фонетик вариантларны теркәгәннәр.

Сүзлектә теркәлгән сүзләрне хәзерге тел берәмлекләре белән чагыштырып караганда, төрле аваз тәңгәллекләрен күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, **п – ф** тәңгәллеге: **жапрак** – яфрак [с.7], **пел** – фил [с.17], **керпек** – керфек [с.20], пяриштя – фәрештә [с.28]; б–**w** тәңгәллеге: **багыт** – вакыт [с.8], **ч–с** тәңгәллеге: **чишямбе** – сишәмбе [с.9], **чыуалчан** – суалчан [с.18], **б – ф** тәңгәллеге: **шкаб** – шкаф [с.12], **к– х** тәңгәллеге: **канжар** – хәнҗәр [с.5], **ж – з** тәңгәллеге: **жирек** – зирек [с.7], **н – л** тәңгәллеге: **жондоз** – йолдыз [с.23].

Сузыклар өлкәсендә ирен гармониясенең тулысынча бирелүе дә тел өйрәнүчеләр өчен кулайлык булып санала: *сő̆т, сő̆т ő̆стő̆, сő̆нгő̆, бő̆рő̆, тő̆шлő̆к, бő̆гő̆н, ő̆лő̆ш, ő̆рлő̆к, шоморот, борон, болот; сойкомне*. Шулай ук тартык авазларның үзара ярашуын сүзлектә чагылдыру тел өйрәнүчеләр алдына куелган максатларны тормышка ашыруда шактый зур роль уйнагандыр: *тямне, белемне, белемнек, ашамнык* һ.б.

Сүз башына сузык аваз өстәлү – протеза күренеше сүзлектәге кайбер берәмлекләрдә генә чагылыш тапкан. Гадәттә, рус алынмаларына хас бу закончалык гарәп теленнән кергән сүзләрдә күзәтелә: эзяр – пояс [с.6] , эшям – свечка [с.12], эшямдял – подсвечникъ [с.12].

Тематик төркемнәрдә теркәлгән сүзләр – телдә иң еш кулланыла торган, иң актив берәмлекләр. Алар хәзерге татар телендә дә бернинди үзгәрешсез кулланыла һәм телнең төп лексик базасын тәшкил итә. Мәсәлән*, койма, аш, токмач, каз, тауык, кылыч, тун, чалбар, ботак, миляш, тал,чыршы, ай, атна, ирта, идян, такта,* һ.б.

Сүзлектә төрле сөйләшләргә хас булган диалекталь берәмлекләр дә очрый, ләкин алар күп түгел: **бистяр** – полотенце [с.6] [ТТДС,1969: 88], **туйра** – дубнякъ [с.7] [ТТДС,1969:424], **эт бороно** – шиповникъ [с.8] [ТТДС, 1969:609], **княген** – вчера [с.9] [ТТДС, 1969:238], **тустаган** – стаканъ [с.10] [ТТДС, 1969:429], **айбагыр** – подсолнечникъ [с.23] [ТТДС, 1969:27], **гердя** – бклка [с.4] [ТТДС, 1969:117], **шяйке** – шайка [с.24] [ТТДС, 1969:520], **ачыткы** – квасъ [с.19] [ТТДС, 1969:57], **чем** – ветвь [с.8] [ТТДС, 1969:480].

Сүзлектә урын алган лексик берәмлекләр арасында рус алынмалары шактый күп. Аларның күбесе татар теленең фонетик закончалыкларына буйсынган, телдә эквиваленты булмаган, төрле реалийларны, гореф-гадәтләрне белдергән берәмлекләр. Мәсәлән, **клят** – клеть [с.3], **прянник** – пряникъ [ с.4], **эштей** – щи [с.4], **буряня** – бревно [с. 7], **пот** – пудъ [с.9], **биршук** – вершокъ [с.10], **скамья** – скамейка [с.11], **самауыр** – самоваръ [с. 11], **укыуат** – ухватъ [с.12], **шкаб** – шкафъ [с.12], **тетрадь** – тетрадь [с.16], **грифел** – грифель [с. 16], **наливка** – наливка [с.19], **рум** – ромъ [с.19], **лачынка** – носилки [с.21], **салам** – солома [с. 21], **скерт** – скирдъ [с.21], **упунка** – опенки [с.13], **струг** – нastругъ [с.29], **клящя** – клещи [с.29], **пичеркя** – печурка [с.11], **пудаука** – пудовка [с.10], **арган** – орган [с.14]. Бары тетрадь сүзенең татар телендә фарсы теленнән кергән *дәфтәр* дигән эквиваленты бар, ләкин авторлар аны күрсәтмиләр.

Сүзлек хәзерге татар әдәби теленә бик якын. Сүзлектә теркәлгән берничә берәмлек кенә онытылган, кулланылыштан төшеп калган. Мисал итеп **сага** – мячъ[с.14] – хәз. тат. телендә – туп, **шакмак** – шашка [с. 14] – хәз. тат. телендә – шашка; **канат сабы** – ручка [с.16] – хәз. тат. телендә – каләм, ручка; **бурлы** – бурый [с.25] – хәз. тат. телендә юк. **Бурлы** сүзе татар телендә сакланмаган. Ләкин XX йөз башы әдәбиятында бу берәмлекнең телдә куллануын очратырга була. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясендә «Туры бурлы булып туган кайбер колыннарның сабыйлык йоны бераздан соң, җир өстенә сибелгән ак чәчәкләр яисә ак йөзгә чыккан матур кара миңнәр кебек, тәңкә-тәңкә булып чуарлана башлый» дигән җөмлә бар. Рус телендә бурый дигән сыйфат бар һәм, галимнәр әйтүенчә, бур дигән сүз рус теленә төрки телләрдән кергән, ә төрки телләрдә ул җирән-кызыл дигән мәгънәдә кулланылган. Килеп чыгышы белән фарсы телендәге bor – коңгырт-кызыл дигән сүзгә барып тоташа. [Шанский , 64].

Сүзлектә этнографик лексикага караган **мялячек** – чохолъ, наколка [с.6], **муйын жака** – нашейникъ [с. 6], **татар атнасы** – пятница [с.9], **кече атна** – четвергъ [с.9] кебек сүзләр дә бар. Бу сүзләрнең барысы да керәшен сөйләшләренә һәм этнографиясенә карый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, бу сүзлек тел өйрәнүчеләр өчен бик уңайлы булган. Чөнки авторлар икенче телгә өйрәтүнең бөтен нечкәлекләрен белеп эш иткәннәр. Көндәлек аралашу өчен кирәкле иң актив берәмлекләрне генә туплану, аларны тематик төркемнәргә аерып бирү, телгә хас фонетик закончалыкларын язуда чагылдырырга тырышу, тәрҗемә иткәндә, нигездә, эквивалентлар белән эшләү аларның тәҗрибәле, оста лексикограф булулары турында сөйли.

## Шиһабетдин Габделгазиз сүзлеге

Үз чорының талантлы язучысы, тәрҗемәчесе, сүзлекләр, дәреслекләр, үзөйрәткечләр авторы Шиһабетдин Рәхмәтуллинның тормыш юлы һәм эшчәнлеге өйрәнелмәгән диярлек. Аның яшәгән еллары да билгесез. Ул төрле чыганакларда төрлечә күрсәтелә. Архивта да төгәл мәгълүматлар очрамады. 1888 нче елның январенда язылган крестьяннар прошениесендә аңа 30 яшь дип бирелгән. [ҮАФ, 2ф. , 2 тас. , 3423 эш]. Моннан чыгып, аның туган елын 1858 нче ел дип фаразларга мөмкин.

Шиһабетдин Габделгазиз улы Рәхмәтуллин Зөя кантоны Имәнлебаш авылында [хәзерге Кайбыч районы Кече Урсак] мулла гаиләсендә туган. Казанда Апанай мәдрәсәсендә укый. Хәрби хезмәттә була. Шул чорда русча өйрәнә, писарь булып хезмәт итә [Валидов, 1923:43]. Унтер-офицер дәрәҗәсен ала. Архив материалларыннан күренгәнчә, хезмәтен тәмамлагач, ул Сембер губернасы Буа өязе Иске Суыксу волосте Яңа Суыксу крестьяннар җәмгыятендә писарь булып тора [ ҮАФ, 2ф. , 2тас. , 3423 эш].

Әтисе Габделгазиз Рәхмәтуллин 1863-1907нче елларда Кече Урсак һәм Чукры Олан авылларында мулла була. Ул имам-хатыйп һәм мөгаллим дәрәҗәсен алган.

Кече Урсак мәхәлләсенең икенче мулласы Әхмәт Бикмәмәтов 1886нчы елда үлә. Авыл кешеләре аның урынына Шиһабетдинне куюларын сорап өязнең полиция идарәсенә хат язалар. Бераз

каршылыклар белән аны Кече Урсак һәм Чукры Олан мәхәләсенә мулла итеп куялар. Каршылыкның сәбәбе – авылда крестьяннар аз, шуңа күрә икенче мулла кирәк түгел, диләр. Бу вакытта аның этисе дә шунда эшли.

Архивта Ш. Рәхмәтуллинның Мөселманнарның Оренбургтагы Диния нәзарәте биргән белешмәсе бар. Анда Шиһабетдинне «имам-җәмигъ, хатыйп, мөдәррис булырга сәләтле» дип бәяләгәннәр. Ул 1885 нче елның 9нчы октябрендә бирелгән [ ҮАФ, 2ф. , 2тас. , 3423 эш].

1907 нче елда Габделгазиз Рәхмәтуллин «картлык сәбәпле мулла булудан баш тарта» һәм үзе урынына оныгы Гыйрфан Минһаҗетдиновны тәкъдим итә. Мәхәллә кешеләре риза булалар. Шул ук вакытта, Шиһабетдинне муллалыктан алуны сорап, хат язалар. Сәбәп итеп аның хезмәтен башкармавын һәм авылның ике мулла тотарга хәле юклыгын күрсәтәләр. Шиһабетдин исә «Гыйрфан Минһаҗевны мулла итеп куюга каршы түгел» дип яза. Ләкин аны этисе урынына өлкән мулла итүгә риза булмый. Моның өчен Гыйрфанның белеме түбән булуын әйтә. Крестьяннарның шуны аңламыйча, бары үз файдалары өчен генә тырышуларын билгеләп китә.

Казан Губерна идарәсе Мөселманнарның Оренбургтагы Диния нәзарәтенә Ш.Рәхмәтуллинның үз-үзен әхлаксыз тотышы сәбәпле, указын алу турында рапорт җибәрә. Ләкин җәмгыять, «мондый фактлар табылмады» дип, рапортны кире кага. Шулай итеп мәхәлләдә Шиһабетдин мулла булып кала. Ә Гыйрфан Минһаҗевка исә белеме түбән булу һәм авылда бер генә мулла булырга тиешлектән указ бирелми [ҮАФ, 2ф. , 2тас. , 7865 эш].

Мәхәллә кешеләре моның белән килешергә теләмиләр. Шиһабетдин һәрвакыт Чукры Оланда яши. Шуңа күрә Кече Урсак крестьяннары үзләренә яңа мулла сорыйлар. Ике авыл арасы ерак, 7 чакрым булганлыктан, мәхәлләне икегә бүлү турында сүз чыга. Ләкин эш ябыла [ ҮАФ, 2ф. , 2тас. , 7865 эш].

Моннан күренгәнчә, Шиһабетдин Рәхмәтуллин каршылыклы шәхес булган. Ләкин кульязмаларын, идарәгә язган хатларын карагач, аның белемле, зыялы кеше булуы күренә. Русча хатлары грамоталы, үтемле

итеп язылган. Бер шикаятендә хәтта идарәгә дә тел тидерә [ ҮАФ, 2ф. , 2тас. , 7865 эш].

1887 нче елгы халык санын алу вакытында, «халык күтәрелешенә юл куйган», өчен Борындык авылы имамнары өстеннән шикаять язуы да билгеле. [Салихов Р. , Хәйретдинов Р.:212. ]

Хезмәтләрендә автор төрле исемнәр күрсәткән. Аның Шиһабетдин Габделгазиз, Шиһабетдин Рәхмәтуллин Имәнлебашы яки Чукры Аланлы тәхәллүсе астында язуы билгеле.

Шиһабетдин Рәхмәтуллинның вафат булган елы да билгесез. «Русча–татарча тулы лөгать» 1920 нче елларда язылган. Ул исә – авторның безгә билгеле иң соңгы кулъязмасы. Җамал Вәлиди 1923нче елда чыккан хезмәтендә әле аның исән булуын әйтә [Валидов, 1923: 43]. Башка чыганакларда төгәл мәгълүматлар юк.

Шиһабетдин Рәхмәтуллин эшчәнлегендә берничә юнәлешне күрсәтергә була. Беренчесе – дәреслекләр. Китапханәдә аның «Яңа әлифбаи төрки» кулъязмасы сакланган. Ул 1893 нче елда язылган, ләкин ни сәбәпледер басылмаган. Дәреслек Сәлим Сабиттан тәрҗемә ителгән. Әлифба авторның методик күрсәтмәләре белән ачыла. Хәрефләр, уку күнегүләре, сүзләр, җөмләләр бирелгән. Сорау һәм җавап рәвешендә әдәп-әхлакка, динигә караган гыйбарәләр бар. Әлифбаның икенче бүлегендә гарәп алфавиты, грамматикасы һәм догалар урнаштырылган [Фәтхи:20]

Сәлим Сабиттан тәрҗемә ителгән икенче дәреслеге – «Гыйльме хисап рисаләсе». Бу арифметика дәреслегендә цифрлар, хисап гамәлләре хакында төшенчә бирелә, күнегүләр китерелә [Фәтхи:21].

Ш. Рәхмәтуллин география дәреслеге дә яза. «Җәгърәфия гомумия»нең 1899-1905 нче елларда берничә басмасы чыга.

Ш. Рәхмәтуллин татарларны рус теленә өйрәтүгә дә үзеннән өлеш кертә. Ул сүзлекләр, үзөйрәткечләр авторы буларак та билгеле. Аның ике сүзлеге безгә мәгълүм. Беренчесе –1893нче елда чыккан «Татар теленнән русчага һәм рус теленнән татарчага тәрҗемә яки лөгать», ә икенесе – «Русча-татарча тулы лөгать». Сүзлек 1920 нче еллар башында эшләнгән.

Ул ике кисәктән тора. Бүген аның кульязма хәлендәге икенче өлеше генә сакланган. Сүзләр тәрҗемәләре һәм аңлатмалары белән бирелгән [Фәтхи:21].

Шиһабетдин Рәхмәтуллинның үзөйрәткечләре дә киң таралган һәм бик күп тапкыр басылган. Мәсәлән, «Самоучитель татарского языка русским и русского языка татарам» хезмәте 1894-1914 нче елларда 8 тапкыр басыла. «Самоучитель Русского и Татарского языков. Словарь» (1914), «Самоучитель киргизского языка русским и русского языка киргизам» (1914) үзөйрәткечләре дә халык арасында киң таралган була.

Билгеле булганча, XIX гасыр уртасында беренче татар календаре чыга. Бу өлкәдә Ш.Рәхмәтуллин да үзен сынап карый. Р. Әмирхановның эшен дәвам итеп, 1890-1901нче елларда календарьлар бастыра. Вакыт күрсәткечләреннән тыш, монда сәүдә, финанс, хокук эшләренә бәйләнешле, чит ил халыклары, дәүләт төзелеше хакында төрле фактлар бирелгән. 1893нче ел өчен чыгарылган календарьда медицина турында гоумими мәгълүматлар бар. Шул чордагы эпидемияләр турында сөйләнә [Фәтхи:41].

Шиһабетдин Рәхмәтуллинның «Чын сүз» (1896) һәм «Чын әкият» (1909) китаплары билгеле. Беренче китап мәзәкләр тора, икенче китапта исә төрле фикерләр, җир тетрәү яки башка шундый чиктән ашып киткән фаҗигале вакыйгалар, төрле кызык хәлләр дә китерелгән [Бәширов, 1963:376]. 1901 нче елда «Төш тәкъбире» китабы чыгуы да мәгълүм.

Шиһабетдин Рәхмәтуллин тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнгән. Ул төрле әдәби һәм дини әсәрләрне татарчага күчереп бастыра. Ислам диненә багышланган гыйбрәтле хикәятләр җыентыгы – «Хикәяләр хәзинәсе»н тәрҗемә итә. «Кәнз-әл-хикаять» исемле бу китап 22 бабтан тора, һәр бабта алтышар хикәя бар. Тәрҗемә итүенең сәбәбен «гыйбрәт һәм хикмәтләр белән таныштырырга телим» дип күрсәтә.

Мөселман юриспруденциясе – фикъһе мәсьәләләренә багышланган гарәпчә «Һәдият-әс сәгълук»ны татарча бастырып чыгара.

Ике гасыр аралыгында кысалы кыйссаларны төрек теленнән тәрҗемә итеп, татар укучыларына җиткерүдә дә Шиһабетдин

Рәхмәтуллин активлык күрсәтә. Г. Газиз һәм Г. Рәхим «Татар әдәбияты тарихы»нда: «XIX гасыр ахыры XX гасыр башында шундый хикәяләрне мәйданга кую белән шөгыльләнүче мулла Шиһабетдин Рәхмәтуллин исемле язучы да килеп чыга. Бу кеше госманлы әдәбиятында санлары бик күп булган шул тип хикәяләрне татарчага тәҗемә итә. Аның тәрҗемәләреннән «Тиярзадә» 1900 нче елда, «Кылаф белән Диларә» 1901нчедә, «Кылаф белән Турандук» 1903 тә басыла» [Г.Рәхим, Г.Газиз, 1925: 253], дип әйтеп үтәләр.

Кысалы кыйсса үрнәкләреннән тагын «Малик» (1903), «Сәйфелмөлек»не (1909) күрсәтергә мөмкин. Шиһабетдин Рәхмәтуллин чыгарган кыйссалар шигъриятле булулары белән аерылып торалар. Алда әйтелгән әсәрләрен ул балаларга уку китабы рәвешендә төзи. К. Насыйридан соң «Әбугалисина» китабын тәрҗемә итеп, берничә тапкыр бастыра. [Татар әдәбияты тарихы, 1987: 257]. Шиһабетдин Рәхмәтуллин китапларында күп кенә вакыйгалар традицион төбәкләрдән бигрәк, әдәбият өчен яңарак, ә төрки татар укучысы өчен үз, якын булган атамалы урыннарда бара (Әстерхан, Җаек, Идел һ. б.). Хикәяләрдә вакыйгалар бара торган җирлекне, геройларның килеш-килбәтен җентеклерәк, детальләр ярдәмендә сурәтләүгә омтылыш үзен нык сиздерә. Шуңа күрә «Дүрт дәрвиш хикәяте» һәм «Мең дә бер көн»нән алынган «Кылаф белән Диларә», «Кылаф белән Турандук» кебек кыйссалары әле бүген дә кызыксынып укырлык дәрәҗәдә. [Миңнегулов, 1988:141].

Ул үзе дә шигырьләр яза. Аның «Куфи мәчесе» шигыре «Татар поэзиясе антологиясе»нә кертелгән. [Татар поэзиясе антологиясе, 1993:393]. Әсәр «Чын әкият хикәяләре» китабыннан алынган.

Шиһабетдин Рәхмәтуллинның балалары да иҗтимагый тормышта актив катнашканнар. Уллары Исмәгыйль һәм Исхак сәләтләре белән аерылып торганнар, кече яшьтән укуга омтылалар. Олы улы Исмәгыйль 1917- 1919нчы елларда зур урыннарда эшләгән. Татарлардан беренче булып ВЧКга җитәкчелек иткән. Ләкин хакимият һәм акча белән сынауга түзә алмый: хөкемгә юлыга. Соңгы язмышы билгеле түгел. [Султанбеков, 1994:136]

Мулланур Вахитовның якын дусты булганга, Исхак Рәхмәтуллинның карьерасы уңышлырак. Ул 1917 нче елдан алып Казандагы сәяси вакыйгаларның үзәгендә тора. Большевикларның беренче газетасында редактор була.

1919 нчы елда Башкортстан Республикасы оештырыла. Автономия хокуклары чикләүгә протест йөзеннән кайбер дәүләт һәм партия җитәкчеләре эш урыннарыннан китәләр. Алар арасында Исхак Рәхмәтуллин да була. Аны кулга алалар, ләкин Сталинның боерыгы белән азат ителә. Казанга кайткач, комуниверситетта укыта. 1936 нчы елда кабат кулга алына. Озак интектергәннән соң, аны төрле ялган гаепләр язылган кәгазьгә кул куйдыралар. Шул ук елны аңа карата «иң югары җәзага тартырга» дигән хөкем карары чыгарыла. [Султанбеков, 1994:137]

Шиһабетдин Рәхмәтуллинның фәнни эшчәнлегенә кыскача күзәтү аны башка галимнәр белән янәшә өйрәнелергә хаклы икәнен күрсәтә. Җамал Вәлиди «аның эшчәнлеге татар әдәбиятының алдагы үсешенә дә йогынты ясады» [Валидов, 1923:43] дип бәя бирә [Миңнегулов, 1988:139].

Ш.Рәхмәтуллинның Ш.Габделгазиз исеме белән басылган «Татар теленнән русчага һәм урыс теленнән татарчага тәрҗемә лөгать яки словарь» дигән хезмәте 1893 нче елда Казан университеты нәшриятында басыла. Китап 15х23 см форматта, 72 биттән тора. Сүзлекнең исеме русча да бирелгән: «Перевод съ татарскаго на русский языкъ или словарь». Исеменнән соң: «Бу тәрҗемәдә һәр затны җенесе вә нәүгысы илә аерым фасылларда бәян кылынгандыр, таки бер мәгълүм нәрсәнең исемени белмәк ирадә кылындыкта дәфгатән табу асан булсын өчен», дип куелган. 1892 нче елның 28 гыйнварында Санкт-Петербург цензурасы сүзлекне бастырып чыгарырга рөхсәт бирә. Сүзлекнең авторы Шиһабетдин Габделгазиз дип күрсәтелгән.

Сүзлек, алда әйтелгәнчә, аерым өлешләрдән тора. 40 бүлектә 1781 сүз тупланган. Тематик төркемнәр: «Адәм тәненең әгъзалары», «Кардәш-ыругларның исемнәре», «Кеше», «Киемнәр», «Ашамлыклар», «Үсемлекләр», «Хайваннар» һ. б.

Сүзләр гарәп һәм рус хәрефләре белән язылган. Битнең сулъяк яртысында татар сүзе, уң ягында гарәп һәм рус хәрефләре белән язылган рус сүзе урын алган.

Сүзлек ахырында «Җөмләләр һәм өзекләр» китерелгән. Бу җөмләләр гадидән катлаулыга ысулына туры китереп урнаштырылган. Алар арасында үгет-нәсыйхәт характерындагы әйтемнәр, мәкальләр, күренекле философларның сүзләре бар.

Шиһабетдин Рәхмәтуллинның бу хезмәте башка үзөйрәткечләреннән әлифбасы булмау белән генә аерылып тора. Ләкин автор үзе аны сүзлек дип атый.

Фонетик яктан караганда сүзләрнең күбесе бернинди үзгәреш тә кичермәгән, хәзергә телдә дә нәкъ сүзлектә теркәлгәнчә кулланыла. Ләкин игътибарны җәлеп иткән күренешләр дә бар. Иң беренче итеп, XIX йөздә сүз башы позициясендә җ ~ й тәңгәллегенең нормалашып җитмәгән булуы бу сүзлектә дә ачык күренә: гортань – جتقلق **җоткылык** [с.4], бок – جن باش **җан баш** [с.4], щека– جاناق **җаңак** [с.4], челюсть – جاناق سواعي **җаңак сөяге** [с.4], платок – جاولق **җаулык** [с.12], воротник – ياقا **яка** [с.12], чечевица – جسمق **җасмык** [с.15], дикий лук – جوا **җуа** [с.15], клубок – جمعق**җомгак** [с.17], одеяло – جورعان **җурган** [с.17].

Төрле аваз үзгәрешләренә дучар булган сүзләр дә бар: сын – اوعل **угыл** [с.5] плакать – يعلاماق **егъламак** [с.48], родиться – توعماق **тугъмак** [с.58]. Монда сүз уртасындагы [г] авазы төшеп калган. Язма әдәби телдә *угыл* варианты XX гасыр башына кадәр кулланылган. Искергән сүз дигән билге белән хәзерге сүзлекләрдә дә бирелә. Сөйләмә телдә ул вариант та күптәннән килә [Рамазанова, 1991:66]. Хрен – كره ن **керән** [с.14] сүзе татар теленең фонетик закончалыкларына буйсынган. Скамейка – ايسكه ميا **эскәмия** [с.17], стол – اوستل **өстәл** [с.17] сүзләрендә протеза күренеше, ягъни сүз алдына аваз өстәлү күзәтелә.

Сүзлектәге берәмлекләр тематик төркемнәргә бүлеп бирелгән. Шушы төркемнәргә, андагы лексик берәмлекләргә киңрәк тукталып үтик. Беренче төркем – «**Кеше**». Бу бүлектә кеше тәненең әгъзалары саналып чыккан. Ләкин беренче булып **Адам – ا دم Адәм һәм Ева –هوا Һава** [с.4]

сүзләре язылган. Бирелгән сүзләрнең күбесе бүген дә үзгәрешсез кулланыла: волоса –چهچ **чәч** [с.4], ухо – قلاق **колак** [с.4], язык – تل **тел** [с.4]; рука – قول **кул** [с.4], нога – اياق **аяк** [с.4]. Арада инде искергән сүзләр дә бар: голень – صيراق **сыйрак** [с.4], плечо – اين باشي **иң башы** [с.4]. Бу сүзләр бүген гади сөйләмдә генә кулланыла. Зрачок сүзенә сүзлектә كوز باشي **күз кешесе** дигән эквивалент китерелә [с.4]. Кайбер сүзләрнең тәрҗемәләре дөрес түгел: икра – اويلدق **уылдык** [с.4] бу очракта аяк балтыры күз алдында тотылган булырга тиеш, ләкин уылдык дип тәрҗемә ителгән. Кисть – اوج **уч** [с.4], ладонь – اوج تبي **уч төбе** [с.4] дигән тәрҗемәләр дә төгәл түгел. Хәзерге әдәби телдә кисть – **кул чугы** дип тәрҗемә ителә [РТС, 1984:216]. Биологик терминнар сүзлегендә «кул чугы – беләзек, уч һәм бармак сөякләреннән тора» дип бирелгән [РТБАС, 1985:260]. Димәк, бу очракта тәрҗемәләргә төгәллек җитми. Моны XIX гасырда татарча анатомия терминнарының формалашып җитмәве белән аңлатып була. Хәер, бу өлкәгә караган терминология хәзерге татар телендә лә камил түгел. Колак сүзе берлек һәм күплек санда күрсәтелгән: ухо – قلاق колак, уши – قلاقلار колаклар [с.4] Чөнки рус телендә бу сүздә аваз күчеше бар һәм, мөгаен, шуңа күрә автор бу сүзләрне аерым-аерым күрсәтергә уйлагандыр.

Икенче төркемгә туганлык терминнары тупланган. Сүзлектә туганлык терминнары һөнәр атамалары белән бергә киләләр. Сүзләрнең барысы да диярлек безнең телебездә әле дә кулланыла: отец – اتا **ата** [с.5], мать – انا **ана** [с.5], дочь – قز **кыз** [с.5] һ.б..

Телдә татар сүзләре белән беррәттән гарәп-фарсы вариантлары да кулланылган. Сүзлектә бу күренеш тә чагылган: вдовец –طل اير **тол ир, сәйиб** [с.6], вдова – طل حتون **тол хатын**, **сәйибә** [с.6]. Сәйиб, сәйибә — гарәп сүзләре [ГТРАС, 1969:456]. XX йөз башына кадәр кулланылган бу сүзләр бүген телдән төшеп калганнар.

Алга таба автор «Киемнәр» дигән тематик төркем тәкъдим итә. Бу бүлектә өс һәм аяк киемнәрен белдергән сүзләр тупланган. Шулай ук тукыма, тегүчелек эше белән бәйле кайбер атамалар да бар. Заман һәм мода үзгәрү сәбәпле, кием-салымга караган сүзләрнең күбесе искергән: поддевка – قاذاقي **казакый** [с.11], камзол – قامذول **камзул** [с.11], кафтан –

چيكمن**чикмән** [с.11], портянки – اياقچا **аякчу** [с.11], лапоть –اچباتا **чабата** [с.11], ичетки – چيتك **читек** [с.11]. Алынмалардан рус теленнән кергән: полотно – پلاتنا **платна** [с.12] сүзе бар. Сүзләр арасында хәзер искергән, пассив кулланылышка күчкән берәмлекләр дә теркәлгән: подкладка – اينچ **инеч, астар** [с.11]. Инеч — күлмәкнең арка һәм күкрәк турысына куелган икенче кат тукыма. Элек бу мәгънәдә астар сүзе кулланылган. [Рәхимова, 1983:57] Хәзер ул казан арты сөйләшләрендә очрый. [ТТДС, 1969:50]

Автор «Ашамлыклар» бүлегендә камыр ризыклары, аш төрләренең исемнәрен биргән. Шулай ук сөт һәм йомырка ризыклары атамалары да бар. Диалекталь сүзләр урта диалектның тау ягы сөйләшләренә карыйлар. Бу күренешне авторның шул сөйләш вәкиле булуы белән аңлатып була. Мәсәлән, сочень –جوقا **жука** [с.13] – төче камырдан юка итеп җәеп пешерелгән ризык. Бу сүзнең Казан арты, тау ягы сөйләшләрендә жука формасы киң таралган. Бүгенге көн сүзлекләрендә ул диалектизм дип карала һәм «табада пешерелгән юка камыр ризыгы» дип бирелә [Хайрутдинова, 1993: 47]. Диалектологик сүзлектә исә, Казан арты сөйләшләрендәге камыр ризыгы атамасы дип күрсәтелгән [ТТДС, 1993:415]. Орешки – ششارا **шишара** [с.13] тау ягы – тархан сөйләшендә бавырсакны шишара дип йөртәләр [ТТДС, 1993:376].Чикләвеккә охшаган булганга, бу ризыкны руслар «орешки» дип атаганнар. Пирок – كلجمهкәлҗемә [с.13] сүзе әдәби телдә сумсаны белдерә [ТТДС, 1993:195]. Әдәби телдә бәрәңге измәсеннән пешерелгән кабартманы кәлҗемә дип атыйлар. Ә инде тау ягы сөйләшендә пирог мәгънәсендә йөри [Хайрутдинова, 1993:30]. Рус алынмасы горчица – عرچيسا **горчица** [с.14.] сүзе бернинди үзгәрешсез кабул ителгән һәм кулланылган.

«Ашамлыклар» төркеменнән соң «Эчемлекләр» дигән төркем килә. Бу тематик төркемгә караган сүзләрнең күбесе бүген дә үзгәрешсез кулланыла: вода –سو **су** [с.14], чай –چي **чәй** [с.14], вино – حمر **хәмер** [с.14] һ.б..

Үсемлекләр төркемен өч бүлеккә бүлеп карарга мөмкин: «Ашарга яраклы үләннәр», «Җимешләр», «Бакча җимеше». «Ашарга яраклы үләннәр» бүлегендә ашлык исемнәре һәм үлән атамалары китерелгән. Сүзләрнең күбесе борыңгы төрки тамырлы. Мәсәлән, ячмень – اربا **арпа**

[с.15] гомум төрки катламга карый. Пырей – ايراوق **айравык** [с.15] – борыңгы төрки ajrig тамырыннан ясалган [Саберова, 1996:41]. Бу сүз хәзер урта диалектта кулланыла. Ә полба – بوراي **борай** [с.15], рожь – ارش**арыш** [с.15] сүзләре татар теленә рус теленнән кергән [Саберова, 1996:55]. Кукуруза сүзенең тәрҗемәсе үзенчәлекле. Ул كعبة بوداي **кәгъбә богъдай** [с.15] дип күрсәтелгән. Бу атама әлеге үсемлекнең безнең якларга ерак көнчыгыш илләреннән керүен раслыйлар. Автор бу төркемдә дә җирле сөйләш үзенчәлекләрен теркәп киткән: шиповник – بورني ايت**эт борыны** [с.15] тау ягы – кама тамагы сөйләшендә гөлҗимешне белдерә [ТТДС, 1969:609], подсолнечник –ايباغار **айбагар** [с.15] тау ягы сөйләшләре белән чиктәш мишәр диалекты сөйләшләрендә көнбагаш мәгънәсендә кулланыла [ТТДС, 1969:8].

Кайбер сүзләр дөрес тәрҗемә ителмәгән: свергубец – قاقي **какы** [с.15] свербига булырга тиеш иде, ә подорожник –مچي بورچاغى **мәче борчагы** [с.15] әдәби телдә – бака яфрагы.

«Җимешләр» бүлегендәге сүзләр бүген дә телебездә үзгәрешсез кулланыла һәм алар татар теленең актив сүзлек фондын тәшкил итәләр: яблоко – الما **алма**, ягода – جلك **җиләк**, калина – بالان **балан**, рябина – ويشنا **вишня** – چيا **чия** [с.16]. Җирле сөйләш сүзләре дә бар, мәсәлән, рожки – قارا قوزاق **кара кузак** [с.16] тау ягы сөйләшенә карый һәм элек базарда сатыла торган татлы төшле кузаклы көньяк җимешенең атамасы булып тора [ТТДС, 1969:289].

Ш.Габделгазиз үз сүзлегендә көнкүреш лексикасына зур урын бирә. Бу берәмлекләр «Йорт. Өй. Хуҗалык» дигән күләмле генә тематик төркемгә тупланганнар. Бу тематик төркемне үз эчендә «Өй», Өй эчендәге нәрсәләр», «Ишек алдындагы каралтылар», «Ындырдагы нәрсәләр» дигән төркемчәләргә бүләргә була.

«Өй» бүлегендә төзелешкә караган атамалар бирелгән: Основание, фундамент – نيعز **нигез** [с.16], бревно – بورنه **бүрәнә** [с.16], матица – ماتچا**матча** [с.16], доска – تاقتا **такта** [с.16] һ.б. берәмлекләр теркәлгән.

Сүзләрнең бер өлеше инде искергән, кулланылыштан төшеп калганнар: застреха – سولاق **сулык** [с.16], ставни – ترازه جابقچى **тәрәзә**

**жапкычы** [с.16], подволока – توفراقسا **туфракса** [с.16]. Кайберләренең мәгънәсе болай: туфракса – жылы саклау өчен туфрак салырлык итеп төзелгән түшәм. Татар телендә – са кушымчасы ярдәмендә йорт элементларын белдергән шактый сүз ясаган: тупса, җепсә һ.б..

Бу төркемчәгә кергән сүзләрнең берничәсе диалектларга карый: توبسا **тупса** [с.17] сүзе әдәби телдә элмәк дип атала,ә قاچى качы [с.17] төзүчеләр термины булып санала. Әдәби телдә аны **атлама**, **бәпкә** дип йөртәләр. Ул өй түбәсендәге каралтыны белдерә. Тау ягы сөйләшендә шул формада йөри [ТТДС, 1969: 198].

«Өй эчендәге нәрсәләр» бүлегендә өй эчендәге җиһаз атамалары тупланган: стул – ورندق **урындык** [с.17] подушка –منده ر **мендәр** [с.17], нары –سكي **сәке** [с.17], полати – سندره **сәндерә** [с.17], лавка – جن سكي **җан сәке** [с.17], поднары – سكي استي **сәке асты** [с.17], лоток – جلپوچ **җилпуч** [с.17], прялка – قبا **каба** [с.17], бердо– قلچ **кылыч** [с.17], сновалки – كلب اعاچى**киләп агачы** [с.17], крючечки – تاقتا قاشق **такта кашык** [с.17], скальница – قلدرچا **калдырча** [с.17], цевка – شوري **шүре** [с.17], ниченки – كركي**күре** [с.17], челнок – سوسا **соса** [с.17], дножки– تبلدرك **тәбәлдерек** [с.17], мялка – تالقي **талкы** [с.17]. Бу сүзләрнең мәгънәләре, кулланылышы Р.Рәхимова хезмәтләрендә җентекле итеп тикшерелгән (Рәхимова, 1983) .

Тематик принципка корылган бу сүзлектә «Уку-язу әсбаплары, фән атамалары» төркеме дә бар. Татарлар бу тематикага караган берәмлекләр гарәп теле белән бәйле. Билгеле булганча, мәдрәсәләрдә гарәп, фарсы телләре укытканнар. Мең елга якын татарлар гарәп язуын кулланган. Шул сәбәпле уку-язу белән бәйле шактый сүз – гарәп-фарсы алынмасы. Әмма алар арасында, вакытлар узу белән, кулланыштан төшеп калганнар әсбапларның атамалары да бар. Мәсәлән, аспидная доска – تاش تاقتا **таш такта** [с.11], грифель –تاش قله م **таш каләм** [с.11], чернильница – قارا ساوت **кара савыты** [с.11]. Элек кара белән язгач, аны ком сибеп киптергәннәр. Шуңа песок – قوم **ком** [с.11], песочница – قوم ساوتي **ком савыты** [с.11] да бу төркемгә кертеп карала.

«Кораллар», «Балта остасының кораллары» бүлегенә, агач белән эшләгәндә кирәкле, эш коралларының исемнәре тупланган. Бу сүзләр әдәби телдә хәзер дә кулланыла: топор – بالتا балта [с.37], долото –

اوترعي **өтерге** [с.37], молоток –چوكچ **чүкеч** [с.37], угольник –پچماق اولچەويچى **почмак үлчәвече** [с.38]. Тематик төркемдә рус алынмалары да бар. Алар татар теле нормаларына буйсынганнар, үзгәреш кичергәннәр: станок – ستان**стан** [с.38], клещи –كلەشچە **келәшчә** [с.38].

«Тимерче кораллары» бүлегендәге сүзләр үзгәрмәгәннәр. Алар тимерчеләр лексикасында бүген дә кулланыла. Мәсәлән, мех – كرك **күрек** [с.38], щипцы – قسقچ **кыскыч** [с.38], наковальня –تتمرچى بوكه ني **тимерче бүкәне** [с.38 ].

«Сугыш кораллары» бүлегендә сүзләр күп түгел. Бу коралларның инде күбесе кулланылмый, шуңа атамалары да искергән, телдән төшеп калганнар: копьё – سنعي **сөңге** [с.36], меч –قلچ **кылыч** [с.38], кинжал – حنجه ر **хәнҗәр** [с.38], пушка – طوب **туп** [с.38], стрела – اوق ук [с.38], лук – جه يه**җәя** [с.38], дубинка –چوقمار **чукмар** [с.38]

«Хайваннар» тематик төркемен автор берничә төркемчәгә бүлеп бирә.

«Йорт хайваннары» бүлегендә лошадь – اط ат [с.22], овца – سا رق сарык [с.22], собака – ايت эт [с.22], кошка –مچى мәче [с.22], мышь –طچقان тычкан [с.22] һ. с. сүзләр теркәлгән. Автор бу хайваннарны җенесенә, яшенә карап та бүлә: корова – سير сыер [с.22], бык – اوعز үгез [с.22], теленок – بوزاو бозау [с.22], тёлка – طا نا тана [с. 22], котёнок –مچى بالاسي мәче баласы [с.22], мышенок – طچقان بالاسي тычкан баласы [с.22]. Бүлектә безнең яклар өчен типик булмаган хайваннар да бар: осел – ايشه ك ишәк [с.22], верблюд – دويا дөя [с.22], лошак –قاجر качыр [с.22]. Рус алынмаларыннан коза – كه جه кәҗә [с.22] сүзе генә теркәлгән.

«Киекләр» бүлегендә кыргый хайваннар исеме бирелгән. Алар барысы да әдәби телдә үзгәрешсез кулланыла. Мәсәлән, волк – بوري бүре [с.25], лиса – تولكي төлке [с.25], медведь –ايو аю [с.25], белка – تين тиен [с.25]. Безнең якларда яшәмәгән хайваннар да бар: лев– اريسلان арыслан [с.25], тигр – يولبارس юлбарыс [с.25], слон – فيل фил [с.25] һ.б.

«Кошлар»ны автор йорт һәм кыргый төрләргә бүлеп карамый. Кош исемнәре үзгәрмәгән, хәзерге татар әдәби телендә дә шулай ук аталалар:

воробей –چپچق чыпчык [с.23], голубь – كوگەرچن күгәрчен [с.23], журавль – تورنا торна [с.23], курица – تاوق тавык [с. 23], петух –اتەچ әтәч [с.23] һ.б.

Ата һәм ана кошларның атамалары төрлечә булган очракта, автор аларга аңлатма бирә: утка – انا اوردە ك ана үрдәк [с.23], селезень – اتا اوردە ك ата үрдәк [с.23], индейка – انا كوركە ана күркә [с.23], индюк – اتا كوركە ата күркә [с.23].

Кошларның төрләре аерып күрсәтелгән: дикая утка – قر اوردە عي кыр үрдәге [с.23], чирок –چوركاىاوردك чүрәкәй үрдәк [с.23], дикий гусь – قر قازي кыр казы [с.23], филин – مچىباشلي جابالاق мәче башлы җабалак [с.23], лесная сова– اورمان جابالاعي урман җабалагы [с.23] һ.б.

Атамалар арасында диалекталь сүзләр дә бар. Мәсәлән, скворец – چيرچقчыерчык [с.23]. Чыерчык – казан арты сөйләшләрендә әдәби телдәге форма белән параллель рәвештә кулланыла [Садыкова: 76]. Снегирь – توش قزيل кызыл түш [с.23] әдәби телдә карабүрек дип йөртелә. Мишәр диалектында һәм казан артының кайбер сөйләшләрендә кызылтүш диләр [Садыкова, с.76]. Синица –چپچك чәпчәк [с.24] казан арты сөйләшләрендә сиртмә койрыкны шулай атыйлар [Садыкова:75], орел – قارا قش кара кош [с.24] сүзе казан арты сөйләшләрендә бөркетне аңлата [Садыкова: 66].

Хәзерге татар әдәби теленең орфографик нормалары буенча кушма сүз булып, бергә язылган сүзләр ул вакытта аерым язылган: лебедь – اق قش ак кош [с.24], орел – قارا قش кара кош [с.24].

Автор бөҗәкләрне «сөяксез җанварлар» дип тәрҗемә иткән. Бу бүлектәге сүзләр хәзерге татар әдәби телендә үзгәрмәгәннәр. Алар шулай ук кулланыла. Мәсәлән, бабочка – كوبە هك күбәләк [с.34], муха –چبن чебен [с.34], пчела –اومارتا قورتي умарта корты [с.34], оса –شپشە шөпшә [с.34], комар –چركى черки [с.34].

«Корсагы белән шуышып йөри торган җанварлар» бүлегендә сөйрәлүчеләр һәм җир – су хайваннары исемнәре бирелгән. Алар хәзерге телдә дә шулай ук кулланылалар. Мәсәлән, уж – توز باشلي جيلان туз башлы җылан [с.35], лягушка – باقا бака [с.35], пиявка – سولك сөлек [с.35].

Җир-су хайваннары һәм сөйрәлүчеләр белән бергә автор түбәндәге сүзләрне дә кертә: дракон –اژداها аждаһа [с.35], червяк – سوالچان суалчан [с.35], моль – كوا көя [с.35].

Урта диалектта ташбаканы гөберле бака дип йөртәләр [Садыкова:60]. Бу Ш. Габделгазиз хезмәтендә дә чагылган: черепаха – عبرلي باقا гөберле бака [с.35].

«Агачлар. Куаклар» төркемендә агач һәм куакларның атамалары гына түгел, ә аларның өлешләренең ничек аталуы да теркәлгән. Мәсәлән, дуб – ايمن имән [с.25], береза– قاين каен [с.25], сосна – نارات нарат [с.25], осина – وساق ا усак [с.25], корень – تمر тамыр [с. 25], кора – قايري кайры [с.25], листок – يافراق яфрак [с. 25].

Сүзләрнең алынма һәм татарча вариантлары янәшә бирелгән. Мәсәлән, острец – ساعز сагыз, сәмих [с.25] **сәмих** гарәп теленнән алынган, агач чәерен белдерә [ГТРАС:521].

Җирле сөйләшкә хас формалар да очрый. Орешник – قواق куак [с.26] әдәби телдәге чикләвек куаклыгы мәгънәсен белдергән [ТТДС, 1993:140].

«Җир» бүлегендә туфрак төрләре һәм рельеф формаларын белдергән сүзләр тупланган. Туфрак төрләренең башта сыйфаты әйтелә, аннан *йер* сүзе килә: хорошая земля – ياحشي ير яхшы йер [с.36], жесткая земля – قاتي ير каты йер [с.36 ], болотистая земля – سازلي ير сазлы йер [с.36], песчаная земля – ير قملي комлы йер [с.36]. Рельеф исемнәре хәзерге телдә дә шулай ук калган. Мәсәлән, гора – تاو тау [с.36], низменность – اويسو ير уйсу йер [с.36], яма–چقر чокыр [с.36].

«Минераллар» бүлегенең исемен автор гарәп сүзе белән «Мәгъдән» дип атый. Биредә металл, кыйммәтле ташлар исемнәре тупланган. Сүзләр бүген дә үзгәрмәгән: золото – التن алтын [с.37], жемчуг – ينجي ا энҗе [с.37], ртуть – تيري كومش тере көмеш [с.37], кремень – چاقما طاشчакма таш [с.37].

«Дөнья тарафлары» бүлегендә искергән сүзләр дә бар: восток – قوياش چعيشي кояш чыгышы [с.28], запад – قوياش بايشي кояш баешы [с.28], юг – توشلك төшлек [с.28], север – تن ياعي төн ягы [с.28]. Арадагы юнәлешләр

дә шул сүзләрдән ясалган: юго-восток – кояш чыгышы белән төшлек арасы [с.28], юго-запад – кояш баешы белән төшлек арасы [с.28] северо-восток – кояш чыгышы белән төн ягы арасы [с.28], северо-запад – кояш баешы белән төн ягы арасы [с.28].

«Һавадагы нәрсәләр» тематик төркемендә күк җисемнәре һәм табигать күренешләре исемнәре тупланган. Мәсәлән, небо – كوك күк [с.27], солнце – قوياش кояш [с. 27], молния – ياشن яшен [с.27], дождь – ياڠغر яңгыр [с.27], ветер – جل җил [с.27]. Карның төрле төрләре аерып күрсәтелгән: крупа – جارما قار җарма кар [с.27], слякоть – جابالاق قار җабалак кар [с.27]. Халыкка билгеле булган йолдызлык исемнәре урын алган. Мәсәлән, Большая Медведица – يولدز جيدكه ن Җидегән йолдыз [с.27], Малая медведица – ايله ك يلدز Илэк йолдыз [с.27], Млечный путь – قر قازي يولي кыр казы юлы [с.27 ]. Хәзерге татар телендә млечный путь сүзенең татар телендә киек каз юлы дигән эквиваленты бар.

«Вакытлар» бүлегендә ел фасыллары, атна көннәре һәм көннең төрле вакыты күрсәтелгән. Бу сүзләр бүген дә үзгәрешсез кулланыла. Мәсәлән, год – يل ел [с. 29], весна – ياز яз [с.29], зима – قش кыш [с.29], неделя – اتنا атна [с.29], сегодня – بوكون бүген [с.29], вечер – كيچ кич [с.29]. Татар телендә вакытны белдерүче күп сүзләр – гарәп алынмалары. Алар телебездә хәзер дә актив кулланыла: век – عاسر гасыр [с.29], час – سه عات сәгать [с.29]. Кайбер сүзләр кулланылыштан төшеп калган, аларны рус алынмалары телдән кысрыклап чыгарган: минута – دقيقة дәкыйкә [с.30], секунда – ثانيا сания [с.30].

Финанс-икътисад өлкәсенә караган сүзләрне «Үлчәү берәмлекләре» дигән төркем берләштерә. Акча хисабына караган сүзләр инде искергән. Ул чордагы акча исемнәре, акча төрләре үзгәрү сәбәпле, кулланылыштан төшеп калган: медь – باقر бакыр [с.31], полкопейки – يارتي تين ярты тиен [с.31], четверть копейки – چيرك تين чирек тиен [с.31]. Рубль – ته نكه тәңкә [с.31] сүзе дә актив кулланылган. Хәзер ул гади сөйләмгә генә хас. Әдәби телдә исә сум сүзе йөри.

Авырлык үлчәү берәмлекләре «Мизан үлчәве» дигән бүлектә карала. Бу үлчәү берәмлекләре хәзер бөтенләй кулланылмый. Алар урынына телгә рус теле аша кергән халыкара терминнар урнашкан. Бу бүлектәге сүзләрнең күбесе гарәп алынмалары: весы – مزان мизан [с.32], золотник – مسقال мыскал [с.32] һ.б.

Металл, агач, пыяла һ. б. материаллардан төрле савытлар җитештерү үсә барган саен сыеклыклар һәм чәчелүчән матдәләрнең күләмнәрен үлчәү берәмлекләре дә камилләшә. Татарлар көнкүрештә кисмәк, капчык, кап, чиләк, чүлмәк кебек әйберләрне файдаланганнар [Беркутов, 1992:64]. Аларны, гадәттә, ашлык үлчәгәндә кулланганнар. Бу сүзләр инде искергән, алар гади сөйләмдә генә калган. Мәсәлән, пудовка – پوداوقا подаука [с.32], четверик – توبال тубал [с.32] һ.б.

«Нәрсәләрнең буен үлчәү» төркемендәге сүзләр – озынлык үлчәү берәмлекләре. Алар XX йөз башында кулланылганнар. Мондый үлчәү берәмлекләренең төгәл кыйммәте булмаган һәм шуңа карамастан төрле халыкларда актив кулланылган [Беркутов, 1992, с. 46]. Ләкин бүген аларны искергән сүзләр буларак карыйбыз. Мәсәлән, сажень – قلاچ колач [с.33] сүзе әйберләрнең озынлыкларын үлчәгәндә бик киң кулланылган үлчәү берәмлеге. [Беркутов, 1992:50]. Верста – چاقرم чакрым [с.33], билгеле булганча, җир эшкәртү процессында туган озынлык үлчәмнәре юл үлчәү берәмлекләренә, ә соңрак озынлык берәмлекләренә әйләнәләр. Бу әверелешкә мисал итеп, «чакрым» дигән ераклык берәмлегенең үсешен күрсәтергә була. Озак вакытлар чакрым – кеше тавышын ишетеп була торган бик якынча ераклыкны аңлата. Ахырда, русларның «верста»лары йогынтысында, бу ике үлчәү берәмлеге тәңгәлләшә, татарлар көнкүрешенә верста – чакрым буларак кереп кала [Беркутов, 1992:51].

«Кәгазь хисабы». Кәгазьне элек төргәкләп йөрткәннәр. Төп –тукыма һәм кәгазьне үлчәү берәмлеге. 1төп кәгазь 20 дистәгә тигез, 1 дистә – 24 табак [Беркутов, 1992: 48]. Тикшерелгән сүзлектә дә шул ук берәмлекләр китерелә: лист – طباق табак [с.33], десть – دیسته дистә [с.33], стопа – ستوب ступ [с.33]. «Ступ – алтышар табаклы сиксән төп; бары 480 табак кәгазь» дип аңлатма бирелә.

Сүзлектә «Әшъяэ мәгъкуләт», ягъни гомуми [абстракт] төшенчәләр теркәлгән махсус тематик төркем бар. Биредә түбәндәге сүзләр тупланган: мысль – اوي уй [с.37], радость – سونچ сөенеч [с.37], благость – ایزغلك изгелек [с.37], надежда – اومت өмет [с. 37]. Абстракт терминнар фәлсәфә фәненә карыйлар. Мәдрәсәләрдә фәлсәфәне гарәп телендә

укыганнар. Шуңа күрә гарәп алынмалары шактый күп: ум – عقل гакыл [с. 37], болезнь –مراز мәрәз [с.37] һ.б.

Автор төсләрне белдергән сыйфатларны аерып күрсәтә: белый – اق ак [с.29] красный –قزيل кызыл [с.29], черный –قارا кара [с.29], желтый – ساري сары [с.29], зеленый – ياشل яшел [с.29], голубой –زنعه ر зәңгәр [с.29]. Шунда ук ат төсләре дә бирелә: бурый –بورلي бурлы [с.29], гнедой – توري туры [с.29], рыжий – جيره ن җирән [с.29], пегий –الا قولا ала-кола [с.29], саврасый – قولا кола [с.29], гнедо-карий – قارا توري кара туры [с.29], гнедо-рыжий –نورن көрән [с.29] һ.б.

Шиһабетдин Рәхмәтуллин үз сүзлегендә кайбер сүз төркемнәрен дә аерып күрсәтә. Моны сүзләрне грамматик төркемләүнең беренче адымнары дип карарга була. Автор сүз төркемнәрен гарәп грамматикасына нигезләнеп язган дип уйлыйбыз. Чөнки гарәп терминнарын куллана. Мәсәлән, «Замырлар – нәрсәләрнең исемнәре урынына куела торган сүзләр, мәсәлән, замырлар, асмаи ишарәтләр, вә гайре мөбгамәтләр» дип аңлатма бирә. Сүзлектә юклык һәм билгесезлек төрләреннән кала, алмашлыкның барлык төркемчәләре дә урын алган. Һәр алмашлык берлек һәм күплек санда бирелгән. 3 зат алмашлыгының русча вариантларында род категориясе дә истә тотылган: я – من мин [с.3], он, она, оно – اول ул [с.3], мы – بز без [с.3], вы – سز сез [с.3], они – الار алар [с.3].

Күрсәтү алмашлыклары хәзерге телдә бернинди үзгәрешсез сакланганнар. Бары тик это – اوشبو ушбу [с.3] борынгы форма гына хәзерге телдә бик сирәк очрый.

Сорау алмашлыклары килеш сораулары тәртибендә бирелгән: кто? – كم кем [с.3], что? – ني ни [с.3], кого? –كمننك кемнең [с.3], чего? – نيننك нинең [с.3], кому? – كمكه кемгә [с.3], чему? – نرسهكه нәрсәгә [с.3]. Кайберләре бәйлекләр белән дә килгән: кем – كم بلان кем белән [с.3], о ком – كم تعرسندا кем тугрысында [с.3], о чём – ني تعرسندا ни тугрысында [с.3]. Билгеләү алмашлыкларыннан *үз* һәм *бары* гына күрсәтелгән. Үз алмашлыгы тартым һәм иялек килешендә төрләнгән формада бирелә: я сам– اوزم үзем [с.3], ты сам – اوزنك үзең [с.3], мы сами – اوزبز үзебез [с.3], свой –ازمننك үземнең [с.3.].

Тартым алмашлыклары ике вариантта тәрҗемә ителгән: 1. иялек килешендә килгән зат алмашлыклары; 2. - ныкы / -неке кушымчасы алган зат алмашлыгы. Мой, моя, моё – مینم минем, минеке [с.3], наш, наша, наше –بزننك безнең, безнеке [с.3].

Автор кайбер рәвешләргә дә тукталып үткән: сюда – بیري бире [с.3], давеча – بایا бая [с.3], намедни – بر كون беркөн [с.3], иногда – قیجاغندا кайчагында [с.3], частенько –یش еш [с.3].

Саннар бүлегендә предметларның санын, исәбен белдерүче сүзләр тупланган. Бары микъдар саннары гына күрсәтелгән. Автор саннарны үсә бару тәртибендә бирә. Башта бердән унга кадәр, аннан дистәләр, йөзләр, меңнәр һәм миллион килә.

Ш.Габделгазиз сыйфатларны ике төркемгә бүлеп карый: «Яхшы һәм яман сыйфатлар», «Нәрсәнең сыйфатлары». Беренчесендә кешенең холкын, рухи халәтен билгеләүче сүзләр тупланган. Аларның күбесе сыйфатка исем ясагыч -лык/ -лек кушымчасы ялгап ясалганнар. Автор бу сүзләрне грамматик ягына карап түгел, ә сыйфатлаучы сүз буларак кына бер төркемгә керткән һәм шулай атаган. Мәсәлән, гордость – تكبرلك тәкәбберлек [с.39], кротость – صبرلق сабырлык [с.39], скупость– سرانلق саранлык [с.39], честность – عدلك гаделлек [с.39] һ.б. Кеше күңел халәтен сыйфатлаучы сүзләрне дә бу бүлектә бирә: радость – سوینج сөенеч [с.39], скука – جمنسو җамансу [с.39], горе – قیغو кайгы [с.39] һ.б.

Җирле сөйләшкә караган түбәндәге сүз бар: трудолюбие – چرعلق лق җыргаклык [с.38]. Ул тау ягы сөйләшендә булдыклылык, эш сөючәнлекне белдерә [ТТДС, 1969:485].

«Нәрсәнең сыйфатлары» бүлегендә сыйфат сүз төркеменә караган сүзләр тупланган: горький – اچی ачы [с.39], хороший – یاحشي яхшы [с.40], молодой –یش яшь [с.41], косой –قیق кыек [с.41], гладкий – شوما шома [с.44] Ясалышы ягыннан караганда, ясалма сыйфатлар бик күп. -лы /-ле һәм -сыз/-сез кушымчалы сыйфатлар күпчелекне тәшкил итә. Әлеге кушымчалар белән ясалган сыйфатлар, антонимнар буларак, янәшә бирелгәннәр. Мәсәлән, острый –اوجلي очлы [с.42], неострый – اچسز очсыз [с.42], стыдливый – اویاتلي оятлы [с.42], бесстыдный – اویاتسز оятсыз [с.43], вкусный – تملي тәмле [с.43], невкусный –تمسز тәмсез [с.43]. Кайбер сыйфатларның хәзерге телдә искергән форма булып саналалар. Алар сыйфат ясагыч кушымчалардан башка гына кулланылалар яки башкача

аффикслар белән ясалалар: хитрый – حيلچەن хәйләчән [с.42] – хәзерге телдә хәйләкәр, кроткий – صبرلقلي сабырлыклы [с.42] – хәзерге телдә – сабыр, старательный – طرشوچان тырышучан [с.43] – хәзерге телдә тырыш, воздержанный – طيناقلي тыйнаклы [с.43] – хәзерге телдә тыйнак һ.б.

Сыйфатлар арасында гади сөйләм сүзләре дә күп: глупец – احماقахмак [с.39], бестолковый – انكرا аңгыра [с.39], слюнявый – سولەگەي селәгәй [с.43], облезлый –تاز таз [с.43]. Бу сүзләр еш кына исем мәгънәсендә кулланылалар, ягъни исемләшәләр.

Хезмәтнең иң зур өлешен тәшкил иткән тематик бүлек – «Фигыльләр. Эшләр». Фигыльләр гарәп алфавиты тәртибендә, инфинитивның борынгы формасы -мак / - мәк белән бирелгәннәр. Тупланган сүзләрнең күбесе актив лексикага карый һәм үзгәрешсез кулланыла: есть – اشاماق ашамак [с.44], сказать – ايتمه ك әйтмәк [с.44], валить – ا وداوماق аудармак [с.44], ходить – ئورمهق йөрмәк [с.44]. Кайбер фигыль юнәлешләре дә бирелгән. Аерым алганда, төп һәм йөкләтү юнәлешендәге фигыльләр янәшә урнашкан: удлинять – وزايتماق озайтмак [с.55], удлиняться – وزايماقозаймак [с.55], родиться – توغماق тугъмак [с.58], рожать – توغدرماق тугъдырмак [с.58], успокоиться –تونوچلانماق тынычланмак [с.58], успокоить – توبوچلاندرماق тынычландырмак [с.58] һ.б.

Арада искергән сүзләр, диалекталь берәмлекләр дә бар: обещать – اداروںماق адарынмак [с.50]. Адарынмак сүзе вәгъдә бирү, сүз бирү дигәнне аңлата [ТТДС, 1969:22]. Притвориться – قايشالماق кайшалмак [с.52] кылану дигән сүз; надоедать – جيك كورسه تمه ك жек күрсәтмәк [с.49;] туйдырып бетерү дигән мәгънә белдерә; поблекнуть – شيلمه ك шилмәк [с.49] шиңү, коруны белдерә [ТТДС, 1993:375].

Күренгәнчә, күләме ягыннан зур булмаган әлеге сүзлеккә бай лексик материал теркәлгән. Автор бары тик сөйләмдә актив кулланыла торган берәмлекләрне генә бирергә тырышкан. Сүзлек һәрьяктан да XIX гасырда дөнья күргән күпсанлы татар теле үзөйрәткечләренә бик якын. Бу ягы белән ул башка сүзлекләрдән аерылып тора.

Сүзләрне тематик төркемчәләргә бүлеп урнаштыру тел өйрәнүчеләрнең хезмәтен күпкә җиңеләйткән. Сүз төркемнәренә игътибар итү, аларга хас грамматик категорияләрне мисалларда гына күрсәтү Ш. Габделгазизнең чит тел өйрәтү методикасын яхшы белүе турында сөйли.

## А.Воскресенский сүзлеге

Воскресенский Алексей Андреевич 1856 нчы елның 23 нче ноябрендә Кострома губернасы Буткиво авылында рухани гаиләсендә туа. Иң элек Кострома семинариясендә белем ала. 1879- 1883 нче елларда Казан духовный академиясенең дини тәгълиматлар өйрәнү бүлегендә укый. 1983 нче елдан Казанның керәшен татарлары мәктәбендә дин фәннәре укыта. 1895 нче елдан Әстерхан губернасының Букеев урдасындагы “кыргыз” мәктәбендә инспектор итеп билгеләнә. 1906 нчы елдан Казан укытучылар семинариясенең директоры, 1914 нче елдан хәзерге Запорожье укытучылар семинариясе директоры булган. Анда гомеренең соңгы көненә кадәр эшли.

А.Воскресенский күбрәк тәрҗемә эшләре белән шөгыльләнә. 1894 нче елда «Русско-татарский словарь» дигән хезмәтен бастырып чыгара.


УРЫСЧАДАН ТАТАРЧАГА КЮЧЕРГЯН

СЮЗЛЯР ЖЫЙЫНЫ.

РУССКО-ТАТАРСКІЙ СЛОВАРЬ

Russko-tatarskii

съ предисловіемъ

о произношеніи и этимологическихъ измѣненіяхъ татарскихъ словъ.

А. Воскресенскаго.

Сүзлек 374 биттән тора. Кереш сүз юк. Бары тик рус хәрефләренең урнашу тәртибе, ягъни рус алфавиты гына бирелә. А.Воскресенскийның русча-татарча сүзлеге керәшен татар мәктәпләрендә кулланыла торган төрле куланмалардагы сүзләрдән һәм Казан губернасының керәшен авылларыннан җыеп кайткан лексик берәмлекләрдән төзелә.

А.Воскресенский сүзлеге искиткеч тулы, төгәл итеп эшләнгән. Автор рус сүзләренең татар телендәге тәңгәллекләрен табарга тырыша. Даими рәвештә булмаса да, сүзләрнең кулланалыш даирәсен күрсәтеп китә. Мәсәлән: Агнецъ – (ц.сл.) бярян, Алла бяряне. Агнецъ непороченный – монсоз бярян, пасха бяряне [В., 1894: 1], бабка (игральная кость) кузна [В., 1894: 3].

А.Воскресенский сүзләрнең тәрҗемәләрен бирү белән генә чикләнми, күп очракта ул сүзнең куллану мөмкинлекләрен күрсәтә, сүзтезмәләр составында сүзнең урынын билгели: деньги – акча (*вообще*), тянкя – (*серебряныя*, которые называются также и комош акча). *Бумажныя* деньги – кагаз акча. *Золотыя* деньги – алтын акча. *Деньжонки* – акча-мокча, акча асяре. За деньги продать – акчага сат [В., 1894: 53].

Сүзлекнең тагын бер үзенчәлекле ягы – сүзләргә аңлатма биреп тәрҗемә итү: касса – касса (акча сала торган төш) [В., 1894: 101], налогъ – налогъ (айбер очен казнага тюляу) [В., 1894:143], профессоръ – профессоръ (Академия белян Университетта ойрятеуче) [В., 1894: 259], вакса – вакса (итек чистарта торган нястя) [В., 1894:17]. Мисаллардан күренгәнчә, бу ысул татар телендә рус сүзләренә туры килә торган эквивалент булмаган очракларда кулланыла.

XIX гасыр татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләренең күбесеннән аермалы буларак, А.Воскресенский фигыльләрне боерык формасында тәрҗемә итә: расплавлять – эрет [В., 1894, с. 275], врать – алда, жалганна, жалганнаб айт [В., 1894: 31] һ.б.

Сүзлектәге кайбер берәмлекләрнең аңлатмалары бик зур итеп бирелгән. Анда сүз турында тулы мәгълүмат табарга мөмкин. Мәсәлән, дорога – жул, Оло жул (большая), баганалы (столбовая), кайынны (саженная) жул. Дорожка – (тропинка) сукмак. Счастливой дороги!

Изге жулга, жакшы жулга! На этой дороге – бу жулда. До этой дороги – бу жулга. По дороге – барышлый. По одной дороге – бер жул белян. Дорожный человек – жулчы. Дорожный запас –жуллык, жуллык азык. Прокладывать, отыскивать дорогу – жулла [В., 1894:57]

XIX гасыр татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрнең барысына да хас булганча, А.Воскресенский хезмәтендә дә архаик һәм тарихи сүзләр шактый күп. Кайбер берәмлекләргә аңлатма биреп үтик: асламчы «разносчик» мәгънәсен белдереп килә [В., 1894:271]. Бу сүз иске татар телендә актив кулланылышта йөргән. Татар телендә **асу-** файда мәгънәсендә кулланылган һәм телебезгә монгол теленнән кергән булырга мөмкин, чөнки монгол телендә телендә ашы«выгода» мәгънәсен аңлата. Жау – войско [В., 1894: 26] XIX гасырда актив лексика составында йөргән, ә бүгенге көндә искергән сүзләр рәтендә карала. Ләкин сөйләшләрдә бу сүз төрле мәгънәдә сакланып калган. Мәсәлән, Казан арты, этнә сөйләшендә җау – күп кеше булган урынны белдерә [ТТДС, 1993: 568]. Әдәби телдә бу лексик берәмлекнең яу (яулады) – «завоевал, заслужил» дигән яңа мәгънәләре кулланылышта йөри. Димәк, иске дип каралган сүзләрнең, бүгенге әдәбиятта яңа мәгънә белдереп кулланылышта йөрү очрагы да булырга мөмкин. Инеч – подкладка [В., 1894: 211] сүзенең сөйләшләрдә энеч, энец вариантлары кулланыла. Бу сүз хатын кызлар һәм ирләр күлмәгенең арка һәм күкрәк турысына тиз тузудан саклау өчен куелган икенче кат тукыма. Инеч калын тукымадан тегелгән тышкы кием эченә теккәндә куела торган икенче кат тукыма дигзәнне белдерә [Рәхимова, 1994: 10]. Атау – остров [В., 1894: 179] сүзе XIX гасырда актив кулланылган булса да, хәзерге әдәби телдә бу лексик берәмлекне искергән сүзләр рәтендә карыйбыз [ТТАС, I: 82]. Атау сүзе оренбург, сыргач, касыйм сөйләшләрендә сакланган [ТТДС, 1969:92], ә хәзреге әдәби телдә бу сүзнең утрау варианты кулланылышта йөри. Котлы – счастливый [В., 1894: 323] сүзе дә хәзерге телдә искергән лексика составына кертеп карала. Кот/котлы XVII – XIX гасырларда бәхет, нур, яшь, матурлык, уңыш мәгънәләрен аңлаткан [ТТАС, II: 168]. Котлы сүзенең «бәхетле» төшенчәсен белдергән мәгънәсе тагын да киңәйгән һәм яхшылык теләү, тәбрик мәгънәсендә йөри башлаган. Җан, тереклек, исән-иминлек, яхшылык, бәхет шатлык, байлык рәвешендә борынгы төрки

телдә һәм иске татар телендә Кутлук (хатын кыз исеме), Котлыкыя, Котлыяр кебек исемнәр, кушаматлар урын алганнар [Саттаров, 1990: 56].

А.Воскресенский сүзлеге үзенең сүзлек составы ягыннан Н.Остроумов сүзлекләренә бик якын. Бу уртаклыкны автор үзе дә күрсәтә, чөнки аларның максатлары, бурычлары бер була. Ләкин сүзлекләр беренче телләре белән аерылалар. Н.Остоумов сүзлекләре татарча-русча итеп төзелгән булса, А.Воскресенский беренче тел итеп рус телен ала. Аңлатма бирү алымнары ике сүзлектә дә бер типта эшләнгән, сүзләрнең бирелү рәвеше дә бер үк төрле. Миссионерлык идеяләрен тормышка ашыру максатыннан төзелгән бу сүзлекләр шул чордыга татар теленең сүзлек составын теркәгәннәр һәм алар шул яктан тел белеме өчен төгәл лексик материал чыганагы булып саналалар.

## М.Юнысов сүзлеге

Мирсәет Юнысов исеме киң катлам укучыларга таныш түгел. Ул — исемнәре онытылган, хезмәтләре озак еллар китапханә киштәләрендә тузан


Татарско-русскій
СЛОВАРЬ
наиболѣе употребительныхъ
словъ и выраженій,
составленный учителемъ русскаго класса
при Чистопольскомъ городскомъ медресе
Юнусовымъ.
Изданіе магазина братьевъ Каримовыхъ.
КАЗАНЬ.
Типографія Торговаго Дома братьевъ Каримовыхъ.
1900.

М.Юнысов сүзлегенең титул бите


Артыклыкъ—излишество.
Аямакъ—щадить.
Аяулыкъ—пощада.
Аяу—щаженіе.
Аялганъ—пощажённый, ая, ое.
Агачъ—дерево.
Агачъ май—деревянное масло.
Азъ—мало.
Атъ блянь бармакъ—ѣхать.
Атъ блянь юрмякь—ѣздить.
Атъ блянь крмякъ—въѣхать, въѣзжать.
Атъ блянь чыкмакъ—выѣхать, выѣзжать.
Аирма—различіе, разница.
Аирмакъ—различать.
Аирлганъ хатынъ—разведённая жена.
Артъ—задъ, тылъ.
Артда—назади.
Артданъ—сзади.
Артъякъ—задняя сторона.
Артъ санъ—задокъ (задняя часть тѣла).
Артъ блянь—задомъ, тыломъ.
Алъ—передъ.
Алданъ—спереди.
Алъ блянь—передомъ.
Алъ санъ—передокъ (передняя часть тѣла).
Алъябкычъ—передникъ, фартукъ.
Аксакъ—хромой, ая, ое.
Аксамакъ—хромать.
Аксатмакъ—сдѣлать хромымъ, ой.
Айгръ—жеребецъ.
Азабъ—мука, мученіе.
Азабламакъ—мучать, маять.
Азабланмакъ—мучаться, маяться.
Аулдашъ—однодеревенецъ.
Аулъ кшисе—поселянинъ, поселянка.
Алдамакъ (алдаламакъ)—обмануть, обманывать.
Алдау (алдалау)—обманываніе.
Алдакчы иръ—обманщикъ.
Алдакчы хатынъ—обманщица.
Алданмакъ—обмануться, обманываться.
Арчымакъ—чистить.
Арчытмакъ—заставить, заставлять чистить.
Арчылмакъ—чиститься.
Атмакъ—стрѣлять, кинуть, кидать.

М.Юнысов сүзлегенең бер бите

җыеп яткан авторларның берсе. М. Юнысовның тәрҗемәи хәленә килгәндә, бу турыда мәгълүматлар бик аз сакланган. Ул Чистай шәһәр мәдрәсәсендә рус теле укытучысы булып эшләгән. Рус, татар телләреннән шәкертләр өчен кулланмалар, сүзлекләр, үзөйрәткечләр язган. Г. Мансуровның «Татар провокаторлары » дигән китабында М.Юнысов хакында кыска гына мәгълүмат бирелә. Автор аның Уфа губернасы Бөре шәһәрендә укытучы булып эшләве, «Бирский» тәхәллүсе белән шикаятьләр, әләкләр язуы турында әйтә. 1912 нче елда М.Юнысов Уфага күчә, охранкага үз хезмәтен тәкъдим итә. Кайда гына яшәсә дә, М.Юнысов үзенең провокаторлык эшчәнлеген туктатмый. «Бубилар эше»н оештыручыларның берсе була. Октябрь инкыйлабыннан соң берничә тапкыр хөкемгә тартыла, ләкин тиешле җәзаны алмый. Казаннан Пермьгә кача, шуннан эзе бөтенләй югала [Мансуров, 1992: 108-109].

Безнең көннәргәчә авторның дүрт сүзлеге сакланган: «Татарско-русский словарь наиболее употребительных слов и выражений, составленный учителем русскаго класса при Чистопольскомъ городском медресе Юнусовым» (1900), «Татарча лөгать» (1903), «Русча вә татарча лөгать» (1903), «Татарско-русский словарь наиболее употребительных слов и выражений» (1906).

Беренче сүзлек 1900 нчы елда Казанда «Кәримовлар» сәүдә йорты типографиясендә дөнья күрә. Хезмәт 115 бит тәшкил итә, 4848 сүздән тора, барлыгы 1000 данә басыла. Автор, нигездә, татар теленең иң актив сүзлек байлыгын чагылдырган. Мәсәлән, аулъ – деревня [5 б.], аксакъ – хромой [7 б.], бить – лицо [21 б.], бауръ – печень [30 б.], бозъ – ледъ [31 б.]. Моны хезмәттә урын алган тотрыклы сүзтезмәләр, фразеологик әйтелмәләрнең бирелүе дә раслап тора: акылдан язмакъ – лишиться ума [10 б.], акылданъ чыкмакъ – сойти съ ума [10 б.]; акылданъ таймакъ – съ ума спятиться [10 б.], эрямъ тамакъ – дармоедъ [19 б.], эч поша – сердце ноетъ [20 б.], джиль куаръ – ветрогонъ [58 б.].

Сүзлеклер төзелеше гади дә, уңышлы да. Татар сүзләре дә, рус сүзләре дә кириллицада гына тәкъдим ителә. Кирилл алфавитында саф татар хәрефләре түбәндәгечә бирелә: **ə** – э этячь – пътухъ [16 б.], – я

бяя – цъна [23 б.]; ө – ӧ – бӧкӧ – затычка [29 б.], ү – ю – бюлмякь – дълить [33 б.] кюзь – глаз [78 б.], – дж – джиль – ветер [с.58] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, автор өчен беренче урында дөрес язу түгел, дөрес әйтү тора. Шура күрә кирилл алфавитында, татар сүзләрен укыганда кыенлыклар тумасын өчен, автор «ПРИМЕЧАНИЕ» дә куя:

«*Дж* соответствует татарской буквъ ج и означаетъ звукъ между ж и *ч,* лапр. въ словъ *джиханъ – міръ;* Н соотвътствует татарск. ڭ и озлачаетъ носовой звукъ *нг,* лапр. въ словъ *танъ – свътъ;* Надстрочный знакъ двъ точки служитъ для смягченія гласлых *у* и *о*» һ. б. [с.3]

Калган сүзлекләрдә ә-э, җ-дж, ө-о, ң-нг, ү-у, һ-х тәңгәллекләре бирелә. Бу графиканы, алда әйткәнебезчә, 1883 елда рус алфавитын Россиядә милли телләргә яраклаштырып, Казан университеты укытучысы, миссионер Николай Ильминский төзи һәм кулланышка кертә [Ильминский, 1883: 15-45].

Сүзлектә фигыльләр -мак/-мәк формасында һәм исем фигыльләр -у/-ү формалары белән тәкъбир ителәләр: элекляу – сплетничание [16 б.], ачмакъ – открыть, открывать [10 б.]

Сүзлектәге күп кенә сүзләрдә борынгы күрелешләр булуы ачыкланды, ягъни бу берәмлекләр борынгы язма әдәби тел традицияләрендә бирелгәннәр. Бу XX йөз башында традицион язма тел һәм сөйләм теленең бергә кулланылуы белән аңлатыла.

Барлык сүзлекләрдә очраган җ ~ й тәңгәллеге бу сүзлектә дә күзәтелә. й-ләштерү – кыпчак телләре өчен хас күренеш, ә җ-ләштерү исә болгар төркеме телләренә карый. Тарихи грамматиканы өйрәнүче галимнәр фикеренчә, [й] авазы борынгырак булып санала һәм ул татар телендә җ ~ й тәңгәллеген биргән [Хаков, 1993: 110]. М.Юнысовның 1900 нчы елгы сүзлегендә җ-ләштерү ешрак очрый: жермакъ - колоть [56], джука ирне – толкогубый, -ая [56 б.], джара – рана [57 б.], джарма – крупа [57 б.], джарау – угождение [57 б.], джонь – шерость [58 б.], джяня – еще [59 б.].

Бер төркем сүзләрдә с ~ ч тәңгәллеген күзәтергә мөмкин. [с] борынгы аваз булып санала. Кайбер сүзләрдә ул яшәеш дәвамында [ч]га

күч: санчке –вилка [53 б.], сачъ – волоса [53 б.], санчмяк – колоть, волзить [53 б.], сачак – цвѣтокъ [53 б.].

Төрки, шул исәптән татар теленә иренләшү күренеше хас. Хәзерге татар язма телендә ул орфографиядә чагылыш тапмый. Борынгы телдә иренләшү язуда да күрсәтелгән. М.Юнысов хезмәтләре шуңа дәлил булып тора: боркот кошъ – беркутъ [27], ботон тянкя – рублевая монета [24 б.], Ләкин бу күренеш һәр очракта да сакланмый, Мәсәлән, тозлы – соленый [27 б.], тортке – тычокъ[27 б.] һ.б.

Язма сөйләм өчен типик күренеш булмаса да, сөйләм телендә [гъ] авазының төшеп калуы – күптәнн килә торган үзенчәлекләрнең берсе. XIX йөздә һәм XX гасыр башында сүз уртасында һәм ахырында [гъ] авазының төшеп калуы татар теле өчен әдәби норма булып санала. Моңа мисал итеп М.Юнысов сүзлегеннән угылъ – сынъ [108 б.] сүзен китерергә була.

Хезмәттә бер төркем сүзләр иске формаларында бирелгәннәр. Борынгы сүзләрдәге [ст], [лч], [лт] төзелмәләре күп очракта хәзерге әдәби телдә бер авазы төшеп калган килеш әйтелә: ултырмак – сажаться, садиться [109 б.], торлакъ – жилье [42 б.] сүзләрендә [л] авазы төшеп калган.

Сүзлекнең төп өлешен төрки-татар лексикасы тәшкил итә. Алар белән беррәттән гарәп-фарсы, рус-европа алынмалары да урын алган.

М. Юнысов сүзлегенең XX йөз башында чыгуын исәпкә алсак, анда гарәп-фарсы сүзләренең күп теркәлүе гадәти хәл. Чыннан да, 1900 нчы елда дөнья күргән беренче сүзлегендә автор, хәтта, әлеге төр алынмаларны бирү белән мавыга. Мәсәлән, тимсах – крокодилъ [47 б.] , тарикъ-мал – наследство [47 б.], тяснифъ итмякъ – сочинять [47 б.], ригая – снисхождение [69 б.], ризванъ – начальник рая [69 б.], шаригать – законъ [70 б.], гаджябь – диво [72 б.], гнахъ – грехъ [72 б.], фаслъ – статья [73 б.], адалять – провосудие [11 б.], ахтари – словарь [11 б.], мусаннифъ – авторъ [90 б.], мулла – мулла [90 б.], мюмбярь – амвонь [90 б.], мюнятджимъ – астрологъ [90 б.], мядехнама – аттестация [90 б.], манара – башня [90 б.], маджара – летопись [91 б.], никяхъ – бракъ [93 б.], афгый –

ехида [14 б.], эграфъ – чистилище [18 б.], бадямь – миндаль [32 б.], талиха – счастье [34 б.], сеххафъ – переплетчикъ [55 б.], хардяль – горчица [65 б.], зубани – адский служитель [68 б.], зинданъ – тюрма [68 б.], гуа- свидетель [72 б.], гарызнамә – челобитная [74 б.], вязирь – министр [94 б.]. Соңрак чыккан хезм тл рд  мондый сүзләр шактый кими төш, М.Юнысов төрки-татар лексикасына игътибарын арттыра башлый.

Рус-европа алынмаларына килгәндә, алар гарәп-фарсы сүзләренә караганда  кимрәк урын алып торалар. Рус алынмалары арасында бик борынгы чорлардан кереп, телебездә  урнашып калганнары да, соңрак алынганнары, төрле фонетик үзгәрешләргә  бирелгәннәре дә  бар. Мәсәлән, трахтир –  трактиръ [47 б.], тулянь – тюлень[47 б.], тюмянь – тминъ  [47 б.], сажинъ – сажинъ [55 б.]  силитря – силитра [55 б.], камфуръ – камфора [77 б.], кяняпи – канапе [76 б.], канария – канарейка [76 б.], кябстя – капуста [76 б.], куасъ – квасъ [77 б.],  камытъ – хомутъ [77 б.], кязя– коза [77 б.],  ксяль – кисель [77 б.], лимунъ – лимонъ [89 б.], лумъ – ломъ [89 б.], лямкя – лямка [89 б.], лакъ – лакъ [89 б.], мюкь – мохъ [91 б.], мучала – мочало [91 б.], эшлия – шлея [18 б.], буряня – бревно [27 б.], буразна – борозда [28 б.], буранка – воронка [28 б.] һ.б.

М.Юнусов сүзлегенең башка сүзлекләрдән тагын бер аермалы ягы – басымга игътибар итү. Автор һәр сүзнең басымын куеп бара, бу күренеш татар сүзләрене белән чикләнмичә, рус сүзләрендә дә  чагылыш таба.

Хезмәттә тормышның төрле өлкәсенә караган диалекталь сүзләр дә чагылыш таба. М.Юнысов үзе яшәгән Чистай,  Бошкортстан төбәкләрендәге җирле сөйләм үзенчәлекләренә  күбрәк басым ясый. Шулай ук урта диалектның минзәлә, мамадыш, казан арты, тау ягы сөйләшләренә караган сүзләрне дә  кертә.

Архаизмнар арасында һөнәрчелек өлкәсенә  караган берәмлекләр шактый күп: талкы – мяльля [45 б.] – киндер яки итен сабагын кыстырып, сындыра һәм ваклый торган агач җайланма [Рәхимова, 1983:21]; сауръ – задъ ичиговъ [55 б.] джитен – ленъ [57 б.] – киндер туку өчен чимал булган үсемлекләрдән берсе – нечкә, нәфис сүсле үсемлек;  джон кабасы – прялка [62 б.], калын  киндер –дерюга [77 б.] сүзләре ачыклап килгән предметлары кулланылыштан төшеп калу сәбәпле  югалганнар. Булат –

сталь [27 б.] сүзе исә корыч дигән атама белән алыштырылган. Төркемчәдәге кайбер сүзләрнең мәгънәләрен тәрҗемәсе ярдәмендә генә аңлап була. Мәсәлән, саур : « читекләр элегрәк барлык яшьтәге һәм җенестәге кешеләр өчен тегелгән. Ирләр читеге бер генә төсле (күбесечә кара төстәге сәхтияннан) үкчәсенә яшел сауры куеп тегелгән» [Рәхимова, 1983:21].

Шулай ук сүзлектә тормыш-көнкүреш, йорт кирәк-яраклары атамалар да бар: берлилъ арбасы – карета [33 б.]; бакрачъ – мѣдный сосудъ [23 б.]; сяке – лавка (скамья) [55 б.]; сяндря – полати [55 б.], казанъ – котелъ [83 б.] – аш пешерү һәм су кайнату өчел кулланыла торган асты ярым түгәрәк чуен савыт [ТТАС, Т. II: 20] ухват – ухватъ [105 б.] – мичтән чуен, чүлмәк алу өчен җайланма [ТТАС, Т. III: 325] сүзләре хәзерге әдәби телдә юк.

Корылма атамасы булган джиль тигрмяне – вѣтреная мельница [58 б.], игенчелек өлкәсенә караган борай – полба [28 б.], йорт хайваннарыннан джитякле ат – заводная лошадь [62 б.] берәмлекләре хәзерге татар телендә сирәк очрыйлар. Соңгы берәмлеккә нисбәтле рәвештә, З.Садыйкованың «Зоонимическая лексика татарского языка» китабында җитәкле ат төшенчәсе кертелмәгән. Алда бары йөк аты, эш аты, эшче ат, җигем аты кебек төзелмәләр генә очрый [Садыкова, 1994:11-12].

Сүзлекләрдә кайчандыр рус-европа алынмалары белән кысрыклап чыгарылган, әмма хәзер телебезгә кире әйләнеп кайткан сүзләрне дә очратып була. Басмаханя – типография [26 б.], табибъ – врачъ [40 б.], тутырма – колбаса [4 б.], букча – сумка [21 б.], дарчынъ – корица [67 б.] сүзләре хәзер телебездә параллель рәвештә кулланылалар һәм бер –берсенә синоним булып торалар.

Тарихи сүзләр хезмәттә аз. Алар тарихның билгеле бер вакытына гына түгел, ә төрле чорларына карый. Бу сүзләрне түбәндәге тематик төркемчәләргә аерып була:

1) элеккеге иҗтимагый-сәяси тәртипләргә бәйләнешле тарихи сүзләр: **ачкыччы иръ** – ключникъ [12 б.], **ачкыччы хатынъ** – ключница

[12 б.], **алпаутъ** – помъщикъ [12 б.], **бикя** – княгиня [30 б.], **би** – клязь [30 б.], **таджъ -** вънец [43 б.], **ат башы тотучы** – кучеръ [5 б.].

2) сугыш, гаскәр, хәрби тормышка караган сүзләр: **ляшкярь** – войско [89 б.], **айбалта** – алебарда [8 б.], **булатъ клычь** – булатный [стальной] мечь [27 б.], **джяя джебе** – тетива [64 б.], **элямь** – знамя [18 б.].

3) элек кулланылган үлчәү берәмлекләре атамалары: **аршинъ** – аршинъ [10 б.], **брь грявянкя** – одинъ фунтъ [23 б.], **батман** – мера в четыре пудовки [24 б.], **сажинъ** – сажил [55 б.]. Бу төркемчәгә кергән сүзләр тормыш барышында башка телләрдән кергән сүзләр белән алыштырылу нәтиҗәсендә телебездән төшеп калганнар.

4) сәүдә өлкәсенә караган сүзләр: **асламчы иръ** – разнощикъ [12 б.], **асламчы хатылъ** – разнощица [12 б.]. Бу тарихи сүзләр Батырша язмалары һәм Е.И.Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы документлары циклында да күзәтелә [Хисамова, 1999:287-320]. Хәзер исә алар тарихи үткәнебезне тасвирлаган әдәби әсәрләрдә генә урын алалар.

М.Юнысов сүзлегенең тагын бер кызыклы ягын билгеләп үтәргә була. Бу хезмәттә **койрыклы йолдызъ** – комета [83 б.], **корымлы май** – вакса [85 б.], **уяткычъ** – будильник [108 б.], **озынъ шалканъ** – брюква [113 б.], **татар какысы** – кука [47 б.], **тяти купшя** – белоголовикъ [47 б.], **татар кашыгы** – разливная лошка [45 б.], **кырня** – дикобразъ [87 б.], **бикря балыкъ** – осетрина [34 б.], **санчкеле тигянякъ** – татарникъ [55 б.] кебек үзенчәлекле берәмлекләр бар. Әлеге сүзләр хәзерге телдә бөтенләй кулланылмыйлар, хәтта аларның кайберләре XIX гасырда дөнья күргән башка ике телле сүзлекләрдә дә очрамый. Шуңа күрә алар турында автор вариантлары булырга мөмкин дип уйларга урын кала.

Хезмәтнең лексик составын теркәгәндә, М.Юнысов рус теленнән турыдан тары тәрҗемә итү алымын кулланган дип әйтергә була, чөнки кайбер фразеологизмнарның тәрҗемәләре уңышсыз килеп чыккан. Мәсәлән, кюздя каш көтмәк – ждать очи не смыкая [78 б.] тотрыклы сүзтезмәсе шундыйлар рәтенә керә. Хәзерге әдәби телдә аның түбәндәге

варианты бар: керфеген керфекк какмыйча (төн буена, чак кына да йокламыйча мәгънәсендә) [Исәнбәт, 1989: 366].

Шунысы кызыклы: сүзлектә телдә еш кулланыла торган, аралашу өчен иң кирәкле сүзтезмәләрне дә очратып була. **Ат белән бармакъ** – ехать на лошади [12 б.], а**т блян юрмякъ** – ездить на лошади [12 б.], б**ашмакъларны кимякъ** – одевать башмаки [26 б.], б**рнымъ тыгылды** – носъ у меня залегъ [27 б.], **такиялы кыз** – взрослая девушка [46 б.], **тярязя пярдясе** – шторы [46 б.], **сикртуб бармакъ** – ехать вскачъ [49 б.], **гаамъ кешесе** – простонородец [72 б.], **кайнар су** – кипятокъ [75 б.]. Билгеле, автор бу сүзтезмәләрне татар телен үзләштерүне җиңеләйтү һәм тизләтү максаты белән кертә.

М.Юнысовның бу сүзлеге үзенең гади, аңлаешлы булуы белән аерылып тора. Ул турыдан – туры татар теле өйрәнүчеләргә атап язылган. М.Юнысов башка милләт вәкилләренә тел өйрәтү методикасын яхшы белгән. Бу авторның сүз сайлау алымында да чагыла, чөнки сүзлеккә актив лексика гына тупланган. Рус теленнән кергән сүзләр, гарәп-фарсы алынмалары башка сүзлекләргә караганда чагыштырмача аз.

Автор бер генә алфавиттан файдаланган. Ләкин алфавит төгәл, системалы рәвештә сакланмый. Кайбер урыннарда төгәлсезлекләр, сүзләрнең урнашу тәртибе бозылу күзәтелә.

***

Шулай итеп, XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр арасында төрле максатларда чыгып төзелгән, төрле күләмле сүзлекләр бар. Кайбер сүзлекләр уку әсбапларына ярдәмлек, тел өйрәнүчеләргә кулланма итеп төзелгән булсалар, икенчеләре зур күләмле энциклопедик характердагы ике телле сүзлекләр булып торалар. Сүзлекләр, нигездә, әдәби тел материалына таянып төзелгәннәр, ләкин шул ук вакытта татар теленең төрле сөйләшләренә нигезләнгән, диалектологик сүзлек дип аталырлык хезмәтләр дә бар.

Гомумән алганда, XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр телебезнең бер гасырлык лексик мирасын туплаган бик кыйммәтле хәзинә булып торалар. Аларны өйрәнү,

сүзлекләргә теркәлгән сүзләрне лингвистик яктан тикшерү, сүзлекләр ярдәмендә телебезнең сүзлек составының бер гасырлык үсешен, хәрәкәтен күзәтү татар теленең лексикология фәненә, тарихи лексикологиягә зур өлеш кертер дип уйлыйбыз.

## Башка төрки телләргә караган ике телле сүзлекләр

XIX гасырда башка төрки телләр белән бәйле сүзлекләр дә дөнья күрә башлый. Китапханә каталогларында, төрле библиографик белешмәләрдә чуваш, алтай, үзбәк, кыргыз, төрек телләренә багышланган сүзлекләр теркәлгән.

Чуваш теленең танылган белгече Н.Н. Золотницкий чувашча-русча сүзлекләр төзү өлкәсендә зур уңыш казана. Н.Н.Золотницкий (1829-1880) Казан университетының филология факультетын тәмамлый, 1865 нче елдан халык мәгарифе министрлыгының Казан белем бирү округында чуваш мәктәпләре инспекторы булып эшли. 1867 нче елда чуваш мәктәпләре өчен беренче әлифба китабы бастырып чыгара. Н.Н.Золотницкий – чуваш тел белеме фәненә нигез салган танылган галим. Аның хезмәтләре чуваш теленең лексикасы һәм фонетикасына багышлана [Кононов, 1974:165-166].

Лексикология өлкәсендәге хезмәтләре арасында галимнең чувашча-русча һәм русча-чувашча сүзлекләре зур әһәмияткә ия. 1871-1884 нче еллар аралыгында аның чувашча-русча һәм русча-чувашча 8 сүзлеге дөнья күрә. Алар арасында «Отрывки из чувашско-русского словаря» (1871-74) дигән тематик сүзлек тә бар. Сүзлеккә төрле халыкларда санау системасы, туганлык атамалары, Алла исемнәре, ай исемнәре, чуваш халык гореф-гадәтләре, йолалары, кием-салым, географик атамалар бирелгән. Төп сүзлек «Корневой чувашско-русский словарь, сравненный с языками и наречиями разных народов тюркского, финского и других» (1875) дип атала. «Корневой чувашско-русский словарь...» 1875 нче елда Казан император университеты типографиясендә басылып чыга, 279 биттән тора, барлыгы 3000 нән артык лексик берәм теркәлгән һәм анализланган. Бу

сүзлек 1879 нчы елда Рус географик җәмгыятенең алтын медаленә лаек була. Сүзлек алдыннан чуваш телендә иң актив тартык авазларның таблицасы урнаштырылган, бу авазлар башка төрки телләр белән чагыштырып бирелә. Мәсәлән, з-с=р каз (тат), хас (алтай), хор (чуваш); ш,с,=л кыш – кыс – хил һ.с. Сүзлек этимологик характерда төзелгән. Чуваш сүзләренең килеп чыгышы, аларның башка телләр белән бәйләнеше күрсәтелә. Бу – төрле төрки телләрнең чагыштырмалы сүзлеге.

Сүзлек алфавит тәртибендә төзелгән. Башта чуваш сүзе, аннан соң сүзнең рус теленә тәрҗемәсе бирелә. Мәсәлән, кизень – лишай [с.34], пиликъ – поясница (кут, тат. – биль, кир. бел, алт. пел) [с.48], соган – лукъ (овощь, уйгур суган; тур, тат, суган; алт. согано) [с.61]. Сүзлек төзегәндә автор Н.Ильминский, Л.Будагов хезмәтләренә таянып эш иткән, бу бигрәк тә сүзләрнең язудагы бирелешендә чагылыш таба.

XIX гасырда Алтай рухани миссиясе вәкилләре төрки телләрне, этнография һәм халык авыз иҗатын өйрәнүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Бу җәмгыять 1828 нче елда төзелә. 1869 нчы елда Казанда «Грамматика алтайского языка. Составлена членами Алтайской миссии » дигән, тюркология фәне өчен бик мөһим хезмәт басылып чыга. Авторлары – иероманах Макарий, В.И.Вербицкий һәм Н.И.Ильминский. Хезмәт өчен төп материалны В.И.Вербицкий туплый, чөнки ул Нижегород рухани семинариясен тәмамлаганнан соң, 1853 нче елдан Алтай рухани миссиясендә хезмәт итә башлый һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шул төбәктә яши. Башта мәктәптә укытучы булып эшли, ә 1857 нче елдан рухани-миссионер итеп билгеләнә. Танылган тюрколог В.И.Вербицкий гомере буе җирле халыкның телен, гореф-гадәтләрен, мифологиясен өйрәнә һәм 30 еллык хезмәт нәтиҗәсе буларак югарыда аталган грамматика һәм сүзлек дөнья күрә. Н.К.Дмитриев фикеренчә, алтай теле грамматикасы озак еллар барлык төрки грамматикалар өчен үрнәк булып тора [Кононов, 1974: 137-138].

Грамматикага кушымта итеп бирелгән «Русско-алтайский и алтайско-русский словарь» дигән лексикографик хезмәт безнең көннәрдә дә үз кыйммәтен югалтмаган. Сүзлекнең беренче өлеше 1–138 бит, ә икенче « алтайско-русский » өлеше 139–289 кә кадәр, ягъни 150 бит. Барлыгы –

8000 нән артык сүз теркәлгән Сүзлек алфавит тәртибендә төзелгән. Алтай теле сүзләре курсив белән кирилл графикасында бирелгәннәр. Сүзлекккә теркәлгән берәмлекләрнең күбесе эквивалент тәрҗемә һәм синонимнар кулланып тәрҗемә ителгәннәр. Мәсәлән, малина – агаш еиилек [с.52], мельница – теермән [с.53], сон – уйуку [с.110], благий – пуурсак, пийанду, якшылык [с.3] воля – тап, кун, енигу, еркин [с.12], мед – пол, мот, сотовый мед – кабагалу мот [с.53] һ.б. Фигыльләр рус телендә неопределенный, ягъни башлангыч формада, ә алтай телендә боерык фигыль формасында теркәлгән: спросить – сура [с.111], узнать –пел [с.126]. Алтайско-русский өлештә, беренчесеннән аермалы буларак, кайбер берәмлекләрнең аңлатмалары да бирелгән. Мәсәлән, арачы – сушенный творог, приготовляемый из подонков остающихся на дне котла, от молока, из коего приготовляется вино [с.139]. Кайбер сүзләрнең кайсы телдән алынганлыгы күрсәтелә: енчу (монг. енгге) – спокойствие, тишина [с.158], яс (Л.Б., тат.яз) – весна, яскы – весенний [с.171], калып (араб) – форма для литья [с.187]. “Б”, “Д” хәрефләренә башланган сүзләр юк. Гомумән алганда, бу сүзлек иң күләмле, иң зур, иң бай сүзлекләрнең берсе. Хезмәттәге материалларны В.В.Радлов үзенең танылган «Төрки халыклар әдәбиятыннан үрнәкләр»ләрендә дә файдалана [Кононов, 1974: 138].

Башкорт, азәрбайҗан, кыргыз (казах), төрек, сарт (үзбәк) телләренә кагылышлы сүзлекләрнең саны, татар теле сүзлекләре белән чагыштырганда, шактый аз. XIX гасырда бу телләргә караган бер- ике сүзлек кенә чыга.

XIX гасырда көнчыгышны өйрәнүдә төрек теле зур роль уйнаса да, бу чорга караган русча-төрекчә, төрекчә-русча сүзлекләр күп түгел. Бу өлкәдә беренче хезмәт итеп М.А.Казем-Бекның төрек телен өйрәнергә теләүчеләр өчен нәшер ителгән әсбабына кушымта итеп бирелгән, 3000 лексик берәмлектән торган русча-төрекчә (1854) сүзлекне әйтә алабыз. Сүзлек ике максатны күздә тотып төзелгән. Беренчедән, бу сүзлектә телдән һәм язма тәрҗемәдә иң еш кулланыла торган берәмлекләр теркәлгән, икенчедән, кулланманың алдагы өлешләрендә урнаштырылган текстлардагы сүзләр сүзлектә чагылыш таба. Сүзлектә һәр сүзнең үз номеры бар. Рус сүзе бирелә һәм төрек теленә тәрҗемә ителә. Тәрҗемә иткәндә сүзнең төрек телендә кулланыла торган барлык синонимнары

күрсәтелә. Төрек сүзләренең рус графикасындагы транслитерациясе дә бар. Мәсәлән, браво – мәрхабә (араб), афәрин (перс), машаллаһ (араб), бәрәкаллаһ (араб); светлый – реушен (перс), ачигъ, мюневверъ, айдин, горра (араб). Сүзлектә төрек телендәге көнчыгыш алынмалары, текстларда кулланылган ялгызлык исемнәре аерым бүлекчәләр итеп күрсәтелә. Ялгызлык исемнәре арасында шәһәр, әдәби әсәр, танылган шәхесләрнең исемнәре бар: Хулжент – имя главного города в нынешнем Фергане или Хоканд в Туркестане [с.8], Меджнун – имя героя поэмы [с.13].

Моннан тыш Л.Лазеревның «Турецко-татарско-русский словарь...с приложением краткой грамматики» дигән сүзлекчәсе билгеле. Бу сүзлек 1864 нче елда Мәскәүдә басыла. Л.Лазерев үзе Мәскәүдәге көнчыгышны өйрәнү институты профессоры, көнчыгыш телләре магистры була. Сүзлек гарәп алфавиты тәртибендә төзелгән, сүзләрнең кайсы телдән алынган булуы махсус күрсәтелә. Мәсәлән, аб – вода (п.) [с.1], сюд – молоко (т.) [с.91], теберсе – радуга (п.) [с.39], саһаръ – утро(а) [с.91], татармакъ –чесать (т) [ с.119]. Автор бу сүзлекне институт студентлары өчен төзи, сүзлеккә, нигездә, тамыр сүзләр генә теркәлгән. Автор билгеләп үткәнчә, сүзлектә ясалма сүзләр, синтаксик һәм этимологик аңлатмалар урын алмаган. Сүзлек Биянкиның «Төрекчә-французча сүзлегенә» һәм М.А.Казем -Бек кулланмасына нигезләнеп эшләнгән.

Башкорт теленең ике телле сүзлекләренең чишмә башында В.В.Катаринскийның лексикографик хезмәтләре тора. В.В.Катаринский Казан рухани семинариясендә һәм академиясендә укый, Н.И.Ильминскийның укучысы була. 1872-1875 нче елларда Чебоксар рухани училищесында күзәтүчесе вызифасын башкара, 1875 нче елдан Оренбург белем бирү округының татар, башкорт, кыргыз (казах) мәктәпләре инспекторы итеп билгеләнә. Шул чорда башкорт, казах телләренең беренче сүзлекләрен төзи, казахлар өчен рус теле дәреслеге яза [Кононов, 1974: 184].

В.В. Катаринскийның «Краткий русско-башкирский словарь» (1893) һәм «Башкирско-русский словарь» (1899) дигән хезмәтләре Оренбургта нәшер ителәләр. Башкорт галимнәре әйтүенчә, бу сүзлекләрдә башкорт теленең Оренбург өлкәсендә таралган сөйләшләренә хас лексик

берәмлекләр урын алган. «Краткий русско-башкирский словарь» (1893) сүзлегенә 2500 гә якын берәмлек теркәлгән, бит саны күрсәтелмәгән, ә «Башкирско-русский словарь» (1899) 237 биттән тора. Казан университеты китапханәсендә В.В.Катаринский сүзлекләре сакланмаган.

XIX гасырда кыргыз (казах) теленең икетелле сүзлекләре, иң беренче чиратта, гамәли ихтыяҗларны күздә тотып төзелгәннәр. Мисалга Ишмөхәммәд Букинның «Русско-киргизский (казахский) и киргизский-русский» (1883), В.В.Катаринскийның «Краткий киргизско-русский словарь» (1895), «Киргизско-русский словарь» (1897) һәм «Русско-киргизский словарь» (1899-1900) хезмәтләрен китерергә мөмкин. Китапханә фондларында В.В.Катаринский сүзлекләре сакланмаган. Ә Ишмөхәммәд Букин сүзлеге 1883нче елда Ташкентта С.И.Лахтин лито-типографиясендә басылып чыга. И.Букин үзен Төркестан укытучылар семинариясенең 4 класс укучысы дип күрсәтә. Сүзлекнең редакторы – семинария остазы Н.А.Воскресенский. Сүз башы мәкаләсендә автор болай ди: « Бу сүзлек Перов шәһәр училищесында һәм Төркстан укытучылар семинариясендә укыганда дәрестән буш вакытларда тупланган сүзләр җыелмасы. Бу сүзлек төгәлләнгән, тулы сүзлеккә дәгъва итми, ул кыргыз теле лексикасын беренче тапкыр системага, тәртипкә китереп туплауда беренче адым булып тора». Сүзлекнең гомуми күләме – 363 бит. Русча - кыргызча өлеш 181 бит, ә кыргызча – русча өлеше 178 биттән гыйбарәт. Сүзлек алфавит тәртибендә төзелгән. Башта рус сүзе, икенче баганада гарәп графикасында кыргыз сүзе, өченче баганада рус графикасында кыргыз сүзе бирелә: августъ – сунбля [с.1], весело – кызыкъ [с.27], душа – жанъ [с.57], масло – май [с.86].

Кыргызча – русча өлеш тә рус алфавиты тәртибендә урнаштырылган: агунъ – течение [с.185], айдаръ – коса [с.189], жети – семь [с.243] Сүзлектә барлыгы 6000 сүз тупланган.

Октябрь инкыйлабына кадәр үзбәк теле сарт теле дип атала. XIX гасырның 80 нче елларында үзбәк теленә багышланган грамматикалар, сүзлекләр дөнья күрә башлый. Бу өлкәдә В.Наливкин, С.Лапин кебек лексикографлар нәтиҗәле эшлиләр.

В.П.Наливкин офицер-артиллерист була. 1873 нче елда, хәрби училищены тәмамлаганнан соң, ул Ташкентта хезмәт итә, Наманганда яши. Шул чорда җирле халыкның гореф-гадәтләре белән кызыксына, телләрен өйрәнә башлый. Үзбәк, таҗик, гарәп телләрен бик яхшы үзләштереп, 1884нче елда Ташкентта ачылган рус-үзбәк мәктәбенең беренче укытучысы була. 1890 нчы елга кадәр Ташкент укытучылар семинариясендә үзбәк теле укыта. 1890-1895 нче елларда Сыр-дәрья, Фирганә, Сәмәрканд өлкәләренең мөселман мәктәпләре инспекторы булып эшли, Фирганә өлкә губернаторы ярдәмчесе булып хезмәт итә, II Дәүләт думасына депутат итеп сайлана [Кононов, 1974: 222].

1884 нче елда В.П.Наливкинның «Русско-сартовский и сартовско-русский словарь общеупотребительных слов, с приложением краткой грамматики по наречиям Наманганского уезда» дигән хезмәте дөнья күрә. Сүзлек Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Русча – сартча сүзлек 294, ә сартча – русча сүзлек 161 биттән тора, барлыгы 12200 гә якын сүз теркәлгән. Мәсәлән, ангел – феришта, балалайка – домбра, вторник – сейшамбе, топливо – отун, свекла – кызылча һ.с. Башка сүзлекләрдән аермалы буларак, бу сүзлектә сүзләрне тәрҗемә иткәндә автор синонимнарны бирергә тырыша. Мәсәлән, богатство – дуния, давлят [с.13], азаматъ – молодец, молодчина, взрослый [с.5., агыз – ротъ, отверстие, дуло [с.4] Сүзлекнең икенче өлешен төзегәндә В.П.Наливкинга хатыны М.В.Наливкина бик нык ярдәм итә.

Ә 1895 елда Сәмәрканд өлкәсендә тәрҗемәче булып эшләүче С.Лапинның «Карманный русско-узбекский словарь…» е нәшер ителә. Сүзлек – чын мәгънәсендә кесә сүзлеге. Аның форматы –10*15. Сүзлеккә Төркстан төбәгендә яшәүче җирле халык белән аралашу өчен иң кирәкле булган 4000 берәмлек теркәлгән. Хезмәт Сәмәрканд шәһәренең хәрби штаб типографиясендә басыла. Бу сүзлек төбәктә яшәүче рус халкына җирле халык теле – үзбәк телен өйрәтү, җирле халык белән аралашу максатыннан чыгып төзелгән. Ул кулланма әсбап характерында. Кереш өлештә зат алмашлыклары (ман, сан, ул, биз, сиз, алар), саннар: 1-10, 20-100, 11-99, көн исемнәре (джума, шинба), ай исемнәре (январь – далю, февраль – худ) акча берәмлекләре (сум, беш таш – 1 рубль), үлчәү берәмлекләре (8 верст – бир таш, 8 пудов – батман) атамамалары бирелә. Сүзлек алфавит тәртибендә төзелгән. Мәсәлән, абрикос- урюк, айва – бихи, бабочка –

купаляк, бабушка – катта ана, брать – алмак. Үзбәк сүзләре курсив белән бирелә. Автор үз хезмәтен В.Наливкин сүзлегенә нигезләнеп төзи.

XIX гасырда дөнья күргән ике телле сүзлекләргә кыска гына күзәтү ясалды. Күргәнебезчә, татарча- русча сүзлекләр, башка төрки тел сүзлекләренә караганда, чагыштырмача күп. Бу хәл сәяси, икътисади, иҗтимагый шартлар белән аңлатыла. XIX гасырда татар теле рус дәүләтенең көнчыгыш илләр белән булган мөнәсәбәтләрендә функциональ дәүләт теле, дипломатия теле булып хезмәт итә. Рус дәүләте исеменнән Кырымга, Төркиягә, Урта Азия халыкларына, Иран, Һиндстан, Монголиягә җибәрегән дипломатик документлар бу чорда башлычы татарча язылалар. Бу икетелле сүзлекләрнең күпләп чыгуына төп сәбәп була.

Шул ук вакытта татар сәүдәгәрләренең Россия империясе күләмендә киң җәелгән сәүдә эшчәнлеген истә тотарга кирәк.

Илнең иң танылган югары уку йортларында – Санкт-Петербург, Казан, Харьков университетларында, һөнәри белем бирү мәктәпләрендә, рухани академия һәм семинарияләрдә, гимназияләрдә татар теле фән буларак укыту да татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләргә аеруча зур ихтыяҗ тудыра.

## XIX гасыр татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрдә теркәлгән диалекталь сүзләр

Әдәби телнең лексикасын үстерүдә диалектлар һәм сөйләшләр ышынычлы чара булып торалар. Әдәби телнең лексикасын баетуда диалекталь сүзләрне файдалану тел үсешен аңлы рәвештә көйләүгә китерә. Күренекле тел галиме М.Зәкиев әдәби телнең лексик байлыгын арттыруда диалектларның ролен төгәл һәм ачык билгели [Зәкиев, 1965: 22].

Әдәби телнең язма һәм сөйләмә формасы арасындагы мөнәсәбәт бик борынгыдан башлана. Алар өчен бердәм ныклы нормалар булмаса да, теге яки бу этник төркемнең, халыкның гомумтел нормалары гасырлар

буе формалашып килә. Телнең бу ике формасын чагыштырып тикшерү нәтиҗәсендә милли әдәби тел өчен хас күренеш - әдәби тел белән диалектлар арасындагы мөнәсәбәт закончалыклары ачыклана.

Әдәби тел еллар үткән саен үзенең эчке ресурслары исәбенә, башка телләр белән үзара бәйләнеш һәм йогынты ясау процессында камилләшә, байый бара. Бу өлкәдә җирле сөйләшләр аеруча әһәмиятле, бетмәс-төкәнмәс чыганак булып торалар. Әдәби тел һәрвакыт алар белән тыгыз бәйләнештә тора, аларга йогынты ясый һәм, үз чиратында, алар исәбенә үсә һәм байый. Бу телнең сүзлек составына карый.

XIX гасырда татар халкы арасында мәгърифәтчелек хәрәкәтенең җәелүе, фән, мәдәният өлкәсендәге күтәрелеш һәм яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә матур әдәбият әсәрләре телендә зур үзгәрешләр барлыкка килә. XIX гасырда стильләр өлкәсендә киң күләмле функциональ үсеш башлана.  Анда тел нормаларының тагын да тотрыклылануы, милли үзенчәлекләрнең артуы һәм телнең эчке мөмкинлекләреннән, андагы төрле стиль алымнарыннан киң рәвештә файдалану күзәтелә.  Матур әдәбият әсәрләрендә сүзлек хәзинәсеннән файдалану элекке традицияләр һәм җанлы сөйләм үзенчәлекләре нигезендә бара. Бер үк мәгънәне белдергән синонимик сүзләрнең кулланылышы киң урын ала [ Хаков, 2003. С. 156].  Синоним сүзләр арасында алынма берәмлекләр дә, диалекталь лексемалар да шактый күп була.

“ ... Татар теленең беренче сүзлекләре  аерым сөйләшләргә нигезләнеп төзелә. Шундыйлардан Дамаскин [1785], И.Гиганов [1801, 1804], Н.П.Остроумов [1876,1892], А.Воскресенский [1894] сүзлекләрен күрсәтергә мөмкин,”-дип яза Л.Т.Мәхмүтова [ТТДС, 1969. С. 5]. Ул бу сүзлекләрнең сергач мишәрләре, Көнбатыш Себер татарлары һәм керәшен татарлары сөйләшләре лексикасына нигезләнеп төзелүен ассызыклый һәм алар тарихи яктан зур әһәмияткә ия булуын әйтә  [ТТДС, 1969:5].

Төрле иҗтимагый һәм җирле диалект вәкилләре яңа тел шартларында килеп эләгә, аларның сөйләме чит сөйләм йогынтысын кичерә  һәм үзләре дә башкаларның сөйләменә тәэсир итә. Мондый

төрдәге процесслар телдәге төрле яшәеш формаларының чикләре “йомшаруга” китерә. Бер яктан, зыялы сөйләмнең китапча формасы юкка чыга, икенче яктан, әдәби сөйләмнең түбәнге чикләре көндәлек аралашу теле белән кушылып китә.

Шунлыктан XIX гасырда дөнья күргән татарча – русча һәм русча - татарча сүзлекләрдә дилекталь лексика да урын ала. Аларны, максатка яраштырып, тематик яктан төркемләү һәм аларга аңлатма бирү кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

XIX гасырда дөнья күргән татарча – русча һәм русча-татарча сүзлекләрдә урын алган диалекталь сүзләрне тематик төркемнәргә бүлеп карау эш өчен уңышлы булыр.

**Табигать күренешләре, агач, хайван, кош-корт исемнәре**: мәсәлән,ان **аннъ** – зверь [Г., :36], اورعاجي **ургачы** – самка – [ Г., : 36], ايرعاقиргакъ – сомецъ [Г., : 36], كركادان **кяркаданъ** – единорогъ [Г., :36], يوشا **юша** – олень [ Г., :36], اق كياك **акъкиякъ** – дикая коза [ Г., : 36], اورشانуршянъ – ласка [ Г., :37],وارته **варте** – бурундук [ Г., :37], بوعا **буга** – поросъ [ Г., с. 37], سملك **симяляк** – овчарка [ Г., : 37]. **Ан** сүзенең “хайван” мәгънәсендә кулланылуы хәзерге телдә сакланмаган, бары тик куян, арыслан, болан, әрлән, йомран сүзләре составында борынгы ан тамыры чагылыш таба. Төмән өлкәсенең Күкрәнде районында **симәләк** “бик кечкенә эт ”, ә Тобол районында “овчарка” мәгънәсендә кулланыла [Тумашева: 190 ]. Әдәби телдәге **болан** сүзе урынына Төмән өлкәсенең Лайтамак төбәгендә **йуша** сүзе йөри [Тумашева: 87].

**Үсемлек атамалары:**تلبادان **тилбадан** (балан) [Г., :41],, قوزوق اعاچى **кузук агаце** (косык агач) [Г., :41], طورنا كوزچيا **турнакүзция** (мүк җиләге) [Г., :41], كونلك اعاچئ **күнлүк агаце** (ачаг төре)] [Г., :41], مشكه мәшкә [Г., :41], تره ك **тирак** –соснякъ [Г., :41], قاراعاي **карагай** – сосна [Г., :41], اعاج ته ت **теть агачь** – лиственница [Г., : 41], كوسوك اعاج **күсүкъ агачь** – кедр [Г., : 42], بايلان **байланъ** – пихта [Г., : 42],مستر **мыцръ** – ребина [Г., : 42] , موءل **муилъ** – черемуха [Г., : 42], قاراغاط **карагат** – смородина [Г., : 42], استحوان **астыхванъ** – малина [Г., : 42], يتبورون **етъбурунъ** – шиповник [Г., : 42], وسقات **уцкатъ** – жемолость [Г., : 42], لبله بل **ляплябель** – свекла [Г., : 48], زرته ك **зяртак** – морковь [Г., : 48], توراب **торобъ** – редька [Г., :

48.], قن **кынъ** – стручокъ [Г., : 480[,نانه **няня** – мята [Г., : 48], مارل **марулъ** – салатъ [Г., : 48], قوقنار **кукнар** – макъ [Г., : 48],اشزق **ашзык** – ящмень [Г., : 49],كروت **крють** – пшено [Г., : 49]. Күргәнебезчә, үсемлек атамалары аеруча үзенчәлекле булулары белән аерылып торалар**.** **Турнакүзция, мыцыр, астыган, уцкат, сәртәк** кебек берәмлекләр бары тик Себер татарлары сөйләшләре өчен генә хас сүзләр булып саналалар.

**Савыт – саба атамалары:** ашлавъ – корыто[Г., : 9 ], قابكير капкир – половник [Г., :.7 ], جمبر цамбяръ – обруч Г., : 9] , شبالا шабаля – ложка[Г., : 9], تلرجمل ترجومال тарчумалъ – утюгъ [Г., : 10]. **Бадьян** [деревянная чашка] – агачтан ясалган савыт мәгънәсен белдерә [О., 1876: 55], [О., 1892: 32]. Бадьян сүзе хәзерге көндә бары тик диалектларда гына сакланган. Мәсәлән, Казан арты, Әтнә сөйләшләрендә бадьян агачтан ясалган савыт мәгънәсен белдерә һәм шул ук мәгънәдә кулланышта йөри. Томбов сөйләшендә бадьян сүзен агачтан ясалган чиләккә әйтәләр [ТТДС, 1993:42]. **Тигяня** [начевки] – бербөтен агач кисәгеннән чокып ясалган озынча улак, савыт, тагарак мәгънәсен белдерә [О., 1876:171], [О., 1892: 195]. А.Воскресенский сүзлегендә бу сүз теркәлмәгән. Хәзерге әдәби телдә тигәнә сүзе сирәк кулланылышта йөри, ләкин диалектларда еш очрый. Мәсәлән, Ульяновск өлкәсендәге карсун, керәшен, мишәр сөйләшләрендә бу сүз тигәнә (тигәнәк) тегәнә вариантларында кулланыла [ТТДС, 1993: 297] һәм чокып ясалган улак, савыт мәгънәсен аңлата [ТТАС, III:12]. **Лагун** – мичкә мәгънәсен белдерә [О., 1876: 100], [О., 1892: 145]. Хәзерге әдәби телдә бу сүз кулланылмый, бары тик сөйләшләрдә генә очрый. Мәсәлән, стәрлетамак, хвалын сөйләшләрендә лагун (лахун) лоханка вариантлары кулланылышта йөри, ә керәшен сөйләшендә лагун варианты гына очрый һәм шулай ук, кечкенә агач мичкә мәгънәсен белдереп килә [ТТДС, 1993: 210]. **Лянгыз** – кечкенә чиләк мәгънәсен белдерә [О., 1892: 146]. Хәзерге әдәби телдә лянгыз сүзе кулланылышта йөрми, ләкин кайбер төбәкләрнең аерым сөйләшләрендә (чистай, чүпрәле, керәшен) актив кулланыла һәм, шулай ук, кечкенә генә су сала торган чиләк мәгънәсен аңлата [ТТДС, 1969: 294]. **Улак** – суны, сыек әйберләрне бөртекле нәрсәләрдән аеру өчен агачтан, таштан яисә калай кебек нәрсәләрдән чокырайтып ясалган озынча җайланма [О, 1876: 129], [О. 1892:216]. Улак сүзе хәзерге әдәби телдә кулланылмый диярлек,

ләкин мәләкәс, хвалын, чүпрәле сөйләшләрендә очрый [ТТДС, 1969:454] һәм шул ук мәгънәне ачыклап килә [ТТАС, III: 306].

Бу төркемгә тагын *каплама, табак кашыгы, саблаяк, бакрач, җәйләү, җилпуч* кебек сүзләр керә. **Каплама** - [Ю.: 83] сүзе урта диалектның минзәлә сөйләшендә бал, май, шикәр салып куяр өчен кулланыла торган капкачлы агач савыт дигән мәгънә белдерә [ТТДС, 1993: 129]. Әдәби телдә аш чүмече дигән сүзнең XIX гасыр сүзлекләрендә берничә төрле варианты теркәлгән Н.Остроумов **табак кашыгы** [О.,:185], К.Насыйри باقراچ бакрач [1878: 14] дип бирәләр. Югарыда күрсәтелгән сүзләр төрле сөйләшләрдә хәзер дә сакланганнар. Табак кашыгы казан арты - мамадыш [ ТТДС, 1993: 134], саплаяк - карсун сөйләшендә [ТТДС, 1993: 263], бакрач - каргалы, стәрлетамак [ТТДС, 1993: 43], казан арты, чистай сөйләшләрендә [ТТДС, 1969: 65] кулланылалар.

Савыт-саба атамаларына **җилпуч** - лоток [ Ю. 1888: 19], **кәрнәшә** - кузовок [О.1892: 111], **җәйләү** - чайное блюдечко [ О, 1892: 88], توستغان**тустаган** [Н., : 66], **чапчак** - кадка [ Ю, : 101], **кулаш**а - лоток [О., :131, Ю., : 77] кебек сүзләрне кертеп карарга була. Бу сүзләр төрле диалектларда кулланылалар, татар теленең диалектологик сүзлекләрендә урын алганнар. Кайберләре, мәсәлән, чапчак сүзе Кызыл Чапчак дигән топонимда сакланган [Населенные пункты..., :205].

Диалекталь берәмлекләр арасында **кешенең тән төзелешенә караган сүзләр** дә бар: تومنكي قبق **түмәнкә кабак** – подглазица [Г., 1801: 27 ] дигән тезмә сүз составындагы түмәнкә сүзе Көнчыгыш диалектта «түбән» дигән мәгънәдә кулланыла. Монда м ~ б тәңгәллеге күзәтелә [Тумашева, 220 ]. صاماى **самай** – виски [Г., 1801: 27] Көнчыгыш диалектта кулланыла [Тумашева, 184]. اورون **йаурун** – крыльца [Г. 1801, 28] Себер татарлары диалектларында иң башы, җилкә, кулбаш, арка мәгънәсендә йөри [Тумашева, 73]. Мишәр диалектында да очрый. ايرغاق **Иргакъ** – небо во рту [Г., 1801: 28] Көнчыгыш диалектларда аңкау мәгънәсен белдерә [Тумашева: 253]. تاغم **Тагым** – подколенье [Г., 1801: 29] Себер татарларында актив кулланыла [Тумашева: 199]. اشق **Ашик** – лодыжка [Г., 1801, 29] мишәр диалектында (Сергач сөйләше, Ләмбрә, Хвалын

сөйләшләре) тубык мәгънәсендә аңлата. [Тумашева: 35]. Чүпрәле сөйләшендә ашык уены, ашык уйнау дигән берәмлекләр составында сакланган. بويرج **бөйрәк** – почка [Г., 1801: 30] урта диалектта [Казан арты, Тау ягы сөйләшләре төркемендә] бөер мәгънәсен белдерә. يانباش **йанбаш** – холки, бедра [Г., 1801: 29] мәгънәсендә Көнчыгыш диалектларда оча сөяген, ايمام **Аймамъ** – горсть [Г., 1801: 28] Күкрәнде, Чебурга сөйләшләрендә уч мәгънәсен белдерә [Тумашева, 68: 19]. كوكسه **Күксә** - грудь [Г Г., 1801: 28]. Күксә/көгүс формаларында Көнчыгыш диалектларда күкрәк читлеге мәгънәсендә йөри [Тумашева: 167].Бу сүз Урта диалектның Минзәлә сөйләшендә дә очрый һәм аның нигезендә **күксәү** дигән яңа сүз дә ясалган [ТТДС, 1969: 281].كيكرتاك **Кикертәк** – горло [Г., 1801: 28; Тумашева, 98], چيرجقاق ساص **цыршкак сацъ** – кудрявый [Г., 1801: 27] Себер татарлары телендә кулланыла. [Тумашева: 245]. موجه **Моча** – туловище [Г., 1801: 29] Себер татарларында моца дип әйтелә һәм гәүдә мәгънәсен белдерә [Тумашева: 153].ايليك **Иликъ** – кость пустая [Г., 1801: 26] көнчыгыш диалектта йелек сүйәк – балтыр мәгънәсендә [Тумашева: 78] кулланыла. سمكروك **Симгирюкъ** – возгри [Г., 1801: 27] Себер татарлары телендә сиңгир дип әйтелә, сеңер мәгънәсендә аңлата. Монда мг~ң күчеше күзәтелә.

**Һөнәр атамалары**: اشمانجي **ашманцы** – хорчевник [Г., 1801: 35], قون **кун** – служанка Г., 1801: 33], اوي اعاسي **уй игасы** – хозяин [Г., 1801: 33], قورا طون **кура тун** – монах [Г., 1801: 33], انكسي **анксе** – охотник [Г., 1801: 34], Шуны искәртергә кирәк: әлеге төркемгә кергән сүзләр башка төркемнәрдәгеләрдән шактый ким һәм алар бары тик И. Гиганов сүзлегендә генә теркәлгән. Моны сүзлекләрдәге һөнәр атамаларының нигездә алынма берәмлекләр белән белдерелүе һәм гарәп, фарсы сүзләрен тәшкил итүләре белән аңлатырга мөмкин.

Тагын бер төркем **өй төзелеше, йорт-җир, урынга караган** сүзләр сүзләрдән гыйбарәт. Бу төркемгә: **чалгый, әндәрә, кәбен, кундыр, түмгәк, күпчек, тумыран, богыл, арча, лачинка, төшлек** һ.б. лексик берәмлекләр карый. **Кундыр** – кунакханә мәгънәсен белдереп килә [О., 1892: 94], [О., 1876:94]. Әдәби телдә кундыр сүзе очрамый, бары диалектларда гына кулланыла. Мәсәлән, “кундырга урнаштык” дип казан арты керәшеннәре сөйли [ТТДС, 1993: 142]. **Кяпчек** мендәр мәгънәсендә

килә [О., 1876: 97], [О., 1892: 139], [В., : 216]. Н.Остроумов сүзлекләрендә бу лексик берәмлек күбчек/күпчек вариантларында очрый һәм тышкы ягы чикмәгән яки челтәр тотылган кечкенә мендәр мәгънәсен аңлата [ТТАС, II: 304]. Хәзерге әдәби телдә бу сүз сирәк кулланылышта йөри, күбрәк диалектларда төрле фонетик вариантларда кулланыла. Мәсәлән, кама керәшеннәре сөйләшендә күпчек/күпчик, чүпрәле, ульяновск сөйләшләрендә/күпцек вариантлары бар [ТТДС, 1993: 207]. **Тумыран** киселгән утын мәгънәсенә ия [О., 1876:125], [О., 1892: 106]. Хәзерге әдәби телдә бу сүз сирәк очрый, ләкин диалектларда, керәшен сөйләшләрендә актив кулланыла [ТТДС, 1993: 307] һәм тупас итеп киселгән утын мәгънәсен аңлата [ТТАС, III, 164]. **Богол** печән кибәне мәгънәсен белдерә [О., 1876: 59], [О., 1892: 44]. Н.Остроумов сүзлекләрендә богол/богон вариантларында теркәлгән. **Богол** сүзе хәзерге әдәби телдә кулланылышта йөрми, ләкин диалектларда сакланган. Мәсәлән, мишәр диалектының кузнецк, хвалын, чүпрәле сөйләшләрендә бу берәмлек актив кулланыла [ТТДС, 1969: 90] һәм конус рәвешле эшләнгән печән кибәне мәгънәсен белдереп килә [ТТАС, I: 173]. **Лачынка** салам тияү өчен җайланма [О., 1876: 100], [О., 1892:145] хәзерге әдәби телдә дә, сөйләм телендә дә сакланмаган. Лачинка/лачынка сүзе бары сөйләшләрдә очрый, казан арты, минзәлә, бөре, урал татарлары сөйләшләрендә актив кулланылышта йөри [ТТДС, 1969: 251]. **Җилдергә** чаңгы мәгънәсен белдерә [О., 1876: 72]. Хәзерге вакытта җилдергә сүзе әдәби телдә дә, диалектларда да юк. Диалектологик, аңлатмалы сүзлекләргә дә теркәлмәгән. Сүзнең тамыры җил булырга тиеш. Татар телендә бик тиз дигәнне билдерүче җил кебек, җилдәй дигән сүзләр бар. **Отор** сыерлар ябу өчен киртә яки читән төшенчәсен аңлата [О., 1876: 106], [О., 1892: 159]. Сүзлекләрдә отар/утар вариантлары бирелә. Утар сүзен татар яссылыгында карасак, татар әдәби телендә утарның 1. загон, 2. хутор, усадьба, имение, татар теленең җирле сөйләшләрендә утар: 1. терлек ябу өчен киртә (минзәлә, зәй-каратай), ферма каралтылары (казан арты, мамадыш, минзәлә, ногойбәк) [ТТДС, 1969: 458]. Г.Ф. Саттаров хезмәтендә бу сүз шулай ук төрле сөйләшләргә бүленеп тикшерелә: 1. утар – иген чәчү өчен уратылып алынган җир (минзәлә), 2. умарталык (чүпрәле) [Саттаров, 1973: 59].

**Өй төзелешенә, йорт - җиргә, хуҗалыкка караган сүзләр** арасында да диалекталь берәмлекләр бар. Мәсәлән, **гюрнячя** [О., :58] сүзе рус телендәге горница мәгънәсен белдерә. Хәзер фонетик үзгәрешләр кичереп, гуринча вариантында мишәр диалектының темников, карсун, чүпрәле сөйләшләрендә кулланылышта йөри [ТТДС, 1993:80].

Әдәби телдәге **баз** сүзе XIX гасырда чыкан сүзлекләрдә берничә вариантта бирелә. Ш.Габделгазиз [Ш.Г.,: 20] һәм К. Насыйри [Н., : 130 ] نه وره پ **нәүрәп**, ә Н,Остроумов **пугарәп** [с.395] дип күрсәтә. Бу ике сүз дә рус телендәге погреб сүзеннән килеп чыккан. Пугарәп вариантында позицион үзгәрешләрнең эпинтеза төре күзәтелә. Бу сүз мишәр диалекты сөйләшләрендә актив [ТТДС, 1969: 251]. Нәүрәп сүзе мәләкәс, чистай, тау ягы, Оренбург мишәрләре сөйләшләрендә баз мәгънәсендә кулланыла [ТТДС, 1969:324]. Ә мишәр диалектының чүпрәле сөйләшендә нәүрәп һәм пугарәп сүзләре параллель рәвештә кулланылалар. Бу сүзенең мишәр диалекты сөйләшләрендә нүгрәп варианты да бар [ТТДС, 1969:325 ]. Пүгарәп - нәүрәп вариантларында /г / ~ /w/ күчеше чагыла. Бу күчеш - кыпчак телләре өчен хас күренеш, һәм кыпчак язма истәлекләрендә бу фонетик үзенчәлек систамалы төс ала [Хаков, 1994: 111].

А.Троянский сүзлегендә چه چهره **чәрәчә** - крыльцо [Т.,т.1:463] берәмлеге теркәлгән. Бу сүз хәзерге әдәби телдә юк, ул бары урта диалектның минзәлә сөйләше Әгерҗе урынчылыгында гына сакланган һәм мунча өй алдын белдерә. Диалектологик сүзлекләрдә теркәлмәгән. Бу бик борынгы сүз, Мәхмүт Кашгарый сүзлегендә үк булган һәм өй алды мәгънәсен белдергән. Бу хакта М.Ногман болай дип яза : "Элек лампа урынына чыра яндырганнар. Алдан әзерләп куелган чыралар өй алдында сакланган. Шуннан өй алды — чырача дип аталган булырга тиеш". XIX гасыр сүзлекләреннән бу сүз Л.Будагов сүзлегендә урын алган [Ногман:103].

**Йорт** сүзенең татар телендә берничә мәгънәсе бар: 1. бина, 2. гаиләә, 3. ил, туган җир, 4. ишек алды [ ТТАС, т.1: 461]. Н.Остроумов [О.,1876:81] сүзлегендә йорт сүзе **двор** (ишек алды) мәгънәсен белдерә. Шул ук мәгънәдә йорт, ишек алды, сүзе мишәр диалекты сөйләшләрендә бик актив кулланыла [ ТТДС, 1993:115]. Чолан сүзе Ш. Габделгазиз

[Ш.Г. :20] сүзлекләрендә کجه ن که **кәҗәнкә** дип бирелә. Бу сүз минзәлә, тау ягы сөйләшләрендә актив кулланылышта йөри [ТТДС, 1993:199]. Бу тематик төркемгә **җарка** [ О.1876:70, О. 1892:189], **уймыр** [ О.1892:214], **бөгәджә** [О.1892:44] кебек сүзләрне кертергә мөмкин Әлеге сүзләр хәзер күбрәк казан арты керәшеннәре сөйләшендә сакланганнар.

Сүзлекләрендә чагылыш тапкан өй төзелеше, йорт-җир, урынга караган сүзләр арасында күбесенчә XIX гасырда актив лексикада урын алган, хәзерге вакытта кулланылыштан төшеп калган һәм аерым диалектларда, сөйләшләрдә генә очрый торган тел берәмлекләре шактый икәне ачык күренә.

Сүзлекләрдә теркәлгән диалекталь сүзләр арасында **кием-салым, тукыма һәм бизәнү әйберләрен** белдергән берәмлекләр дә бар. Мәсәлән, **бишбармак** - перчатки [ Ю. 1900:31],قاتا **ката**- валенки [ Н.1878:84], تيره ك **тирәк** -узор [ Н.1878:45], **сырга** - серьги [ О. 1892:182], **чөлкә** - чулки [ К. Т-Р.С:.6], **күтәрмә** - каблук [ Ю. 1900:14], تنبراك **түнбрак** – платье [Г, 1801:16],يقتا **екта** – халат [ Г, 1801:12], طامبال **тамбал** – штаны [ Г, 1801:17], **ишим, пайпак** – чулки [ Г, 1801:17], **атуз** – ичиги [ Г.,1801:17], **кябысъ** – башмак [Г., 1801:17], كلباش **кялябаш** – дивичий калпак [Г.,1801 : 18], كاكته **кяктя** – прикопотки, носки к чулкам [ Г.,1801 :18], قطاط **кытат** – китайка [ Г., 1801:18],مقمال **макмал** – бархат [ Г., 1801:18], سراوس **сыраус** – подтяжка на волосах [ Г.,1801:18], **кортя-** фуфайка [ Ю, 1900:80], نيلت**нильт** - лента [ К.Н.,1878:78 ], اينهك **айнәк** очки [ Г., 1801:3], **мун җака** – ожерелье [О., 1876:150 ], **тамакса** – ожерелье [ О., 1876:188 ], **чачак** – девичий головной убор [ О., 1876: 225], **сягатьлямя** – часы [ Ю., 1900:56]. Кием-салым атамалары арасында этнографизмнар булуын да күрәбеә.

Бу төркемгә караган **кәйтан, олтан, астар, кәвеш** һ.б. сүзләр дә күренә. **Кәйтан** укадан ишелгән бау мәгънәсенә ия [О., 1876: 99], [О., 1892: 144]. Н.Остроумов сүзлекләрендә кайтан/кәйтән/гайтан вариантлары теркәлгән. Бу сүз хәзерге әдәби телдә кулланылышта йөрми, бары тик аерым сөйләшләрдә генә сакланган. Мәсәлән, казан арты керәшеннәре, лаеш, урал арты татарларында гайтан/кәйтән вариантлары файдаланыла һәм бау мәгънәсен белдереп килә [ТТДС, 1969:211]. **Астар**

– хатын кызлар баш киеменең эчке ягын белдерә. Бу сүз әдәби телдә сирәк кулланыла, ләкин күп кенә сөйләшләрдә бар. Мәсәлән, казан арты, балтач, камышлы сөйләшләрендә баш киемнең эчке ягы мәгънәсен белдерә [ТТДС, 1969: 30]. Р.К.Рәхимова астар сүзен тастар формасында бирә һәм “бизәкле сөлге сыман яулык” – дип аңлата [Рәхимова, 1983: 79]. Ф.Баязитова аңлатуынча, астар (тастар) сүзе мишәрләрдә һәм әстерхан татарларында баш киеме астыннан бәйләп калдыра торган яулык төшенчәсенә ия [Баязитова, 1997: 118]. **Олтан** – аяк киеменең табан формасындагы аскы өлеше дип шәрехләнә [О., 1876: 106, О., 1892: 157]. Бу берәмлек хәзерге әдәби телдә дә кулланылышта йөри, ләкин казан арты, камышлы сөйләшләрендә аеруча актив [ТТДС, 1993: 235], [ТТАС, II: 467]. **Кәвеш** – калын күннән, калын олтанлы итеп тегелгән борынгы аяк киеме мәгънәсенә ия [О., 1876: 100], [О., 1894: 4]. Элегрәк кәвешнең башын өскә таба кәкре һәм очлы итеп теккәннәр. Кәвеш, гадәттә, читек яки тула аяк өстеннән киелгән. Шунлыктан бу ике атама парлы сүз формасында, җыйма мәгънәдә дә кулланыла: читек-кәүеш, кәүеш-читек [Рәхимова, 1983: 94] һәм кунычсыз йомшак аяк кием мәгънәсендә йөри [ТТАС, II: 247]. Кайбер сөйләшләрдә, мәсәлән, ульяновск сөйләшендә йорт эшләрен башкарганда кия торган аяк киеме галош үзенә кәүеш атамасын алган.

**Ката** сүзе - тепекәй [ ТТДС, 1993:132], эчкен [ ТТДС, 1969:193], чөлкә (рус теленнән чулки) сүзе - казан арты, гәй, зәй керәшеннәре [ТТДС, 1969:505], ә күтәрмә сүзе тау ягы, мәләкәс, камышлы сөйләшләрендә [ТТДС, 1969:287] очрый.

**Ашау-эчү, ризык атамаларын** белдергән сүзләргә сүзлекләрдә аеруча зур урын бирелгән. Бу төркемгә: **дурчмак, корт, бөкмә, кортым, айбагар, талкан** кебек лексик берәмлекләр керә. **Дурчмак** сүзе Н.Остроумов сүзлекләрендә түгәрәк ак ипи мәгънәсенә ия [О., 1876: 67], [О., 1892: 62]. Дурчмак сүзе әдәби юк, ләкин күп сөйләшләрдә актив лексик берәмлек ролен үти. Сөйләшләрдә сүзнең мәгънә төрлелеге күзәтелә. Мәсәлән, алабуга керәшеннәре, мамадыш сөйләшләрендә дучмак, минзәлә сөйләшендә дүречмак, тархан сөйләшендә дүртпочмак вариантлары бар [Хайрутдинова, 1993: 38]. Бер төбәктә дурчмак – эче камырдан ясалган калач мәгънәсен аңлатса, икечесендә - эченә баллы

әйбер кыстырып пешергән дүрт читле камыр ризыгы дигәнне белдерә. **Корт** – сыр мәгънәсен белдерә [О., 1876: 92], [О., 1892: 127], ә хәзерге әдәби телдә корт - сөтне әкрен янган утта озак кайнатудан алынган ашамлык, кызыл эремчек мәгънәсен белдерә [ТТАС, II: 161].ә XIX гасыр сүзлекләрендә теркәлгән мәгънә [корт – сыр] минзәлә сөйләшендә очрый һәм кабартма зурлыгында әвәләп киптереп ясалган сөт азыгы мәгънәсен аңлатып килә [ТТДС, 1993:139]. **Айбагыр** әдәби телдә көнбагыш дигәнне белдерә [О., 1876: 64], [О., 1892: 6] һәм бу сүз XIX гасырда бик актив кулланылышта була, чөнки шушы чор сүзлекләренең күбесендә айбагыр сүзе теркәлеп калган. Хәзерге әдәби телдә айбагыр сүзе кулланылмый. Ләкин аерым төбәкләрдә, аеруча мишәрләрдә, айбагар/айбагыр фонетик вариантлары чагылыш таба [ТТДС, 1993: 21]. Мәсәлән, мәләкәс, хвалын сөйләшләрендә айбагыр сүзе актив кулланылса, чистай, чүпрәле, ульяновск сөйләшләрендә айбагар фонетик варианты кулланылышта йөри [ТТАС, I: 29]. **Талкан** [О., 1876: 118], [О., 1892: 187] керәшен сөйләшендә күбрәк таңкал, темников, нурлат тоңкал дип йөртсәләр, чистай сөйләшендә талкан/толкан формасы кулланылышта йөри һәм сүсле үсемлекнең сабагын уып, салам кылчыгын аеру дигән мәгънәне аңлата [Хайрутдинова, 1993: 139]. Талканны бодай һәм карабодай онын кыздырып, тозлы су кушып ясыйлар.

XIX гасырда чыккан сүзлекләрдә ашау- эчү, ризык атамаларын белдергән диалекталь сүзләргә тагын اچيتقي **ачыткы** - квас [Ш.Г.1893 :14], بوككا ن **бөккән** - пирог [ Ш.Г..1893:13, В.1894:327, К.Т-Р.С.1880:16, Н.1878:33], **гердә** - булочка [ К.Т-Р.С.1880:16, О.1876:64], **дучмак, дурчмак** - лепешка [О.1876:67], له وهش **ләвәш** - сладкий пирог [Н.1878:100], **тәбикмәк** [О.1892:211], **кашык чумары** - клецки [Ю.1900:135], **җуача** - оладьи [О.1892:82], **пирмәңке** - пилмән [ К.Т-Р.С. 1888:13], **саум** - свадебный гостинец [О.1892 :172], **бирамаш** - праздничное кушанье [Т. 1833:197],چاي لوج **ләух чәй,** кирпичный чай [Н. 1878:100]پيراش **пираш** - пиво [Т. 1835:255], سهر ته كرچيمه **керчемә** - мед варенный, сладкий [Т. т.2:154], **сәртә**- суп, бульон [Г., 1801:14; Т. 1833:570],سوسو **цюцю** - сусло [Г., 1801:15], ايشتي **эштей** - щи [К.т.р.с. 1880:17; Г., 1893:13], قرندق **кырындык**- крошка [ К.Н, 1978:88 ],

صعونسогон – угощение с руки [ О, 1892:175 ] кебек сүзләрне өстәргә мөмкин.

Сүзләрнең берничәсенә генә аңлатма биреп үтик: **гердә** сүзе татар теленә фарсы теленнән кергән. Урта диалект сөйләшләрендә кулланыла. Тау ягы - норлат, казан арты - лаеш сөйләшләрендә вак ипи, хәергә бирер өчен кечкенә итеп әвәләнә торган ипи дигәнне, ә казан арты - керәшен сөйләшләрендә мәет күмгән көнне яки үлгәннәрне искә алганда пешерелә торган вак күмәч дигән мәгънә белдерә [ ТТДС, 1969:117.] **Саум** сүзе казан арты, тау ягы, зәй-керәшеннәре, камышлы, мәләкәс, чистай, чүпрәле, мордва-каратай сөйләшләрендә туйга алып бара торган күчтәнәч, азык-төлек буларак та кулланыла [ТТДС, 1969:353].

Н.Остроумов сүзлегендә урын алган صعون **согон** – угощение с руки [ О, 1892:175 ] сүзе Себер татарлары сөйләшләрендә сакланган, ләкин мәгънәсе аз гына үзгәргән. Д.Г.Тумашева хезмәтендә бу сүзнең ике мәгънәсе теркәлгән: 1. ашарга теләү, нәфесләнү, 2. ашап кую [ Тумашева: 191].

Сүзлекләрдә чагылыш тапкан азык-төлек, ризык атамаларының диалекталь вариантлары хәзерге вакытта урта диалектның Казан арты-керәшен, мишәр диалектының кузнецк, темников сөйләшләренә карый.

Сүзлекләрдә **туганлык атамаларын** белдергән берәмлекләр аерым игътибарга лаек. Боларга түбәндәге берәмлекләр керә: طوطا **тута** - тетка [Н., 1878:35], **печкө** – свекровь [О.1892:161], **беием** - свекровь [О.1876:58., 1892:39], پيچكەچە **печкәчә**-своячина [Н. 1878:98], **җанагай** - деверь [ К.Т-Р.С.1888:6], **тутай** - сестрица [ О.1876:125], **тыума** - потомок [О.1876:126], **олан** - сын, дитя [О.1876:105], **бикәч** - супруга [ Ю. 1900:57]. **Бикәч** сүзе чүпрәле сөйләшендә яшь хатын [ ТТДС, 1993 :54] мәгънәсендә кулланыла. Бу сүз М.Юнусов сүзлегендә **бикәч түшәге** [Ю. 1900 :57] сүзтезмәсе итеп бирелә. Әлеге сүзләрнең күбесе керәшен сөйләшләрендә кулланылалар.

**Дядяй** – агай, ага мәгънәләренә ия [О., 1876 : 62; О., 1892 : 53]. Бу лексик берәмлек татар әдәби телендә кулланылмый, ләкин сөйләм телендә актив файдаланыла [ТТАС, I : 318]. Тау ягы керәшеннәре

сөйләшләрендә дад’у/дядяу формасы [Баязитова, 1997 : 90], кузнецк, сыргач, темников, мамадыш сөйләшләрендә дәди/дәдәй вариантлары очрый [ТТДС, 1969 : 131]. **Тютей** апа мәгънәсен белдерә [О., 1876 : 125; О., 1892 :206]. Бу лексик берәмлек бары тик диалектларда гына сакланган. Түтәй сүзенең сытытай/сытый/тутай/тәтә вариантлары иске татар әдәби телдә дә актив кулланылышта йөргән. Тау ягы керәшеннәре сөйләшендә т’ит’у/тейтау (тути) вариантлары кулланыла [ТТДС, 1996 : 450], [Баязитова, 1997 : 91]. Тутай – Тутаев фамилиясендә һәм Татарстанның Апас районындагы Тутай авылы атамасында сакланган [Саттаров, 1990:73]. **Печкә**– кайнана [О., 1876 :108, О., 1892 :161] сүзе XIX гасыр сүзлекләрендә бик еш очрый. Хәзерге әдәби телдә бу сүз юк, ләкин аерым сөйләшләрендә сакланган. Мәсәлән, керәшен сөйләшендә печкә сүзе актив кулланыла һәм кайнана мәгънәсен белдерә. Тау ягы керәшеннәре печкә дип кайнанага эндәшәләр, печкәчә дип иренең сеңлесенә мөрәҗәгать итәләр [Баязитова, 1997 : 92]. **Олан** – бала [О., 1876 : 105, О., 1892:156] диалектларда, сөйләшләрдә олан/огълан вариантларда килә, малай, егет мәгънәсен аңлата. Бу сүз күбрәк мишәр диалектында, минзәлә сөйләшләрендә очрый [ТТДС, 1969:326] һәм мәгънә төрлелеге белән аерыла. Әзербәйҗан - оглан, төркмән - олган, төркистан - оглан, төрек телендә бу лексик берәмлек **хезмәтче** мәгънәсен аңлата; гагауз - оглан, казах - улан, алтай - удлан, татар - олан (кечкенә бала) дигән фонетик вариантлары бар. Борынгы язмаларда бу лексик берәмлек бала мәгънәсендә йөргән. Ан – күплек санының архаик күрсәткече дип санала [Покровская, 1961 : 15-16]. Хәзер олан дип өлкән кешеләр зурларны якын итеп мөрәҗәгать иткәндә дә әйтәләр [ТТАС, II, 466]. Оглан > огул - Чыңгыз хан нәселенең хан тәхетенә утырмаган әгъзаләре титулы. Шушы сүзгә нигезләнгән Чукрый олан (Чукри Уланова) авылы да бар [Саттаров, 1990:83]. **Тыума** нәсел мәгънәсен белдерә [О., 1876 : 126, О., 1892 :208]. Бу лексик берәмлек хәзерге көндә бары тик сөйләшләрдә генә кулланыла. Мәсәлән, хвалын сөйләшендә тума варианты сакланган [ТТДС, 1969 : 425]. Бу сүз нәсел, токым, тегe яки бу урыннан туып үскән, шуннан чыккан кеше мәгънәсен аңлата [ТТАС, III : 163].

**Кәбен** [бракосочетание] - өйләнешү дигән мәгънәдә килә [О., 1876 : 99, О., 1892 : 193]. Кәбен сүзе борынгы заманнарда ук фарсы теленнән

кергән дип карала [Баязитова, 1986 : 157] ләкин хәзерге вакытта диалектларда, мишәр, глазов татарлары сөйләшләрендә [ТТДС, 1969 :266] актив лексик берәмлек булып йөри һәм чиркәүдә христиан дине йоласы буенча укылган никах мәгънәсен белдерә [ТТАС, II:247]. Кәбен сүзе татар халкының борыңгылыкны сакланган, аерымланып калган төркемендә: нократ, пермь татарлары сөйләшләрендә дә кулланыла һәм мөселман дине буенча никахлашуны белдерә. Башка телләрдә кәбен сүзе: фарсы телендә (кабин) законлы, кумык телендә (гебин) – хатын, ногайбәк керәшеннәре сөйләшендә - кәбенгә керү – чиркәүдә никахлашу мәгънәләрен белдерә [Баязитова, 1992 :27].

Шулай ук **кешене төрле яктан характерлый торган берәмлекләрне** дә күрсәтеп үтәргә була. Мәсәлән, **канчык** – кычкырып көлүче кеше мәгънәсен белдерә [О., 1876 : 84, О., 1892 : 109]. Бу сүз казан арты, мамадыш керәшен сөйләшләрендә очрый [ТТДС, 1969 : 191]. Ике мәгънә белдереп килә: 1. кычкырып көлүче кеше, 2. хәрәкәтләнгәндә тыйнаксыз, ир-атның күзенә ташланырга торучан хатын-кыз [ТТДС, 1993, 156]. [О., 1876, 80, О., 1892, 97]. Хәзерге әдәби телдә **ирдавай** [О., 1876: 80, О., 1892: 97] сүзе юк, ләкин аерым диалектларда сакланган. Мәсәлән, казан арты керәшен сөйләшендә бу лексик берәмлек еш кулланыла [ТТДС, 1993: 101]. **Чирляшкя** [О., 1876:134, О., 1892:228] әдәби телдә бик сирәк очрый, ләкин күп кенә сөйләшләрдә актив кулланыла. Мәсәлән, алабуга керәшен, чүпрәле сөйләшләрендә бу лексик берәмлек аеруча еш кулланыла[ТТДС, 1969: 486]. Чирләшкә дип тиз авыруга сабышучы, яки авырып ятучы кешегә әйтәләр [ТТАС, III:431].

Тупланган материал тагын бер төркем аерырга мөмкинлек бирде. Бу - диалекталь **сыйфатлар, рәвешләр, ярдәмлек сүзләр** төркеме. Мәсәлән, **заматта** - бик тиз [ О.1892:90], **салпы** - вялый [ О.1892:170], **орон** - секретно [ Ю. 1900:27], **урынтын** - тайно [ О.1892:219], **сартын** - по-поводу [ О.1892:171], **умаза** - ненасытный [ О.1892:216], **рыскаллы** - счастливый [Кр.1888:45], **кенәген** - вчера [О.1876:90], **кана** [ О.1892:109], **ару** - чистый [ Ю. 1900:7], **алчак** - приветливый [ Ю. 1900:8]. Заматта сүзе замат формасында казан - арты Әтнә, камышлы, мәләкәс, чистай сөйләшләрендә кулланыла [ТТДС, 1969:136]. Салпы сүзе татар телендә "салпы ягына салам кыстыру" фразеологизмында кулланыла. Ә тау ягы

сөйләшләрендә салпылык “тынычлык, әкренлек” мәгънәсен белдерә [ТТДС, 1969:360]. Орон, урынтын сүзләре бер тамырдан. Бу сүзләр мишәр диалекты сөйләшләрендә актив кулланылалар. Яшерен, яшертен дигән мәгънә белдерәләр [ТТДС, 1969:328]. Рыскаллы - бәхетле сүзенең синонимы. Рыскал - гарәп алынмасы. Хәзер бу сүз мишәр диалектының сергач, урта диалектның минзәлә сөйләшендә бар. [ТТДС, 1969:354]. Алчак сүзе казан арты, бәрәңге, глазов, минзәлә, тау ягы сөйләшләрендә ачык йөзле, якты чырайлы, ягымлы дигән мәгънәдә йөри [ТТДС, 1969:36]. Сүзләр арасында умаза, уңкыт сүзләре дә кызыклы. Хәзерге татар телендә без бу сүзләрнең мәгънәсен рус теленнән кергән обжора сүзе белән белдерәбез. Ә XIX гасырда бу мәгънәне югарыда күрсәтелгән умаза, уңкыт сүзләре белән белдергәннәр. Умаза зәй керәшеннәре сөйләшендә сакланып калган [ТТДС, 1969:454], ә ункыт [Ю,1900:28] гәй, красно-уфим сөйләшләрендә бар [ТТДС, 1969:331]. Ширеп – нык, таза мәгънәләрен белдерә [О., 1876: 177, О., 1892:236, В., 1892:115] һәм керәшен сөйләшләрендә генә сакланган [ТТДС, 1969 :516]. Аран аз дигән мәгънәгә ия [О., 1876: 50]. Казан арты, мамадыш, тау ягы сөйләшләрендә аран, аран-аран, аранрак сүзләре сөйләмдә очрый һәм көч-хәл белән, көчкә дигән мәгънәләрне белдерә [ТТДС, 1993: 30]. Ә чуваш телендә актив лексика составына керә. Алгасак – назлы мәгънәсен аңлата[О., 1876: 48, О., 1892: 13] һәм казан арты, минзәлә, этнә сөйләшләрендә кулланыла [ТТДС, 1969: 34], ягымлы, ачык чырайлы мәгънәләрен белдерә [РТС, 1997: 239]. Жабалдаш – түбән дигән мәгънәдә Тау ягы сөйләшләрендә кулланыла [ТТДС, 1958: 217]. **Терекле** – көчле, тиз, томат мәгънәләрен белдерә [О., 1876:212, О., 1892: 194] һәм урал татарлары бу сүзне яратып кулланалар [ТТДС, 1969: 407]. **Туктумал** – сәбәпсез дигән мәгънәгә ия [О., 1876:124], Н.Остроумовның 1892 нче елгы сүзлегендә **тикмәгә** [б.124] дигән мәгънә белдереп килә. Туктумал сүзе хәзерге әдәби телдә сакланмаган, ә диалектларда бар. Мәсәлән, казан арты, мамадыш сөйләшләрендә тикмәгә, керәшен сөйләшләрендә туктумал вариантлары [ТТДС, 1969: 412] һич көтмәгәндә, сәбәпсез, дуамаллап мәгънәләрен белдереп килә [ТТАС, III:96]. Мишәр диалектының Чүпрәле сөйләшендә **тиктымалга** дигән фонетик варианты кулланыла. **Бежгяк -** брюзгливый мәгънәсен белдерә [О., 1876: 56, О., 1892: 42, В., 1894: 14]. Хәзерге

вакытта бу лексик берәмлек борынгы диалекталь сүз дип карала һәм минзәлә сөйләшендә очрый. Аңлатмалы сүзлектә бежгәк сүзе теркәлгән һәм сукранучан дигән төшенчәне аңлата [ТТАС, I: 143]. **Чаман** – ялкау мәгънәсен белдерә [О., 1876: 133, О., 1892: 224]. Татар әдәби телендә бу лексик берәмлек кулланылмый. Глазов, казан арты, керәшен сөйләшләрендә очрый һәм шул ук төшенчәне белдереп килә [ТТДС. 1969:474], [ТТАС, III: 407]. **Уяз** – килбәтсез, каты күңелле дигән төшенчәләрне белдерә [О., 1876:131, О., 1892: 222]. Н.Остроумов һәм А.Воскресенский сүзлекләрендә уяз/үзән вариантлары теркәлгән. Әдәби телдә бу лексик берәмлек кулланылмый, ләкин каргалы сөйләшендә сакланган һәм шул ук мәгънәне аңлата [ТТДС, 1993: 327]. **Арыу** – чиста мәгънәсен белдерә [О., 1876: 50], ә Н.Остроумовның 1892 нче елга сүзлегендә ару/здорова ли ты? / саумы син [О.,1892: 21] мәгънәсен ачыклый. Арыу/ару – борынгы төрки сүз. М.Кашгари сүзлегендә, әрмән – кыпчак текстларында да күрсәтелгән [Абдуллин, 1974:123]. Арыу/ару сүзе күбрәк изге, гөнаһсыз дигән мәгънәләрдә кулланылган. Соңга таба ул «яхшы, чиста» төшенчәсен аңлаткан. Ару сүзе шулай ук, исәнләшү, хәл сорашу сүзе булып та тора: Арыумысыз сез? Арыу әле, бик арыу гына (яхшы) – ногайбәк сөйләшендә [Баязитова, 1997: 88]. Бу лексик берәмлек хәзерге көндә дә күп сөйләшләрдә сакланган һәм төрле мәгънәләрдә килә. Казан арты керәшен сөйләшендә арыу-сау, саумы, златоус сөйләшендә ару-яхшы, чүпрәле сөйләшендә чиста, бай мәгънәләрен белдерә [ТТДС, 1993: 32]. Билтәк - тотлыга торган дигән мәгънә белдерә [О., 1876:59], [О., 1892: 42]. Хәзерге татар әдәби телендә бу лексик берәмлек сирәк кулланыла, ләкин сөйләшләрдә еш очрый һәм билтәк/биртәк фонетик вариантларда файдаланыла. Мәсәлән, хвалын, чүпрәле сөйләшләрендә бу сүз актив һәм сөйләшендә кимчелек булган кеше дигәнне аңлата [ТТДС, 1969: 86]. **Жалан** һәрвакыт мәгънәсендә [О., 1876: 69, О., 1892: 69]. чүпрәле, хвалын сөйләшләрендә, жалан/ялан вариантлары мамадыш, минзәлә, керәшен сөйләшләрендә актив кулланыла һәм шул ук мәгънәне аңлата [ТТДС, 1892:383], [РТС, 1997: 83].

**Аерым предметларга караган** сүзләргә **сүрәлекә, бөгелҗә, билге** кебек лексик берәмлекләр керә. **Сүрякя** балык тоту өчен кулланыла торган җайланма мәгънәсен белдерә [О., 1876, 117, О., 1892, 183]. Мишәр

диалектының чүпрәле сөйләшендә сөрәкә сүзе Н.Остроумов сүзлегендә теркәлгән мәгънәдә кулланыла, ә диалектологик сүзлектә бу мәгънә теркәлмәгән. **Богялҗә** божра төшенчәсен белдерә [О., 1872, 44]. Пермь татарлары сөйләшендә бу лексик берәмлек актив кулланыла һәм ябылып, йомылып җитмәгән божра, яки ярым божра формасындагы әйбер мәгънәсен аңлата [ТТАС, I: 213], [ТТДС, 1993: 65].

Сүзлекләрдә, исемнәр, сыйфатлар, рәвешләр белән бергә, диалекталь фигыльләр дә теркәлгән. Бу төркемгә: **олак, камаш, чагай, борлок, айгылда, чурла, арыуландыр, тумыр** лексик берәмлекләре керә. Фигыльләр бирелешендә билгеле бер форма кулланылмый, алар төрле заман формасында, төрле затта бирелгәннәр. **Олак** чыгып китү мәгънәсен белдерә [О., 1892: 156, О., 1876: 105]. Олак сүзе диалектларда, сирәк булса да, әдәби телдә дә кулланыла [ТТАС, 1979: 466]. Керәшен, пермь татарлары, чистай сөйләшләрендә бу лексик берәмлек актив чагылыш тапкан. Ләкин олак сүзен куллануда мәгънә төрлелеге күзәтелә: керәшен сөйләшендә олак - югалту, пермь татарлары сөйләшендә ияләшү, мамадыш сөйләшендә әллә кая китеп югалу мәгънәләрен ачыклый [ТТДС, 1993: 239]. **Борлок** – уйлану төшенчәсен белдерә [О., 1892: 46]. Н.Остроумовның 1876 сүзлегендә бу сүз теркәлмәгән. Борлок сүзе хәзерге әдәби телдә төшеп калган, бары тик бу лексик берәмлекне керәшеннәр сөйләшендә очратырга мөмкин [ТТДС, 1969: 70]. **Айгылда** – кычкырып көлү төшенчәсен белдерә [О., 1876: 42], [О., 1892: 6]. Аңлатмалы сүзлектә бу сүз турнылда “сөйләм телендә генә кулланылып, кешнәп көлү төшәнчәсен аңлаткан лексик берәмлек булып килә” диелә [ТТАС, 1977: 29]. Айгылдау сүзе бик күп сөйләшләрдә чагылыш тапкан. Мәсәлән, тары татарлары сөйләшендә айгылдау – каты, яшьсез көлү мәгънәсен белдерә [ТТДС, 1948: 10]. Бу лексик берәмлек гайгылдау дигән аваз ияртеменнән [-г] авазның төшеп калуы нәтиҗәсендә ясала. Себер татарлары сөйләшендә айгалу/айгылдау – озак маташу төшенчәсен белдерә [Тумашева, 1992: 18]. **Арыуландыр** – сафландыр, чистарт, чистарын, әйбәтлән дигән мәгънәләрне белдереп килә [О., 1876:50], [О., 1892: 177]. Арыу/ару/аруландыр диалекталь лексик берәмлек дип карала [ТТАС, I: 73] һәм казан арты, чүпрәле, минзәлә, златоус, алабуга сөйләшләрендә кулланылышта йөри [ТТДС, 1993: 32].

XIX гасырда дөнья күргән сүзлекләрнең күбесе әдәби тел сүзлекләре итеп төзелгәннәр Ләкин, шулай булуга да карамастан, сүзлекләрдә, бүгенге көн күзлегеннән караганда, диалекталь сүзләр дә шактый урын алган. Моның сәбәпләрен берничә дәлил белән ачыклап була: сүзлек авторлары К.Насыйри, Г.Шиһабетдин, С.Кукляшев, М.Юнысов хезмәтләрендә үзләре яшәгән төбәк өчен хас булган сүзләрне теркәгәннәр. Бәлки алар бу сүзләрне әдәби норма дип уйлаганнардыр, ә бәлки, аңлы рәвештә, җирле вариант буларак теркәгәннәрдер. Миссионер авторлар Н.Остроумов, А.Троянский, А.Воскресенский диалекталь сүзләрне, бигрәк тә керәшен сөйләшләренә караган лексик берәмлекләрне, үз хезмәтләрендә гарәп-фарсы алынмаларыннан котылу өчен файдаланганнар, чөнки алар үзмаксат итеп керәшен сүзләрен әдәби әйләнешкә кертүне куйганнар.

И.Гиганов сүзлекләрендә Көнчыгыш диалектларга хас булган берәмлекләр өстенлек итә. Бу, әлбәттә, авторның яшәү һәм эшләү урыны белән аңлатыла.

XIX гасыр татарча-русча һәм русча - татарча сүзлекләрендә теркәлгән диалекталь сүзләр җирле сөйләшләрнең берәмлекләрен активлаштыралар, әдәби телнең лексик байлыгын арттыралар. Сүзлекләрдә диалекталь сүзләрнең урын алуы аларның төрле төбәк халкына адресланган булуы да һәм бу сүзлекләрдән төрле диалект һәм сөйләш вәкилләренең куллану ихтималы күздә тотып төзелүне раслый. XIX гасырда әле әдәби тел һәм диалектлар чиге билгеләнә генә башлый, кайбер сүзләр кулъязма сүзлекләрдә дә теркәлгән була, авторлар аларны караган булырга мөмкин.

Күргәнебезчә, XIX гасыр ахырында дөнья күргән сүзлекләрнең лексикасында кием-салым, бизәнү әйберләрен белдергән байтак сүзләр тупланган. Аларның күпчелеге бүгенге көндә пассивлашкан, ләкин татар теленең аерым сөйләшләрендә актив лексик берәмлек буларак чагылыш табалар.

Без XIX гасырда дөнья күргән сүзлекләр ярдәмендә моннан бер гасыр элек булган диалекталь үзенчәлекләрне күз алдына китерә алабыз. Алар хәзерге диалектологик сүзлекләрдә чагылыш тапканнар. Бу хәл сөйләм теленең чагыштырмача әкрен үзгәрүенә дәлил булып тора.

Телдә сакланып калган диалекталь сүзләр һәм үзенчәлекләр телебезнең бик борынгы чорларын, төрки халыклар, кабиләләр, этник төркемнәр арасындагы бәйләнешләрне чагылдыралар. Вакытлар үтү белән диалекталь берәмлекләр, кулланылыш сферасын киңәйтеп, гомумхалык теленә күчәләр, әдәби телгә үтеп керәләр.

## XIX гасыр сүзлекләрендә сүзләрне тәрҗемә итү алымнары

“Сүзләрне тәрҗемә итү принциплары сүзлекләрнең төзелү максатлары белән бәйле. Әгәр сүзлекләр татар теле лексикасын беренчел үзләштерүне күздә тотып төзелгән булса, анда рус сүзләре татарчага, гадәттә, атама юлы белән (сүзгә-сүз) тәрҗемә ителә” [М. Ногман, 1969:59]. Танылган галим В.П. Берков болай дип яза: “Тәрҗемәи сүзлекләрдә тәрҗемә ителә торган берәмлекләргә төгәл эквиваленты бирелергә тиеш” [В. Берков, 1973, :21]. Гомумән, лексикография теориясендә иң идеаль алым – сүзне бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә эквивалент куллану. Галимнәр эквивалент тәрҗемәнең берничә төрен аералар: формаль эквалент, мәгънәви эквивалент һәм ситуацион эквивалент. Формаль эквивалент очрагында ике телдәге мәгънә бер үк төрле формалар белән белдерелә. Мәгънәви эквивалент бер үк мәгънәнең төрле телләрдә төрле ысуллар ярдәмендә күрсәтелүе белән характерлана, ә ситуацион эквивалент булганда, бер ситуация төрле формалар, мәгънәләр белән тәкъдир ителәләр [В. Гак, 1974: 9-10].

Тәрҗемә иткәндә сүз сайлау иң мөһим эш булып санала. Ике тел сүзләре арасында төрле мөнәсәбәтләр урнашырга мөмкин. Бер төркем сүзләргә икенче телдә тулысынча туры килә торган бер генә берәмлек була. Алар даими эквивалент дип аталалар. XIX гасырда татарларга рус теле, русларга татар телен өйрәтү максатыннан төзелгән сүзлекләрдә сүзләр, нигездә, даими эквивалент белән тәрҗемә ителәләр. Бу берәмлекләр җыйнак, аңлаешлы һәм ике телдәге сүзләрнең мәгънәсе бер – берсенә тулысынча туры килә. Мәсәлән: صالقون салкын – холодный [Н. 1878:70],يووشلامك юешләмәк – мочить [Н. 1878:120], اول аулъ – деревня [Г.,

1801:1], ورام урам – улица [Г., 1801:1], تاقتا такта – доска [Г., 1801:1], бура – сруб [Ю., 1900:33], тау – гора [Ю., 1900:38],тукран – дятель [Ю., 1900:44], сукыр – слепой [Ю., 1900:50], сра – пиво [Ю., 1900 :50],باقا бака – лягушка [Н., 1878:20], баур – печень [О., 1892:37], кабак – тыква [О., 1892:102], باشاق башакъ – колосъ [Н., 1878:29], تامچى тамчы – капля [Н., 1878:39], چچك чячякъ – цветокъ [Н., 1878:53] кәгазь – бумага [О. 1892:103], киле – ступа [О. 1892: 119], козгон – ворон [О., 1892: 123], اچقچ ачкыч – ключ [Н., 1878:11] һ.б.

Күргәнебезчә, югарыда саналган сүзләр бер сүз, ягъни татар сүзләренең рус телендәге эквивалентлары белән тәрҗемә ителгәннәр.

Лексикографның төп максаты – тәрҗемәи сүзгә мөмкин кадәр төгәл эквивалент табу. В. П. Берков үзенең «Слово в двуязычном словаре» исемле хезмәтендә ( Таллинн, 1977) түбәндәге параметрларны аерып чыгара: 1) сүзнең лексик мәгънәсе, 2) сүзнең грамматик параметры, 3) стилистик параметр, 4) бәяләү параметры, 5) ешлык параметры, 6) ареал параметры, 7) ассоциатив параметр һәм 8) сүзнең мәдәни мәгънәсе.

«Ике телле лексикографиядә сүзнең лексик мәгънәсенең бүленеше турында ике төрле караш яши», - дип яза В. П. Берков [1973: 51]. Автор ике карашны аерып, аларның уңай һәм тискәре якларын күрсәтә. Беренче карашның нигезендә түбәндәге фикер ята: барлык ике телле сүзлекләрдә сүзләрнең мәгънәви структурасы һәм аңлатма сүзлектә бирелгән мәгънәви структура белән тәңгәл килергә тиеш. Икенче караштa исә, сүзләрнең лексик мәгънәләренең бүленеше тәрҗемәи эквивалентлар санынннан гыйбарәт.

Мисал өчен, Н. И. Фельдман, бу карашларның беренчесенә таянып, үзенең «Об анализе смысловой структуры слова в двуязычных словарях» исемле хезмәтендә түбәндәге фикерне ассызыклап үтә: «Ике телле сүзлекләрдә сүзләрнең бирелеше механик рәвештә тагылган тәрҗемәләрдән һәм аңлатмалардан хасил булмый, ә сүзләрнең мәгънәви структурасын бирүдән тора» [Фельдман: 11]. Әйе, сүзнең мәгънәви структурасының бирелеше тел өйрәнүчеләргә чит телне җанлы һәм тулы күзаллау өчен ярдәм итә. Шуның белән бу караш ике телле сүзлекләрдә

чит телне өйрәнү өчен гамәли белешмә кыйммәтен генә түгел, ә фәнни җыентык ролен үти.

Икенче караш вәкилләре исә, ике телле сүзлекләрнең асылын аларның тәрҗемә эшендә гамәли белешмә ролен башкаруда күрәләр. Аның төп бурычы – тел өйрәнүчеләргә сүзлек составы элементларының аерым эквивалентларын тапшыру дип билгелиләр.

Димәк, бу ике карашның үзенчәлекләре түбәндәгедән гыйбарәт: беренчеләре – сүзнең мәгънәви структурасын белми торып, аерым тәрҗемәи эквивалентларны эффектив рәвештә куллану мөмкин түгел; икенчеләре – дөрес һәм урынлы итеп тәрҗемәи эквивалентларны куллану өчен, сүзнең мәгънәви структурасын белү зарури.

Күзәтелгән барлык фактларга йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: сүзнең ике телле сүзлекләрдә бирелеше бары тик сүзнең мәгънәви структурасы яссылыгында кхрсәтелергә тиеш. Мәсәлән, Н. Остроумов сүзлегеннән китерелгән мисаллар: Бат – погрузиться, увязнуть, впасть (о глазах) [О., 1876: 56], Баш – голова, начало, начальник [О., 1876: 57], бер башы – одна голова; въ одиночку [О., 1876: 57]; сыу башы – истокъ реки [О., 1876: 57]; туй башы – распорядитель пира [О., 1876: 57]; ут башы – головня горящая [О., 1876: 57]; җан башы – предплечье [О., 1876: 57]; җул башы – провожатый [О., 1876: 7]. Бала – дитя, балам (ласкательное), дитятко мое; балачага ребятишки вообще [О., 1876: 55]; Бармак – палец [О., 1876: 56];. Название пальцев: баш бармак – большой палец [О., 1876: 56]; имян бармак – указательный палец [О., 1876: 56]; урта бармак – средний палец [О., : 1876: 56]; атсыз бармак – безъимянный палец [О., 1876: 56]; чянячя бармак – мизинецъ [О., 1876: 56].

Димәк, алда әйтелгәннәрдән чыгып, без түбәндәге нәтиҗәгә килә алабыз: XIX гасырда дөнья күргән татарча – русча, русча – татарча сүзлекләрдә сүзгә – сүз, ягъни эквивалент белән тәрҗемә итү алымы киң кулланылган. Бу сүзлекләренең лөгатьлекләрендә тормышның төрле тармакларына караган сүзләр, исемнәр, сыйфатлар гына түгел, хәтта фигыльләр һәм абстракт мәгънә белдергән атамалар – сүзгә-сүз тәрҗемә ителгәннәр. Бу төр сүзлекләргә И. Гиганов, К. Насыйри, А. Троянский, А. Воскресенский, Н. Остроумов тарафыннан төзелгән сүзлекләр карый.

Сүзгә – сүз, ягъни эквивалент белән күчерелгән сүзләр, гадәттә, дөрес тәрҗемә ителгән. Алар җыйнак һәм аңлаешлы. Һәрбер сүзлектә дә оригинал һәм тәрҗемәи телләренең үзенчәлекләре сакланып, сүзләргә тулы һәм төгәл эквивалент тәрҗемә бирелгән.

Шулай итеп, XIX гасыр лексикографлары сүзлекләрендә сүзләрнең эквивалент тәрҗемәләрен биреп, телебезне баеталар, үстерәләр һәм камилләштерәләр.

Кайбер алынмаларны татар теленә тәрҗемә иткәндә, эквивалент сүз булмаганда, аңлатма бирү алымы да сүзлекләрдә чагылыш таба. Рус сүзенең мәгънәсен ачыкларга кирәк булган очракта, бу сүзләрне аңлату өчен сүзтезмәләр, җөмләләр белән аңлатма бирелә. Мәсәлән, К.Насыйри үзенең 1892 елда чыккан сүзлегендә рус һәм европа сүзләрен аңлатма бирү юлы белән тәрҗеиә итә: акробат – аркан өстендә уйнаучы [Н., 1892: 5]; амнистия – гөнаһны багышлау, гафу [Н., 1892: 6]; ампутация – адәмнең бер әгъзасын кисеп алу [Н., 1892:6]; аппетит – ашыйсы килү [Н., 1892:6]; апрель – сәнәи шәмсиянең дүртенче ае [Н., 1892: 6]; аллея – агач арасында юллар [Н., 1892: 5]; актриса – тамашаханәләрдә уйнаучы хатын [Н., 1892: 5]; букет – бер тотым гөл [Н., 1892: 10]; вагон – тимер юл арбасы [Н., 1892: 11]; гармонический – хуш тавышлы [Н., 1892: 14]; громоотвод – яшен кайтаргыч [Н., 1892: 16]. К. Насыйри фикеренчә, рус алынмаларын татар теленә сүзгә – сүз тәрҗемә итү күпчелек очракта уңышлы булып чыкмый, чөнки тәрҗемә ителгән сүзләр рус телендәге сүзнең төп һәм төгәл мәгънәсен белдерә алмый.

А. Воскресенский үз сүзлегендә рус сүзен – рус сүзе белән тәрҗемә иткәндә, җәяләр эчендә сүзләрнең татарча аңлатмаларын биреп бара. Мәсәлән, награда – награда (яхшы хезмәт өчен бирелгән бүләк) [В.,1894: 137]; лазарет – лазарет (чирле солдатлар ята торган өй) [В.,1894:118]; лагерь – лагер (солдатлар җәй көне өйрәнә торган төшләр) [В., 1894: 117]; банк – банка (акчаны үстерергә сала торган төш) [В., 1894: 3]; адресъ – адрес (язу өстенә кешегә язганны күрсәтү) [В.,1894: 1]; аптека – аптека (дару ясап бирә торган өй) [В.,1894: 2]; магнитъ – магнит (тимерне тарта торган таш) [В., 1894: 125]; василискъ – василискъ (зур елан) [В., 1894: 17]; вакса – вакса (итек чистарта торган нәстә) [В.,1894: 17]; кабинетъ –

кабинет (укымышларның эшли торган бүлмәсе) [В., 1894: 98]; казинетъ – кежинет (материя) [В., 1894: 98]; каникулы – каникулы (эшләми торган вакыт) [В., 1894:100]; кила – кила (чир) [В.,1894: 102]; кедръ – кедр (җимешле агач) [В., 1894: 102]; набатъ – набат (халыкны җыяр өчен чан кагу я әйбер шакылдату) [В., 1894: 136]; сайка – сайка (каты камырдан салган бодай күмәче) [В.,1894: 287]. Болай тәрҗемә итүне телдә эквивалект таба алмау белән аңлатып була. Шулай ук сүзләрне әлеге тәртиптә тәрҗемә итү мәгънәләрне яхшырак аңларга мөмкинлек бирә.

Телдәге үзенчәлекле реалийләрне, ягъни һәр халыкның мәдәнияте, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәте, йолаларына бәйле рәвештә барлыкка килгән лексик берәмлекләрнең мәгънәләрен ачыклаганда, тәрҗемә ителә торган телдә төгәл эквиваленты булмаганда, икетелле сүзлекләрдә сүзләрне аңлату юлы белән тәрҗемә итү алымы да киң таралган. XIX гасыр сүзлекләре арасында бу алым Н.Остроумовның “Татарско – русский словарь” (1892) хезмәтендә төп принцип булып тора. Автор һәр сүзгә диялек аңлатма бирә, сүз ясалыш үзенчәлекләрен күрсәтә, мәсәлән: **әрәмә** – низкое место (по большей части около реки) густо заросшее преимущественно жирек, а также и другими деревьями балан, миляш, шоморт; -лек тоже самое: [О. 1892:22], **каймак** – густыя сливки снимается съ варенаго молока ([любимое у крещеных татаръ угощение) [О. 1892:104], **нагышъ** – узоры, вышитые шелкомъ на платке , назначаемомъ для женского наряда...[О. 1892:152], **какы** – болотное растение, употреблямое бочарами для законопачивания бочек [О. 1892:106];

Н.Остроумов сүзлегенең тагын бер үзенчәлеге итеп сүзләргә тасвирлама биргәндә, төрле аңлатмалар, мисаллар китерүне әйтергә кирәк. Икенче төрле әйткәндә, автор сүзләргә лингвистик иллюстрацияләр бирә. Мәсәлән: **калак** – лопатка (деревянная, а также и часть тела), мешалка, чайная ложка: сука калагы палици (часть сохи) [О. 1892:106]; **кашка** – съ белымъ пятном на лбу (лошадь) [О. 1892:115]; **курт** – крутой, тяжелый характером, ул бик курт кеше – он очень крутой человекъ [О. 1892:132]; **тиле** – глупый, дурак: тилегә тюря жук – дураку начальства нет; тиле таш җыя – дурак камни собираетъ, тиленен эше кара бозау теше – дело глупаго – зубы чернаго теленка; тиле белян табма да

оляшмя дя – съ дуракомъ и не находи и не дели; тиле белян донья тулган – мир полненъ дураками [О. 1892:196].

К.Насыйри ислам дине өлкәсенә караган сүзләрне һәм терминнарны аңлату юлы белән тәрҗемә итә. Без аны түбәндәге мисалларда күзәтәбез: حاج хаджъ – путешествие в Мекку [Н. 1878:56], حرام харамъ – запрещенный шаригатом [Н. 1878:56], حلال халяль – дозволенный шаригатом [Н. 1878:56], حديث хадисъ – предание, слова, речи пророка относительно религии [Н. 1878:56], خطبه хотбя – речь в похвалу Бога, пророка, асхабов во время полуденного намаза въ пятницу (җомга хотбәсе) [Н. 1878:57]; حور хур – черноглазая райская девица [Н. 1878:56], زكوة зекать – сороковая часть всего имущества, отдаваемая въ милостыню [Н. 1878:62], صحابه сахабя – тотъ, кто успелъ беседовать съ пророкомъ Мухаммедомъ [Н. 1878:70], مريد моридъ – ученикъ какой-либо аскетической общины [Н. 1878:102], منبر минбяръ – кафедра хатыба въ мечети [Н. 1878:104].

Сүзләрне аңлатып бирү юлы белән тәрҗемә ителгән берәмлекләрне А. Воскресенский сүзлегендә дә очратабыз: профессор – академия белән университетта өйрәтүче [В., 1894: 253]; каникул – эшләми торган вакыт [В., 1894: 100]; лупа – зурайтып күрсәтә торган пыяла [В., 1894: 123]; библиотека – җыелган кенәгәләр куя торган төш [В., 1894: 8]; инспектор – бер эшне карап торучы [В., 1894:93]; крестьян – чукындырылган кеше, иген игүче, авыл кешесе [В., 1894: 113]; патриот – туган җиренә бирелгән кеше [В., 1894: 192]; отмыкать – ач, отмычка – ачкыч (ачкычка охшатып ясаган ачкыч) [В., 1894: 185]; праздник, празднество – бәйрәм, праздничные припасы – бәйрәмнек, бәйрәмгә кирәкле әйберләр, праздновать – бәйрәм ит [В., 1894: 234]; ящикъ – жящик, сандык, арҗә (маленький, в виде сундучка с покрышкой и без нее), алаб (большой, продолговатый коробъ для хранения хлеба), тартма (небольшой, продолговатый, деревянный, узенький ящичек, может быть выдвижной), ящикъ у стола –өстәл тартмасы, өстәл астындагы тартма [В., 1894: 370].

Н.Остроумов христиан дине өчен хас берәмлекләргә тасвирлама бирә: **питрау** – Петровъ день, праздникъ, чествуемый особенно крещенно – татарами мамадышскаго и лаишевскаго уездовъ [О. 1892:162],

**теяберсенъ** – это слово произносится на поминкахъ по умершемъ человеке съ присоединениемъ его имени при этом вкушаютъ блины, кашу [О. 1892:195]. М.Юнысовта ислам диненә бәйле берничә берәмлек кенә аңлату юлы белән тәрҗемә ителгән: **мяктебъ** – татарская начальная школа [Ю. 1900:92], **мядряся** – татарская школа, стоящая выше мектеба [Ю. 1900:92], **муазинь** – мусульманское низшее духовное лицо [Ю. 1900:92]. Әлеге терминнарның, дин өлкәсенә караган сүзләрнең шул рәвешчә тәрҗемә ителүе авторларның сүзлек төзү принципларын яхшы белүе турында сөйли. И.Гиганов сүзлекләрендә бу принцип бөтенләй чагылыш тапмый.

С.Кукляшев сүзлегендә дә сүзләрне тәрҗемә иткәндә кызыклы аңлатмалар очрый. Мәсәлән, وماچ у**мач** – мучной бульон [К., 1859:19], دلدل**дөлдел** – конь Алия, 4 арабского халифа [К., 1859:49 ], ايبالتا **айбалта** – топор с длиннымъ топорищем, которымъ киргизы бьютъ волков [К., 1859:24], تبتر **типтәр** – типтярь, название народа, которой проживаетъ в Оренбургской губернии [К., 1859:31], ايسطرشنا **эстаршина** – начальник юрты или нескольких деревень [К., 1859:21], صور بازاري **сур базары** – базаръ, торгъ сурками в мае месяце при г. Оренбурге [К., 1859:62].

XIX гасыр татар лексикографиясенең нигезен русча – татарча, татарча – русча сүзлекләр тәшкил итәләр. Сүзлекләр санының артуына татар халкының рус халкы белән күптәнге иҗтимагый – сәяси, икътисади, мәдәни бәйләнешләре, татар теленең Идел – Урал буе һәм Көнбатыш Азия халыклары арасында иркен кулланылуы тәэсир итә.

## XIX гасыр сүзлекләрендә сүзләрне синонимнар кулланып тәрҗемә итү алымы

Тел мәдәниятенә ия булу телнең сүзлек байлыгын өйрәнүдән башка бара алмый. Ә телнең сүзлек байлыгы ул – сүзләрнең мәгънәләрне тулы һәм төгәл бирә алуы, шулай ук яңа сүзләр ясауга сәләте. Телнең сүзлек

байлыгы, үз чиратында, телнең синонимнарга бай булуы белән билгеләнә. Димәк, сүзлек хәзинәсе бай булган тел синонимнарга да бай була.

Һәр телнең үз лексик – семантик системасы бар. Чөнки һәрбер телдә үзенә генә хас булган үзенчәлекләр күзәтелә. Бу аерымлыклар түбәндәге шартларга нигезләнгән: төрле телләрдә сүзләр санына, һәр сүзгә беркетелгән мәгънәләр эчтәлегенә, сүз мәгънәсенең күләменә, сүзнең функциональ үзенчәлекләренә һәм кулланыш сфераларына. Бу исә лексикограф алдына, һәр телне яхшы белү өстенә, яңа таләпләр, яңа мәсьәләләр куя. Мәсәлән, бер телнең лексик берәмлегенә тәңгәл икенче телдән дә лексик берәмлек тапмаган очракта, телнең башка үзенчәлекләреннән файдалана белү. Бу очракта – ике телнең дә синонимик байлыгыннан файдалана белү күздә тотыла.

Шуңа күрә кайбер сүзләрне тәрҗемә иткәндә, мәгънәсен ачыклаганда сүзлек авторлары синонимнар кулланалар. Бу аңлашыла да, чөнки: «Мәгънәләр төсмере – сүзнең семантик үзенчәлеге, мәгънәне, төшенчәне барлыкка китерүче билгеләр берәмлеге ул. Сүзнең мәгънәсендә төп һәм өстәмә мәгънәләр була. Сүз мәгънәсендәге өстәмә билгеләр – синоним сүзләрне бер – берсеннән аера торган мәгънә төсмерләре алар. Сүзләрнең мәгънәсенә карамый, бәлки сөйләмдә теге яки бу стилистик максатка хезмәт итүенә, функциясенә генә карый торган төсмер сүзнең өстәмә төсмере була. Димәк, синоним сүзләр – уртак төшенчәгә йөрүче мәгънәдәш сүзләр», - дип яза Ш. Ханбикова үзенең хезмәтендә [Ханбикова,1980: 4].

Тел белемендә синонимнар мәсьәләсенә күп кенә лингвистлар, язучылар һәм галимнәр зур әһәмият биргәннәр. Синонимнарның, телне баетыр өчен, фикерне төгәл һәм камил җиткерер өчен, сүзләрне үз мәгънәсендә кулланыр өчен ифрат дәрәҗәдә зур йогынты ясавын билгеләделәр.

XIX гасырда иҗат иткән лексикографлар да сүзлекләрендә сүзләрне синонимнар кулланып тәрҗемә итү алымын читләтеп узмаганнар. Мисал өчен, И. Гиганов (СПб., 1801), А. Троянский (Казан, 1833 – 1835), К. Насыйри (Казан, 1878), М. Юнусов (Казан, 1900) кебек танылган лексикографларның сүзлекләрендә синонимнар кулланып тәрҗемә итү

алымы киң чагылыш тапкан. Мисал өчен, И. Гигановның сүзлегендә (СПб., 1801) тәрҗемә итеп китерелгән синонимнарның саны, нигездә, икедән артмый. Мәсәлән: هلق هراوید дивара, кала – стена [Г., 1801: 3], هسیلک رصانم монасиръ, кялися – церковь [Г., 1801: 3], وشراج رازاب базаръ, царшү – рынокъ [Г., 1801: 4], تبیک ناکود кибитъ, дюканъ – лавка [Г., 1801: 4], ترامع اذب бяна, аймаратъ – строение [Г., 1801: 5], وبای کولروا ябувъ, үрълюкъ – крышка [Г., 1801: 6], قامجوب شویم миюшъ, буцмакъ – уголь [Г., 1801: 6], نابدرن غساب جی баскыцъ, нардыбанъ – лесница [Г., 1801: 6], وکزوک هذیآ кюзкю, айня – зеркало [Г., 1801: 6], غارچ ماشد шамъ, цырагъ – свеча [Г., 1801: 8], چاکیت قایا аякъ, тигацъ – чашка [Г., 1801: 9], هزیذ وکنوس сюнгү, няйзя – копье [Г., 1801: 11], میلچ ازناق канза, чилимъ – трубка курительная [Г., 1801: 12], رکشد دنق кандъ, шакяръ – сахаръ [Г., 1801: 15], جاس قاقشرچ цыршканъ, цацъ – кудри [27], رطاخ رکف хатеръ, фикиръ – мысль [Г., 1801: 30], نمرد توق جوک күцъ, күвватъ, дарманъ – сила [Г., 1801: 30], کیرچ رکشل ляшкаръ, цирикъ – войско [Г., 1801: 34], بیبط رگوراد дарюгаръ, табипъ – лекарь [Г., 1801: 35], حوف جنوس сюнүчь, фярхъ – радость [Г., 1801: 35], سوماذ تایوا үятъ, намысъ – стыдъ [Г., 1801: 35], کنآ ناویح хайванъ, аикъ – зверь [Г., 1801: 36], قفشد ریکنیا инкыръ, шафакъ – сумерки [Г., 1801: 57] һ.б.

Сүзлектә синонимнар бирелүнең төп сәбәбе – әлеге хезмәтнең җирле муллалар тарафыннан тикшерелеп, өстәмәләр, төзәтмәләр кертелүендә. И.Гиганов, сүзлекнең титул битендә, сүзлекне муллалар тикшерде, дип искәртә. Шул вакытта муллалар, җирле сөйләш берәмлекләре янына татар телендә кулланылган гарәп-фарсы алынмаларын да теркәп баралар. Шул сәбәпле синонимик рәтләр барлыкка килә. Югарыда бирелгән мисалларга таянып, без түбәндәге фактны раслый алабыз: И. Гиганов сүзлегендәге синонимнар әдәби тел берәмлекләре һәм диалекталь сүзләрдән гыйбарәт. Автор әдәби вариант белән бер рәттән җирле сөйләшкә хас лексик берәмлекләрне дә терки: голубь – каптяръ, кябутяръ, кюгярцюнъ [Г., 1804: 98]; рябина – мыцыръ, миляшъ [Г., 1804: 522]; сыръ, творогъ – ацыгяй, иримцикъ, куртъ [Г.,1804: 592] һ.б.

И. Гиганов тарафыннан төзелгән сүзлектә исем, сыйфат һәм фигыль генә урын тапкан. Синонимнар буенча теоретик хезмәтләрдә зур гына

бәхәсләргә дучар булган ярдәмлек һәм модаль сүзләр мәсьәләсе бу сүзлекләрдә гамәли яктан чишелмәгән.

Һәр телнең үз лексик-семантик системасы булу сәбәпле, һәрвакытта да сүзне икенче, бигрәк тә кардәш булмаган, телнең бер сүзе белән генә аңлатып биреп булмый. Шуңа күрә кайбер сүзләрне тәрҗемә иткәндә, мәгънәсен ачыклаганда сүзлек авторлары синонимнар кулланалар. Кайбер очракларда сүзгә икенче телдә берничә контекстуаль эквивалент туры килә. Сүзлекләрдә тәрҗемә итеп китерелгән синонимнарның саны, нигездә, ике, ә кайбер вакытта өч, дүрт, биш берәмлектән торган синонимик рәтләр дә очрый. Мәсәлән: ایسسلك эсселек – жар, зной [Н., 1878: 17], بورون борын – нос, клюв [Н., 1878: 32], مه غلوم يتمك мәгълүм итмәк – извещать, объявить [Н., 1878: 103], تونچ тыныч – спокойный, тихий [Н., 1878: 76], اما әмма – но, однако [Н., 1878: 19], غير гайре – иной, прочий [Н., 1878: 79], قايغورماق кайгурмак – печалиться, горевать [Н., 1878: 86], سيبيركي себерке – веник, метла [Н., 1878: 63], قالعا калга– крепость, замок [Г.,1801:8],بشيک пишикъ – зыбка, люлька [Г.,1801:8], كيس киис – войлокъ, кошма [Г.,1801:.8], اوق укъ – пуля, стрела [Г.,1801:11], قولاقشهкулакша – шапка съ ушами, малахай [Г.,1801:17], ايچمک ицмякъ – исподки, варежки [Г.,1801:17], طشماق тышмакъ – верхонки, мохнатыя руковицы [Г.,1801:17], كاكته кякта – прикопотки, носки къ чулкамъ [Г.,1801:18], اصلام асламъ – ростъ, процентъ [Г.,1801:34], طولانا тулана – боярка, боярышникъ [Г.,1801:43], خاتا хата – грехъ, беззаконье [Г.,1801:54], эш – дело, работа [Ю., 1900: 15], ачелекъ – горечь, кислость [Ю., 1900: 15], талау – ограбление, грабежъ [Ю., 1900: 40], тамыр – корень, жила [Ю., 1900: 42], джмагать – семья, общество [Ю., 1900: 63],

Шулай итеп, сүзлеккә татар сүзләренә синоним итеп гарәп – фарсы алынмалары да теркәлгән.

Синонимик байлыкның тагын бер күрсәткече – синонимик ояларның күләме. Татар телендәге синонимик рәтләр нигездә ике сүздән тора, өч яки дүрт сүздән торган синонимик рәтләр дә очрады.

М.Юнысов хезмәтендә сүзләрнең өчәр синоним белән тәрҗемә ителүе дә очрый: аирма ачыкъ – очевидно, явно, явственно [Ю., 1900: 15], биздермякъ – отваживать, отучить, отучать [Ю., 1900: 34], тубя – темя,

крыша, вершина [Ю., 1900: 38], кисмякь – сечь, резать, рубить [Ю., 1900: 76]һ.б.

А.Троянский синонимнар белән тәрҗемә итүне бик актив куллана. Һәр сүзнең ике, өч, дүрт синонимы бирелә.Мәсәлән, اوله ن үлән – трава, мурава, зелень [Т., т.1:131 ], اوي өй – дом, изба, покой [Т., т.1:139], اويورمهөермә - вихарь, буря, сильный ветер [Т., т.1:139], ايسلي исле – душистый, вонючий, угарный, или: имеющий запах, дух, вонь, угар [Т., т.1, с.153], پيشه пишә – рукоделье, художество [Т., т.1:259], ته حشين тәхсин – хвала, похвала, одобрение [Т., т.1:281], ته فه رج тәфәрреҗ – веселье, забава, утешение, восхищение, увеселение [Т., т.1: 331], ته فهرق тәфәррык – развод, разведение, разлука, отдел, отделение [Т., т.1:331], جرتماقҗыртмак – драть, раздирать, разодрать, изодрать, рвать, разорвать, изорвать [Т., т.1, с.393];جرتدرماق җыртдырмак – велеть драть, раздирать, изодрать, рвать, разрывать, разорвать, изорвать [Т., т.1:393], جرتشماقҗыртышмак –взаимно с кем драть, раздирать, издирать [Т., т.1:393], جرتلماق җыртылмак - драться, раздираться, изодраться, рваться, разрываться, разорваться, изорваться, или быть раздираему, издираему, разрываему [Т., т.1:394] һ.б.

Шуны да әйтеп китәргә кирәк: сүзлекләргә теркәлгән берәмлекләрне өйрәнеп чыкканнан соң, терминнар, конкрет предметлар, алмашлыклар һәм сан исемнәре, бик тар мәгънәле һәм күчмә мәгънәдәге сүзләр синонимик мөнәсәбәткә бик сирәк, хәтта бөтенләй кермиләр.

Ш. Ханбикова синонимик мөнәсәбәт мәсьәләсенә карата болай ди: «Һәр сүзнең икенче, өченче яки күчмә мәгънәсе, ким дигәндә күчмә мәгънәдә кулланылышы бар. Әгәр дә сүз бер генә мәгънәле түгел икән, димәк, ул нинди дә булса башка сүз белән синонимлаша ала, яки синоним кулланышка керергә аның потенциаль мөмкинлеге бар» [Ханбикова, 1980: 181]. Димәк, телдәге барлык сүзләр дә диярлек синонимик мөнәсәбәткә керә алалар. Синоним була алмаган сүзләр махсус терминнарда, кайбер конкрет исемнәрдә, алмашлыкларда һәм саннарда гына очрый.

XIX гасырда дөнья күргән татарча – русча һәм русча – татарча сүзлекләрендә тәрҗемә итеп китерелгән синонимнар берсен икенчесе тутыру, конкретлаштыру тәртибендә тезеләләр һәм гадәттә ике – өч сүздән

артмыйлар. Синонимнардан дөрес файдалану - һәр ике телнең дә лексик – семантик системасын тулы чагылдыруга китерә.

XIX гасыр лексикографлары үзләренең сүзлекләрен югарыда китерелгән барлык шартларны күздә тотып төзегәннәр. Шуңа күрә, бүгенге көндә дә бу сүзлекләр синонимнарны чагылдырган бай һәм әһәмиятле чыганак ролен үтиләр.

## XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрдә сүзләрнең үзара синонимлыгы

Татар теле - синонимнарга бик бай тел. Бу, мөгаен, телебезнең борынгыдан ук яшәп, чарланып килүеннән, халкыбызның мәгълүматлы, укымышлы халык булуыннан, үз теленә яратып, игътибар һәм ихтирам белән каравыннан киләдер.

XVIII йөздәге кульязма сүзлекләрдә үк синонимнардан файдалану, сүзләрне синонимнары белән куллану очраклары булса да, аларны махсус тикшерү, өйрәнү совет чорында гына башлана: Х. Сәлим, В. Хангилдин, Ш. Рамазанов, Л. Җәләй хезмәтләрендә синоним төшенчәсенә аңлатма бирелә, татар телендәге синонимнарны өйрәнүгә керешелә.

## Сүзлекләрдә семантик юл белән ясалган синонимнар

Сүзләрнең мәгънәләре үзгәрү, мәгънә төсмерләре өстәлү яки кайбер билгеләрен югалту юлы белән барлыкка килгән синонимнар семантик юл белән ясалган синонимнар дип аталалар. Сүзлекләрдә чагылыш тапкан семантик синонимнарны сүз төркемнәренә мөнәсәбәтле рәвештә бүлеп анализлык. Иң күп синонимик оялар исем һәм сыйфат сүз төркеменә карый. Без шул төркемнәргә караган семантик синонимнарга киңрәк тукталырга булдык. Исем сүз төркеменә караган түбәндәге

синонимнар тупланды: **Беременнная женщина** сүзтезмәсенең тәрҗемәсен И. Гиганов "юклю хатунъ, буазъ, айле, икекатъ"[Г., 1804: 9] дип бирә. К. Насыйри "Татарча – русча сүзлеге"ндә әлеге сүзтезмәнең "хамиля, корсаклы хатын, ауырлы, йөкле хатын" вариантлары китерелә [Н., 1878: 34]. Хәзерге татар әдәби телендә йөкле, авырлы хатын сүзтезмәләре кулланыла. Корсаклы хатын тезмәсе күбрәк сөйләм телендә очрый, ә буаз сүзе бу мәгънәдә кешегә карата әйтелми. Хамиля, айле, икекатъ сүзләре исә, кулланыштан төшеп калганнар. Хәмилә сүзе төрек телендә, икекат берәмлеге уйгур телендә кулланыла.

**Богатство** - "байлыкъ, ганиликъ" [Г., 1804: 19], А. Воскресенский бу сүзне "байлык, мал, рыскал" [В., 1894: 10] дип, ә К. Насыйри "дәүләт" [Н., 1892: 9] дип тәрҗемә итә. Аңлатмалы сүзлектә "ганимәт" дип бирелә һәм ике мәгънәсе күрсәтелә: сугышта кулга төшкән байлык, трофей һәм табыш, казаныш, уңыш [ТТАС., 1977, т.1:259]. Татар теленең диалектологик сүзлегендә "мал" сүзенең ике мәгънәсе бирелә:1. терлек (мал ойасы) - тепекәй сөйләше, мал ызбасы - стәрлетамак сөйләше; 2. байлык, милек [ТТДС., 1993: 218]. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә өченче мәгънәсе дә күрсәтелә: "сату итү әйберләре, товар" [ТТАС., 1979, т.2: 361], рыскал сүзе злотоуст сөйләшендә "бәхет" мәгънәсендә кулланыла.

**Вдохновение** "илгамъ, сүлү" [Г., 1804: 49], А. Воскресенский сүзлегендә "гайрәтләндерү" [В., 1894: 18], К. Насыйрида "җанландырмак, гайрәтләндермәк" [Н., 1892: 13] дип тәрҗемә ителгән. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә "сулу" сүзенең өч мәгънәсе күрсәтелә: 1. шиңә башлау яки шиңү (үсемлек турында); 2. ябыгып төссезләнү, ямьсезләнү; 3. сулыш (сулыш алу — сулу алу) [ТТАС., 1979, т.2: 683]. Күргәнебезчә, сулу сүзе хәзерге вакытта "илһам" мәгънәсендә кулланылмый.

**Взгляд** берәмлеген И. Гиганов "назар, каравъ" [Г., 1804:50] дип бирә. А. Воскресенский "карау" [В., 1894:20], К. Насыйри "күрү, назар" [Н., 1892:15] вариантларын тәкъдим итәләр. Аңлатмалы сүзлектә "карау" сүзенең 22 мәгънә төсмере күрсәтелә: 1. күзләрне нәрсәгә дә

булса юнәлтеп карап, шул нәрсә турында мәгълүмат алу; 2. каралу, тикшерелү процессы [ТТАС, 1979, т.2: 56]. Назар сүзе дә бар. Ул 1. караш, игътибар, илтифат, күз салу; 2. караш, уй мәгънәләрен белдерә һәм искергән сүз икәнлеге искертелә [ТТАС., 1979, т.2: 432]. Бүгенге көндә бары тик караш сүзе генә кулланыла.

**Вид лица** "шикиль, сыфатъ" [Г., 1804: 51], К. Насыйрида "чырай" [Н., 1878: 45], "сурәт" [Н.,1892: 15], А. Воскресенский сүзлегендә "йөз, бит" [В., 1894: 120] дип бирелә. Чырай сүзе диалектологик сүзлектә караңгы чырай (угрюмое лицо) сүзтезмәсе составында урын алган. Ул тау ягы, норлат сөйләшендә кулланыла [ТТДС., 1993:361]. Аңлатмалы сүзлектә шәкел сүзе искергән сүз дип бирелә һәм "форма" мәгънәсенә ия икәнлеге белдерелә. "Йөз" мәгънәсе юк [ТТАС., 1977, т.1: 533]. XX гасыр башындагы әдәби әсәрләрдә йөз, бит мәгънәсендә фарсыдан кергән чәһрә сүзе кулланылган, һәм ул югары стильгә, шигърияткә хас сүз буларак кабул ителә. Телебездә чәһрә сүзенең чырай дип бозылган варианты бар. Ә ул исә, киресенчә, түбәнсетү төсмерен белдерә [Сәгыйтов, 1992:22-23.].

**Вестник** сүзенең тәрҗемәсен И. Гиганов берничә вариантта бирә: " сявенце, лагунце, хаберце, хабярь биргүце" [Г., 1804:88]. Лагун сүзе диалектологик сүзлектә дә бирелә. Мәгънәсе: "кырга су алып бару өчен хезмәт итә торган капкачлы агач савыт, агач чиләк" [ТТДС., 1993: 332]. Лагүнце дип кырга шул савыт белән су ташучы һәм хәбәр алып килүчене атап йөрткәннәр.

**Зерно** "кюзь, дана" [Г., 1804: 195], А. Воскресенский бу сүзне "бөртек, орлык" [В., 1894: 84] дип тәрҗемә итә. Аңлатмалы сүзлектә күз сүзенең 18 мәгънәсе күрсәтелә, ләкин орлык мәгънәсе юк [ТТАС., 1979, т.2: 282]. Димәк, күз һәм данә сүзләренә хәзерге вакытта синонимик мәгънә хас түгел.

***Знак*** "бильги, нишан, киртыкъ" [Г., 1804: 198]. А. Воскресенский сүзлегендә "билге, тамга" [В.,1894: 85], К. Насыйрида "галәмәт" [Н., 1892: 55] дип бирелә. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә нишан "билге, тамга, эз, галәмәт" мәгънәсендә иске китап телендә

кулланыла дип күрсәтелә. Икенче мәгънәсе: "егет белән кызның бер - берсенә биргән вәгъдә бүләкләре" [ТТАС., 1979, т.2: 445].

**Искра** "үцкүнъ, кылкынъ" [Г., 1804: 214], К. Насыйри "очкын" [Н., 1892: 60] дип тәрҗемә итә. Татар теленең диалектологик сүзлегендә "кылкыну" фигыле күрсәтелә. Ул "атлыгу, бик теләп тору (рваться, стремиться к чему – либо) " [ТТДС., 1993: 187] мәгънәсен белдерә. И. Гиганов сүзлегендәге "кылкын" сүзе белән бер тамырдан килеп чыгуы ачык күренә.

**Клевета** "бюгтань, яла ябу" [Г.,1804:231], А. Воскресенский "аляк, сылтау" [В.,1894: 103], К. Насыйри "гайбәт" [Н., 1892: 65] дип тәрҗемә итә. Сүзлек авторлары биргән синоним сүзләр бер-берсеннән мәгънә төсмерләре белән аерылалар. Аңлатмалы сүзлектә бирелгән мәгънәләрен карап китик: гайбәт "уйдырма фактларга нигезләнгән сүз, хәбәр" [ТТАС.,1977, т.1: 255]; сылтау "берәү эшләгән дип күрсәтү, рас-ларга маташу һәм берәр сәбәпкә, гадәттә, урынсыз рәвештә , кайтарып калдыру" [ТТАС.,1979, т.2: 700]; әләк "берәүне нәрсә өчен дә булса гаепле санап, еш кына яла ягып, аның өстеннән власть вәкилләренә яки башка-ларга җиткерелгән яшерентен сүз, хәбәр, донос" [ТТАС., 1981, т.3: 682].

**Суп** "уря" [Н., 1878, 12], А. Воскресенскийда "өйря, салма, чумар, аш" [В., 1894: 321], К. Насыйрида "ит кайнаган су, шулпа" [Н., 1892: 199]. А. Вос-кресенский ашның төрле төрләрен күрсәтә. Алар аңлатмалы сүзлектә түбәндәгечә аңлатыла: өйрә "гадәттә ярма салып пешерелгән сыек аш" [ТТАС., 1981, т.3: 698]; салма "токмач камырын дүрт почмаклап кисеп яки камырны вак кына кисәкләргә өзгәләп, ашта пешерелгән ашамлык; чумарның бер төре" [ТТАС., 1979, т.2: 621]. Диалектологик сүзлектә "өйдә ясал-ган токмач" мәгънәсе бар. Злотоуст һәм карсун [Ульяновск] сөйләшләрен-дә кулланыла [ТТДС., 1993:262]. Чумар "кайнап торган ит шулпасына, сөткә салып пешерү өчен үзенә бертөрле әзерләнгән вак камыр кисәкләре салып пешерелгән аш" [ТТАС., 1981, т.3: 446]. Күргәнебезчә, "аш" сүзенең сөйләм телендә һәм диалектларында төрле вариантлары кулланылган. **Половник** сүзен К. Насыйри "бакрач" [Н., 1878: 19] дип тәрҗемә итә.

Бу сүзнең сүзлекләрдә төрле кызыклы вариантлары китерелә. А. Воскресенскийда "чюмеч, татар кашыгы" [В., 1894: 222], Н. Остроумовта "кастрюля" [О., 1892: 112], И. Гигановта "капкиръ" [Г.,1804: 413] дип тәрҗемә ителә. Бакрач диалектологик сүзлектә "аш чүмече" дип бирелә. Стәрлетамак (Башкортстан) һәм каргалы (Оренбург) сөйләшләрендә кулланыла [ТТДС., 1993: 43]. Аңлатмалы сүзлектә берничә мәгънәсе күрсәтелгән: 1. бакыр шлем [иске сүз]; 2. озын саплы зур чүмеч, бакыр чүлмәк. Бу мәгънәсе бары тик диалектларда гына кулланыла. 3. күчерелмә мәгъ-нәсе: кара тутлы кеше; [ТТАС., 1977, т1: 113]. И. Гигановның хезмәтендә би-релгән "капкиръ" [кәпкер] Себер татарлары сөйләшләрендә өч мәгънәдә очрый: 1. тишекле чүмеч, сөзгеч; 2. соскыч; 3. күп сөйләүче, сөйләүчән; [СДСТ., 1992 :54].

**Наследство** "тярикя" [Н., 1878: 45], "әйтеп калдырылган әйбер, мал" [В., 1894: 147], "ашия" [Г., 1804:305] вариантлары бирелә. **Тәрикә** аңлатмалы сүзлектә "берәүдән калып та әле бүленмәгән мирас, мал" дип аңлатыла [ТТАС., 1981, т.3: 226]. Искергән сүз булып санала. Мирас "хуҗа үлгәч башка берәүнең хосусый милкенә күчә торган мал, мөлкәт, байлык" [ТТАС., 1979, т.2:396] мәгънәсенә ия. **Әшья** сүзе гарәп телендәге шәй сүзеннән һәм ул әйбер, предмет дигәнне белдерә, татар телендә актив кулланылмый, әмма төрек телендә еш очрый..

**Судья** сүзен сүзлекчеләр "туря" [Н., 1878: 42], "тикшерүче, хөкем итүче" [В.,1894: 321], "хаким" [Г., 1804, 586] дип тәрҗемә итәләр. Әлеге сүзләр мәгънә төсмерләре белән аерылалар. **Түрә** "эш башында торган кеше, башлык" [ТТАС., 1981, т.3: 289]. **Хаким** "судья, хөкем итүче, казый" һәм "өстенлек итүче, югары, өстен" [ТТАС., 1981, т.3: 360] мәгънәләрен белдерә.

**Узор** сүзенең сүзлекләрдә "тирякъ" [Н.,1878: 45], "бизәк" [Н., 1892:210], "челтәр, чигеш, нәкыш" [В., 1894: 340], "тагылъ" [Г., 1804: 625] кебек тәрҗемәләре бар. Каргалы сөйләшендә тирәк сүзе "тармак, ботак", ә бәрәңге (Мари – эль) сөйләшендә "бизәк, чигү бизәге" мәгънәсендә кулланыла. Казан арты, дөбъяз сөйләшендә "җирлек" мәгънәсендә очрый [ТТДС.,1993:299]. Аңлатмалы сүзлектә болай

аңлатыла: 1. тополь; 2. зур һәм биек агач. Бу мәгънәсе бары диалектларга гына хас. 3. тукымага чигеп яки басып төшерелгән агач, чәчәк рәсемнәре; иске мәгънә төсмере белән кулланыла [ТТАС.,1981, т.3:105]. **Тагылъ** сүзе "бизәк" мәгънәсендә Төмән өлкәсе Тобол районында кулланышта йөри [СДСТ., 1992: 199].

**Служанка** "джария" [Н., 1878: 54], "хезмәтче" [В., 1894:302], "күнъ" [Г., 1804: 548]. Синонимнар сүзлегендә "хезмәтче" сүзенең түбәндәге вариантлары китерелә: "асрау, йорт эшләрен башкаручы, хадим[ә], ялчы" [СС., 1999: 108]. XIX гасыр сүзлекләрендә теркәлгән синонимнар бу сүзлектә урын алмаган.

**Разговор** берәмлеген "гябъ" [Н.,1878: 95], "мөгамәлә, сүз" [Н., 1878: 167], "сөйләшү" [В., 1894: 268], "кяпляшү" [Г.,1804: 494] дип тәрҗемә итәләр. Гәп сүзе "әңгәмә,сөйләшү" [ТТАС.,1977, т.1:283] мәгънәсенә ия. Бүгенге көндә әлеге синоним сүзләрнең барысы да кулланыла**.**

**Работник** сүзенең "малай" [Н., 1878: 101], "хезмәтче" [Н., 1892:165], "эшче, ялчы" [В., 1894:266] кебек синонимнары бирелә. Малай сүзенең аңлатмалы сүзлектә 4 мәгънәсе бар: 1. яңа туган яки кече яшьтә-ге, яшүсмер ир бала; 2. сөйләм телендә гомумән сөйләүчедән яшьрәк булган ир кешене белдерә; 3. хезмәтче; иске сүз дип күрсәтелгән; 4. бер – береңә тәкәллефсез һәм дусларча мөрәҗәгать итү сүзе; сөйләм телендә генә кулланыла; [ТТАС., 1979, т.2: 361]. Күргәнебезчә, бары тик өченче мәгънәсе генә А. Воскресенский тәрҗемәсе белән туры килә**.**

**Желание** "морад" [Н., 1878:103], "касд, теләү, арзу" [Н., 1878: 44], "уй, дәрт, нәфес" [В., 1894: 163], "хахламакълыкъ, арзуламакълыкъ" [Г.,1804:153]. Морад сүзе аңлатмалы сүзлектә "максат" дип бирелгән [ТТАС., 1979, т.2: 404]. Дәрт берәмлеге диалектологик сүзлектә "кайгы, хәсрәт, борчу" мәгънәсендә хвалын сөйләшендә (Ульяновск0 кулланыла [ТТДС., 1993: 90]. Хахламакълыкъ, арзуламакълыкъ, касд берәмлекләре хәзерге татар телендә очрамый. Алар алынма берәмлекләр. Арзу сүзе телебезгә фарсы теленнән кергән һәм теләк, омтылыш дигән мәгънә белдерә.

**Стихотворение** лексемасы сүзлекләрдә "нязмь" [Н., 1878: 107], "бәет" [Н., 1892: 197], "әйтмеш, стих" [В., 1894: 316] дип бирелә. Назым аңлатмалы сүзлектә "шигырь, шигъри төзелеш" [ТТАС., 1979, т.2:432] рәвешендә аңлатыла. Бәет сүзенең ике мәгънәсе күрсәтелә: 1. халык авыз иҗаты әсәре: берәр кешегә яки вакыйгага багышланып, гадәттә шаярту яки кызгану хисләре белән сугарылган шигырь; 2. шигырьнең мәгънә һәм интонация ягыннан аерымланып торган бер кисәге, өзеге; [ТТАС., 1977, т.1: 203]. Бирелгән аңлатмалардан күренгәнчә, алар поэзия жанрының төрләре булып саналалар.

**Супруга** сүзенең "джифитъ" [Н., 1878: 94], "зәүҗә" [Н., 1892: 86], "кушым" [В., 1894: 321], "халяль" [Г., 1804:588] кебек синонимнары теркәлгән. Кушым сүзе аңлатмалы сүзлектә "кушымта" дип бирелгән [ТТАС., 1979, т.2: 200], ә сүзлектәге мәгънәсе күрсәтелмәгән. Зәүҗә "ир хатыны" дип аңлатыла һәм иске китап телендә кулланылган дигән искәрмә бирелә [ТТАС., 1977, т.1: 354]. Хәләл сүзе өч мәгънәгә ия: 1. шәригать тарафыннан тыелмаган, рөхсәт ителгән; 2. намуслы; 3. сөйләм телендә "никахлы" мәгънәсендә дә кулланыла [ТТАС., 1981, т.3: 383]. Кушым, зәүҗә сүзләре хәзер кулланыштан төшеп калган. Берсе автор тәрҗемәсе дип уйларга урын бар, шуңа активлашмаган, ә икенчесе алынма сүз, ул башка алынмалар белән кысрыкланган.

**Уважение** сүзенең мондый синонимик рәте китерелә: "ригая" [Н., 1878: 61], "хөрмәт итү" [Н., 1892:207], "кадерләү, хөрмәтләү" [В., 1894:336]. Ригая кылу аңлатмалы сүзлектә болай аңлатыла: 1. игътибар итү; 2. ихти-рам итү; [ТТАС., 1979, т.2:595]. А. Воскресенский аның икенче мәгънәсен генә күрсәтә. Бүгенге көндә кадерләү, хөрмәтләү сүзләре ешрак кулланыла.

**Магнит** "иня таши" [Н., 1878: 27], А. Воскресенский "магнит" [В., 1894: 125] дип тәрҗемә итә. Ә К. Насыйри "мыкнатыс" [Н., 1878: 27] вариантын да бирә. Синонимнар сүзлегендә "инә ташы" сүзтезмәсе генә күрсәтелгән [СС., 1999: 68]. Бүгенге көндә сөйләмдә магнит сүзе ешрак очрый.

**Толпа** "таифя" [Н., 1878: 74], "җыен, чирү" [В., 1894 :330], "кюмякъ" [Г., 1804:605] дип тәрҗемә ителә. Чирү диалектологик

сүзлектә "гаскәр" дип бирелгән. Казан арты, керәшеннәре сөйләшендә [ТТДС., 1993:354] кулланыла. Җыен "бер төркем авылларда ел саен үткәрелә торган бәйрәм. Тау ягы, тархан сөйләшендә [ТТДС.,1993: 416] күзәтелә. Таифә аңлатмалы сүзлектә:1. бериш җан ияләренең аерым төркеме; 2. кабилә, халык, этник группа [ТТАС., 1981, т.3: 17] дип аңлатыла.

**Ворота**, **дверь** сүзләре "капу" [Н., 1878: 89], "капка, ишекъ" [В., 1894: 23] дип бирелә. Аңлатмалы сүзлектә "капка" һәм "капкач" [ТТАС., 1979, т.2: 47] мәгънәләре күрсәтелә. Капы "капка" мәгънәсендә ләмбрә сөйләшендә (Пенза) [ТТДС., 1993:158] очрый. Капу варианты архаик форма булып санала, борынгы әдәби әсәрләрендә, язма истәлекләрдә чагылыш таба.

**Достоинство** "кадръ" [Н.,1878: 87], "лаеклык, хасият" [Н.,1892:39], "тиешлек" [В., 1894: 58], "шаясталыкъ" [Г., 1804:138]. Әлеге синоним сүзләрнең мәгънә төсмерләре төрле: лаеклык "лаеклы булу" [ТТАС., 1979, т.2: 328], тиешлек "тиеш булу" [ТТАС., 1981, т.3:94], хасият "кемгә яки нәрсәгә дә булса хас сыйфат, үзлек, үзенчәлек" [ТТАС., 1981,т.3: 364] мәгънәләренә ия. Кадр һәм шаясталык берәмлекләре хәзерге вакытта кулланылмый.

Н. Остроумовның 1892 елда басылган "Татарско – русский словарь"хезмәтеннән алынган мисалларны карап китик. **Кромка, обшивка подола** "адеб" [О., 1892: 3], "кыйыу, тасма" [В., 1894: 170], "тегү" [Н., 1892: 104] дип тәрҗемә ителә. Кыю сүзенең аңлатмалы сүзлектә өч мәгънәсе бирелгән. Өченче мәгънәсе А. Воскресенский тәрҗемәсе белән якын: "өстен кисү, кистереп алу" [ТТАС., 1979, т.2: 244]. Тасма "бизәү, бизәнү һәм кием-салымны матурлау өчен, шулай ук кием-салымга беркетелгән шартлы билге сыйфатында да кулланыла торган тар гына озын тукыма" [ТТАС., 1981, т.3:51] мәгънәсен белдерә.

**Свекровь** "бейем" [О., 1892: 39], "печкя, кайнана" [В., 1894: 290] дип бирелә. Чистай керәшеннәре сөйләшендә печкя "биана, кайнана" [ТТДС., 1993: 246] мәгънәсендә кулланыла.

**Булочка** сүзенең "гердя" [О., 1892: 57], "кюмяч" [В., 1894:352] вариантлары бирелә.

**Оладьи** "жуача" [О., 1892: 82], "коймак" [В., 1894: 352], "төче коймак" [Ю., 1900:46]. Жуача "бодай оныннан пешерелгән ак ипи, бодай күмәче" дигән мәгънәдә минзәлә һәм стәрлетамак сөйләшләрендә [ТТДС., 1993: 415] очрый.

**Селение, деревня** "ил" [О., 1892: 93], "аул, карья" [Н.,1892: 36], село "чиркәүле авыл" [В., 1894: 294], деревня "чиркәүсез авыл" [В., 1894: 53]. Ил сүзе селение (авыл) мәгънәсендә теркәлгән. Хәзерге телдә аның мәгънәсе киңәйгән. Авыл дигән мәгънәдә ул кайбер авыл исемнәрендә генә сакланып калган. Мәсәлән, Кариле, Казиле. Карья сүзе аңлатмалы сүзлектә иске китап теле берәмлеге дип бирелгән. "Авыл" мәгънәсендә йөри [ТТАС., 1979,т.2: 67]. Карья сүзе XIX гасыр-XX гасыр башы матур әдәбият әсәрләрендә очрый.

**Чайная ложка** сүзенең "калак" [О., 1892: 107], "бал кашыгы" [Н., 1892: 74], "кашык" [В., 1894: 122], "шабала" [Г., 1804:265] кебек вариантлары бирелә. Шабала сүзе Барабинка авылында (Томск өлкәсе, Томск районы) "кашык" мәгънәсендә кулланыла [СДСТ., 1992: 248].

**Четверть** "түтәреш" [О., 1892: 210], "чирек, карыш" [В., 1894: 360] дип тәрҗемә ителә. Бу сүзләр аңлатмалы сүзлектә болай аңлатыла: карыш "озынлык үлчәве берәм-леге — киерелгән кулның баш бармак очы белән урта бармак очы арасы, уртача чирек аршинга тигез" [ТТАС., 1979, т.2:67] дип бирелә. Чирек сүзе 1. бөтеннең дүрттән бер өлеше; 2. дүрт өлешкә бүленә торган уку елының бер өлеше; 3. метрик система кертелгәнче, бик борыннан кулла-нылып килгән, чиләк сыешының дүрттән бер өлешенә тигез булган сыек-лык күләмен үлчәү берәмлеге [3,1 л ]; 4] метрик система кертелгәнче, бик борыннан кулланылып килгән, аршынның дүрттән бер өлешенә тигез бул-ган озынлык үлчәү берәмлеге; карыш [17,775 см]; [ТТАС., 1981, т.3:430] кебек мәгънәләргә ия. Аңлатмалы сүзлектә түтәреш сүзе белән мәгънәдәш түтәрәм сүзе очрый. Ул "дүрттән бер өлеш, чирек" [ТТАС., 1981, т.3:290] мәгънәсендә кулланыла.

**Блин** "табикмәк" [О., 1892: 211], "коймак" [В., 1894: 9] дип тәрҗемә ителә. Тау ягы, тархан сөйләшендә (Татарстанның өлешчә Буа, Апас һәм Тәтеш районнары) табикмәк "өстенә бәрәңге яки эремчек ягып ачы камырдан пешерелгән пәрәмәч, шәнгә" [ТТАС., 1981, т.3: 248]. Ә аңлатмалы сүзлектә табикмәк болай аңлатыла: "әче камырдан табага җәеп пешерелә торган, беленнән калынрак ашамлык" [ТТАС., 1981, т.3: 206]. Әлеге аңлатмалардан күренгәнчә, камыр ризыклары татар әдәби телендә һәм диалектларда төрле мәгънәләрдә йөри.

XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча – татарча сүзлекләрдә урын алган синонимик мәгънәле сүзләр арасында сыйфатлар белән белдерелгән берәмлекләр дә шактый күп. Бу уңайдан И. Гигановның 1804 елда басылган "Российско – татарский словарь" исемле хезмәтеннән алынган түбәндәге сүзләрне кертергә мөмкин: **бездельник** : "бикаръ, ишсез [Г.,1804: 8], ә К. Насыйриның "Русча – татарча сүз-леге"ндә "һөнәрсез" [Н. 1892:7] дип тәрҗемә ителә. Бикар берәмлеге хәзерге вакытта искергән сүз булып санала. Татар телендә кулланылмый, ә уйгур телендә кияүгә чыкмаган, өйләнмәгән - ялгыз кешене белдерә. Шулай ук буш вакыт мәгънәсендә дә йөри.

**Безнадежный** "үмидсезъ, наүмидъ" [Г.,1804: 9]. А. Воскресенскийның сүзлегендә "ышангычсыз, өметсез" [В., 1894: 5] дип бирелә. Аңлатмалы сүзлектә исә, "нәүмиз" формасында очрый. Ул "күңелсез, боек" дип аңлатыла [ТТАС., 1979, т.2: 454 ].

И. Гиганов **безпамятный** сүзен болай тәрҗемә итә: "ядьсез, ядкашъ, дагулъ, хатерсезъ" [Г., 1804: 9]. А. Воскресенский "катерсез" [В., 1894 5], ә К. Насыйри "һушсыз" [Н., 1892: 8] дип бирә. "Ядь" аңлатмалы сүзлектә "истәлек, хатирә" дип күрсәтелә [ТТАС., 1981, т.3: 622]. Хәтер, һуш, яд- барысы да татар теленә гарәп, фарсы телләреннән кергәннәр.шул ук мәгънәне белдерүче төрки чыгышлы ис сүзе сүзлекләрдә теркәлмәгән.

**Большой** сүзенең берничә синонимик пары китерелә: "олугъ, зуръ" [Г., 1804: 23], А. Воскресенский "дәү, шяп, оло" [В., 1894: 11]

вариантларын бирә. Синонимнар сүзлегендә эре, олпат, сыешлы, күп сыйдырышлы синонимнары да өстәлгән [СС., 1999: 42].

**Бедный** "фякыръ, гарилъ, гидай" [Г., 1804: 35]. К. Насыйри сүзлегендә бу сүз "юксыл" [Н., 1878: 118], ә А. Воскресенский хезмәтендә "ярлы" дип күрсәтелә [В., 1894:4]. Юксыл сүзе аңлатмалы сүзлектә дә бар. Мәгънәсе: "ярлы кеше, изелгән, эксплуатацияләнгән сыйныф вәкиле" (иске дип күрсәтелгән) [ТТАС., 1981, т.3: 605]. Синонимнар сүзлегендә "ярлы" сүзенең түбәндәге вариантлары китерелә: "фәкыйрь, юксыл; гидай; ярлы – ябагай; хәлсез; хәле начар; тормышы начар; ябагай; мохтаҗ; - га моң; [СС., 1999:124]. "Гидай" сүзе Казан арты, балтач сөйләшендә ике мәгънәдә кулланыла: 1. ялангач; 2. ялан өс; [ТТДС., 1993: 79]. И.Гиганов бу сүзне *киеме юк кеше, фәкыйрь кеше* дигәнне бирү өчен теркәгәндер дип уйларга урын кала.

**Здоровый** сүзенең синонимик берәмлекләре шактый: "исян, аманъ, савъ" [Г.,1804:193]. А. Воскресенский "исян, сау, таза, арыу" [В.,1894:83] дип тәрҗемә итә. К. Насыйрида "сәламәт" [Н.,1892: 54] дип бирелә. Аман сүзенең диалектологик сүзлектә ике мәгънәсе күрсәтелә: 1.гүя, әйтерсең лә; Ул бастан сөйләшендә кулланыла. 2.имин; бу сүз темников сөйләшендә кулланыла [ТТДС., 1993: 28]. Себер татарлары сөйләшләрендә аман сүзе кабатланып килеп "һаман, һаман саен" мәгънәсендә йөри [СДСТ., 1992: 24].

**Красивый** "үямъ" [Н., 1878: 33]. А. Воскресенскийның биргән тәрҗемәсе: "матур, ямьле, шыклы, кюркям, чибәр, сылу" [В., 1894: 112], "гүзәл, матур" [Н., 1892:31], И. Гиганов сылу сүзен фонетик яктан үзгәртеп "сүлүвъ" [Г., 1804:248] дип тәрҗемә итә.

**Твердый** сүзе "сабит" [Н., 1878: 84], "нык" [В., 1894:326], "катигъ" [Г., 1804: 598] дип тәрҗемә ителә. Аңлатмалы сүзлектә сабит "нык, тайпылмаучан, кире кайтмаучан" [ТТАС., 1979, т.2: 610] мәгънәсендә бирелә. Хәзерге вакытта каты, нык синонимнары еш кулланыла.

**Светлый** "ряушанъ" [Н., 1878: 62], "саф, якты" [Н., 1892:182], "яктылык" [В., 1894: 290]. Раушан сүзе "якты, ачык, саф, чиста, пакъ,

керсез, асыл" [ТТАС.,1981,т.3, 580] мәгънәләренә ия. Искергән сүз булып санала.

**Сладкий** берәмлегенең "сөчөкъ, ляззятли" [Н., 1878: 63], "татлы, тәмле" [В., 1894: 300], "сюцюкъ" [Г., 1804:546] кебек синонимик вариантлары китере-лә. Сүцүк сүзе Төмән өлкәсе, Тобол районында "җиләк-җимеш суы" мәгънәсендә кулланыла [СДСТ., 1992: 196].

Күргәнебезчә, XIX гасыр сүзлекләрендә иң күп синонимнар семантик төркемчәгә карый. Аларның кайберләре мәгънәләрен үзгәрткән, яңа мәгънә төсмере алган, кайбер билгеләрен югалткан. Ә күпчелек берәмлекләр хәзерге телдә дә актив кулланыла. Бу аларның тотрыклы булуын, үз урыннарын югалтмаулары хакында сөйли.

## Синонимнарның фонетик юл белән ясалышы

Татар әдәби теленең фонетик төзелеше, гомумтөрки фонетик струк-турага нигезләнсә дә, үзенә хас закончалыкларга ия булуы белән аерылып тора. Анда татар теленең аерым эволюцион үсешен ачык күзәтергә була.

Ә хәзер сүз яки грамматик формаларда авазлар үзгәрү – фонетик юл белән ясалган сүзләрне карап китик.

Без тикшергән сүзлекләрдә күбрәк алынмалар фонетик үзгәрешләргә дучар булалар. Аларның күбесенә диссимиляция күренеше хас. Диссимиля-ция нормалаштырылмаган сөйләмдә [гади сөйләм, диалектлар, балалар сөй-ләме] чагылыш таба һәм, гадәттә, орфоэпик норма буларак кабул ителми.

Ш. Габделгазизның 1893 елда басылып чыккан "Переводъ съ та-тарского на русский языкъ или словарь" исемле сүзлегендә **счеты** сүзе "шутъ" [Ш.Г., 1893:11] дип, К.Насыйрида"сан хисабы" [Н., 1892, 200], ә А.Воскресенскийда "исяб" [В., 1894, 323] дип бирелә. Ике тартык

аваз бергә килү татар теленә хас күренеш түгел. Шуңа күрә, татар теленең үз фонетик законнарына яраклаштырылып счет сүзе "шутъ" формасында сөйләмдә кулланыла башлый.

**Серьги** "сырга, колак алкасы" [Ш.Г., 1893:13], "алка" (у мужчин), "сырга" (у женщин) [В., 1894: 295]. Сырга сүзе Казан арты, лаеш, злотоуст, турбаслы (Башкортстан) сөйләшләрендә "колагалка" мәгънәсендә кулланыла [ТТДС, 1993: 275]. Сырга берәмлеге серьги сүзенең татарлашкан варианты. Алгы рәт сузыклары арткы рәт сузыклары белән алмашынган

**Подносъ** "патнусъ" [Ш.Г., 1893:18], "чынаяк асты" [Н., 1892: 184], "пуднус" [В.,1894: 213]. Хәзерге вакытта чынаяк асты "поднос" мәгънәсендә кулланылмый. Ул - "блюдца" сүзенең татарча тәрҗемәсе.

**Кузовъ** " кзау" [Ш.Г., 1893:21], "кызау, карнаша" [В., 1894:116]. Әлеге сүзнең диалектологик сүзлекләрдә төрле мәгънәләре күрсәтелә. Кызау "тегермәндә мөшкәгә ашлык салу өчен хезмәт итә торган зур агач савыт". Шул мәгънәдә тау ягы, тархан сөйләшендә [ТТДС., 1993: 145] кулланыла. Шулай ук, карнаша сүзенең дә берничә мәгънәсе бирелә:1. җилпуч; (Казан арты керәшеннәре сөйләшендә); 2. Казан арты, мамадыш сөйләшендә "агач каерысыннан ясалган җиләк җыя торган савыт" мәгънәсен белдерә; 3.тубал; Казан арты керәшеннәре сөйләшендә кулланыла [ТТДС., 1993: 130].

1900 елда басылган М. Юнысовның "Татарско – русский словарь... " хезмәтендә теркәлгән: **известка** "эзбись" [Ю.,1900:18] сүзе, башка сүзлекләрдә "избис" [В., 1894: 88], "акбур таш" [Н., 1892: 57], "чершелъ" [Г., 1804: 204] кебек фонетик я лексик вариантлар белән бирелгәннәр.

**Гробъ** "тагаракъ" [Ю., 1900: 43], "табут" [Н., 1892: 33], "груп" [В., 1894: 50]. Тагарак тау ягы, норлат, тархан сөйләшләрендә "җилпуч" [ТТДС., 1993: 284] мәгънәсендә кулланыла.

Димәк, счеты — шутъ; серьги — сырга; поднос — патнус, пуднус; кузов — кызау; тетрадь — титрад; известка — эзбись, избис; гроб — груп сүзләре диссимиляцион үзгәрешләр кичергәннәр.

Төрки телләрдә сүзләрнең беренче иҗегендә сузык авазлар үзләренең тотрыклыгы, ныклыгы һәм дәвамлылыгы белән аерылып торалар. Шунлык-тан аларда борынгы диалекталь үзенчәлекләр күбрәк саклана. Икенче һәм соңгы иҗекләр үзгәрешкә күбрәк тартылалар. Чөнки аларга күп очраклар-да төрки телләргә хас булган сузыклар гармониясе дигән фонетик закон-чалык зур йогынты ясый, беренче иҗектәге сузыкларны да охшашландыра. Гадәттә, төрки сүзләр я алгы рәт, я арткы рәт сузыклары белән әйтеләләр [Хаков :101].

XIX гасыр сүзлекләренең авторлары да кайбер сүзләрне сингармонизм законына яраклаштырып бирәләр. Мәсәлән: **век** "гоморъ" [Г.Ш.., 1893: 29], "гасыр" [Н., 1892: 28], "гумер, жөзжыл" [В., 1894: 41], "заманъ, азяль" [Г., 1804: 87].

**Русый** "кунгуръ сары" [ГШ., 1893: 29], "сары" [Н., 1892: 177], "конгыр" [В., 1894: 285].

**Ученый** "белекле" [ГШ., 1893:40], "галим" [Н., 1892: 214], "укымыш" [В., 1894: 349], "үкүмышъ" [Г., 1804:639].

**Кланяться** " башрмакъ" [Ю., 1900: 22], " бүкүлмәк" [Н., 1892: 65], " башкүяменъ" [Г., 1804: 231].

**Стогъ** " бугулъ" [Ю., 1900: 33], " богол, печән кибәне" [В., 1894: 316], "кибән" [Н., 1892:197]. Богыл сүзе аңлатмалы сүзлектә " конус рәвешендәге печән кибәне" [ТТАС., 1977, т.1: 173] дип бирелә.

**Пища** "тагамъ" [Ю., 1900: 38], " ъыда, тәгамъ, аш" [Н., 1892: 126], " җим, ашамлык" [В., 1894: 202].

**Плечо** " джауръ" [Ю., 1900: 63], " җилкә" [Н., 1892: 127], " иң, иңбаш" [В., 1894:203], " үмүзъ" [Г., 1804, 386].

**Копь¸** " сүнгү, няйзя" [Г., 1804: 242], "сөнгө" [В., 1894: 109].

**Искра** "үцкүнъ, кылкынъ" [Г., 1804: 214], "очкын" [Н., 1892: 60].

**Креститься** "төртөнмякъ" [Н., 1878: 42], "кач кылу, чукыну" [В., 1894: 112].

**Внук** "нябиря" [Н., 1878: 104], "улның улы, кызның улы" [В., 1894: 124], "нябирякызъ, нябиря - үгүлъ" [Г., 1804: 58]. Нәбәрә [нәүәрә] "онык" мәгънәсендә Төмән өлкәсендә кулланыла [СДСТ., 1992: 158].

**Малый, небольшой** "ляля" [О., 1892: 146], "аз, кечкенә, зур түгел" [Н., 1892:92], "вак" [В., 1894:125], "кицикъ" [Г., 1804:273]. Югарыда китерелгән мисаллардан аңлашылганча, сүзлекләрдә шактый синонимнар теркәлгән. Алар телебезне баеталар, матурлыйлар.

Күргәнебезчә, югарыда күрсәтелгән сүзләр сингармонизм законына буйсындырылганнар. Әлеге сүзләрнең күпчелегендә иренләшкән сузыклар-ның кулланылуы лабиаль гармонияне барлыкка китерә (гоморъ, кунгуръ сары, бүкүлмәк, бугулъ, богол). Борынгы төрки һәм татар әдәби телендәге лабиаль сузыклар арасында аерма бар. Мәсәлән, борынгы у [ү] авазын та-тар телендә ө фонемасы алыштырган. Алгы рәт сузыкларындагы мондый үзгәрешләр, ягъни у [ү] > ө көчеше түбәндәге сүзләрдә ачык күзәтелә. Мә-сәлән, бүкүлмәк сүзе беренче иҗектә ү > ө , икенчесендә ү > е фонемасы алыштырган. Сүнгү, сөнгө сүзләре шундый ук күчешне кичергән.

Димәк, татар телендә икенче һәм аннан соңгы иҗекләрдә иренләшү беренче иҗектәге кебек үк көчле түгел. Шулай да, беренче иҗектә о – ө авазлары килсә, иренләшү сүзнең тамырында барлык иҗекләрдә дә көчле була (гоморъ, богол, сөнгө, төртөнмякъ, сөчөк).

Татар телендәге иренләшкән у, ү авазларына килгәндә исә, эш бө-тенләй башкача тора. Бу авазлар татар телендә сүзнең беренче иҗегендә генә иренләшәләр. Лабиаль гармония икенче һәм соңгы иҗекләргә җәелә алмый. Мәсәлән, коңгырт, бөгелү, богыл, сөңге, очкын, угыл сүзләрендә ачык күренә, ә хәзерге татар әдәби телендә кунгуръ сары, бүкүлмәк, бугулъ, сүнгү, үцкүнъ, үгүлъ формалары кулланылмый.

Тартык авазлар да тарихи артикуляцион яктан кайбер үзгәрешләр кичергәннәр. Бу өлкәдә авазларның бер-берсе белән күчешен, алмашынуын һәм төрле фонетик үзгәрешләрне күзәтергә мөмкин. Башка төркемгә кергән төрки телләрдән (угыз, уйгур)

аермалы буларак, татар теленең тар-тыклар өлкәсендә дә болгар – кыпчак телләренә хас үзенчәлекләр төп урынны алып тора [ Хаков: 110 ].

Мисаллардан күренгәнчә, сүзләрнең мәгънәләре үзгәрмәгән. Бары тик аларның фонетик тышчалары үзгәреш кичергән. Бу бигрәк тә, тартык авазларның чиратлашуында күренә.

Шулай ук, тупланган мисалларда протеза, эпентеза күренешләрен күзәтергә мөмкин. Протеза күренешенә мисаллар: **правосудие** "адалятъ" [Ю., 1900: 11], "хөкемдә гаделлек" [Н., 1892: 145]; (адалятъ – гаделлек). **Знамя** "гиямъ, тү" [Г., 1804: 199], "байрак, галям" [Н., 1892:55], "алям" [В., 1894: 85]; (алям – галям). **Красивый** "үямъ" [Н., 1878: 33], "гүзәл, матур" [Н., 1892: 69], "ямьле, шыклы, кюркям, чибәр, сылу" [В., 1894: 112], "сүлүвъ" [Г., 1804:248]; (үямъ – ямь). **Разум** "фягемъ" [Н., 1878: 81], "гакыл" [Н., 1892:172], "акыл" [В., 1894: 273]; (гакыл – акыл).

Эпентеза күренешенә мисаллар: **полководец** "сяргаскярь" [Ю., 1900:52], "сяриляшкярь" [Г., 1804: 413], "пулык башлыгы" [В., 1894: 221]; (пулык башлыгы – полководец). **Гордо** "тяккабер, ирямеү" [Г., 1804: 99], "һавалы" [Н., 1892: 31], "көпөр, олосымак, горбоян" [В., 1894: 48]; (горбоян – грубиян). **Гнев** "гынабя" [О., 1892: 58], "үпкә, ачу" [В., 1894: 45]; (гынабя – гнев). **Книжка** "рисаля" [Н., 1878: 61], "дәфтәр, китап" [Н., 1892: 65], "кенягя" [В., 1894, 122], "китабцыкъ" [Г., 1804:234] (кенәгә –книга).

Шулай итеп, милли әдәби тел нормалашу чорында күп кенә борынгы тел формалары фонетик яктан үзгәрешләр кичерәләр. Әлеге сүзләрдә фонетик тышчалары үзгәрү һәм авазларның чиратлашуы күзәтелә. Алар лексик мәгънәне үзгәртмиләр, ә бары тик фонетик вариантларны биреп, синонимик рәтне баеталар. Татар телендә авазларның мондый тарихи чиратлашуы билгеле бер закончалыклар нигезендә бара һәм бер система тәшкил итә.

## Синонимнарның морфологик юл белән ясалышы

XIX гасыр сүзлекләрендә иң аз очраганы — төп сүзгә синоним сүз яки бер үк функцияле кушымчалар ялгану юлы белән ясалган синонимнар. Алар түбәндәгеләр: **благородный** "бүярзадя, яхшызадя" [Г., 1804: 14]. –задә кушымчасы хәзерге татар телендә сирәк очрый. Ул фарсы теленнән кергән. Бу кушымча белән килгән исем атасының титулы белән белдерелгән улны тәкъбир итә [ Татар грамматикасы, т.I :285 ]. Ә бу очракта ул сыйфат белән килеп, теләсә кемгә карата әйтелә ала.

**Вдруг** "берьюлы, берчя" [Г., 1804: 42]. Бер тамырыннан ике төрле вариант ясалган. Берчя –архаик форма, ләкин ул кайбер диалектларда очрый. Мәсәлән, мәләкәс, карсун сөйләшләрендә "бөтенләй" һәм "бер буйдан" мәгънәсендә кулланыла. Пермь татарлары сөйләшендә "бертигез" [ТТДС., 1993:51] мәгънәсе очрый.

**Зверь** "хайванъ, анъ" [Г., 1804: 191]. Анъ – архаик форма. Ул "хайван" мәгънәсен белдергән. Бүгенге көндә куян, болан, арыслан сүзләрендә сакланган. Соңрак хайван сүзе барлыкка килгән.

**Передникъ** "алъябкыч" [Ю., 1900: 7], "ал – чүпряк, алжабкыч" [В., 1894:195]. Монда ике сүз кушылып ясалган [ал + чүпрәк һәм ал + япкыч]. Элегрәк ал – чүпрәк дип, ә хәзер алъяпкыч дип кулланыла.

**Бытие, сущность** "булдык" [О., 1892: 50], "булмыш, булдык, булу" [В., 1894: 15]. Әлеге сүз бул - тамырына төрле заман формалары кушылып ясалган (бул + билгесез үткән заман = булмыш), бул + билгеле үткән заман (булдык), бул + хәзерге заман (булу).

**Хлеб** "дурчмак" [О., 1892: 62], "икмяк, кюмяч, ипей" [В., 1894: 352]. Икмәк һәм ипей сүзләре ик - тамырыннан ясалганнар. Икмәк – әдәби телдә, ипей – сөйләм телендә кулланыла.

**Разговорчивый** "гябчуни" [Н., 1892: 89], "сөйләшү, сүзчән" [В., 1894: 262]. Монда гәп сүзенә - чуни кушымчасы ялганып яңа сүз барлыкка килгән. Әлеге кушымчаның - чән сыйфат ясагыч

кушымчасының архаик варианты булуы да мөмкин. **Подсолнечник** "ай багаръ" [Ш.Г., 1893: 16], "көнбагыш" [Н., 1892: 133]. Бу берәмлек - багу (көнгә, кояшка) багу, айга багу) тамырыннан ясалган. Әлеге үсемлекнең чәчәге кояш формасына охшаган булу яки өскә, ягъни күккә (айга, кояшка) карап үсүе дә шулай аталуга сәбәп булырга мөмкин. Айбагар сүзе карсун, стәрлетамак, хвалын, мәләкәс сөйләшләрендә "көнбагыш" мәгънәсендә кулланыла [ТТДС., 1993:21].

**Чистить** "арчымакъ" [Ю., 1900:7], "аруламакъ, тазаламакъ" [В., 1894:361], "пакъламакъ" [Н., 1878: 221]. Аруламакъ һәм арчымакъ сүзләре ар - тамырыннан ясалып төрле грамматик формаларда килгәннәр.

**Скатерть** "ашмулыкъ" [Ю., 1900: 14], "ашжаулык" [В., 1894: 297], "ашяулыкъ, софра" [Н., 1892: 184], "дястүрганъ" [Г., 1804:539]. Аш сүзенә мулык һәм яулык сүзләре ялганып, ашяулык, ашмулык синонимнары барлыкка килгән. Софра сүзе дә "аш, табын" мәгънәсен бирә.

**Больница** "аурулар өе" [Ю., 1900: 15], "шпитал, чирлеләр өе" [В., 1894: 11], "аурухана, шифахана" [Н., 1892: 10]. Аурухана һәм шифахана синоним сүзләре - хана кушымчасы ялганып ясалган. Бу кушымча белән килгән исемнәр ясаучы нигез белән бәйләнешле нинди дә булса җитештерү, җәмәгать туклануы предприятиясен, дәвалану учреждениесен тәкъбир итә [ Татар грамма-тикасы. т.I :285 ].

**Кланяться** "башрмакъ" [Ю., 1900: 22], "бүкүлмәк" [Н., 1892:65], "башкүяменъ" [Г., 1804: 231]. Монда башрмакъ (баш ору) һәм башкүяменъ сүзләре бер тамырдан ясалганнар. Баш кую (башкүяменъ) аңлатмалы сүзлектә болай аңлатыла: 1. ял итү яки иркенрәк урнашу өчен урын эзләү; 2. корбан булу, һәлак булу. Баш ору: 1. башны бәргәләү, баш белән сугу; 2. аеруча түбәнчелек һәм хөрмәт билгесе – кешенең аяк туры-сына бөгелеп баш ию [ТТАС., 1977, т.1: 137] мәгънәсен белдерә.

**Жильё, жилище** "торлакъ" [Ю., 1900: 37], "мәкам" [Н., 1892: 45], "тора торган урын" [В., 1894: 65], "турушъ, торлавъ" [Г., 1804: 159].

Әлеге сүзләр тор - тамырыннан ясалган һәм төрле грамматик вариантларда килгән: торлакъ - турушъ - турлавъ.

**Безпамятный** "ядьсез, ядкашъ, дагулъ, хатерсезъ" [Г., 1804: 8], "һушсыз" [Н., 1892: 8], "катерсез" [В., 1894: 5]. Яд нигезеннән ясалган ядьсез, ядкашъ сүзләре "хәтерсез" мәгънәсендә киләләр. Яд сүзе "истәлек, хатирә, хөрмәт" дигәнне аңлата [ТТАС.,1981, т.3:622].

**Родственник** "кардәш" [Н., 1878:111], "карындаш, туган" [В., 1894: 281]. Кардәш һәм карындаш сүзләре бер тамырдан ясалган. Вакытлар үтү белән карындаш сүзе кыскарып кардәш дип кулланыла башлаган.

Күргәнебезчә, сүзлекләрдә бу төргә сүзләр аз очрый. Моннан шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: әлеге төр сүзләрнең синонимик вариантларын ясауда башка төрләр белән чагыштырганда пассиврак кулланылган.

Тупланган мисаллар әдәби телнең семантик, фонетик һәм морфологик яктан тотрыклы әдәби нормаларга күчү процессы халыкның сөйләм теле җирлегендә баруын күрсәтә. Моны әлеге сүзләрнең диалектларда кулланылуы да дәлилли.

Синонимнарның барлыкка килү юлларын тикшерү мондый нәтиҗәләргә китерде:

1. Татар теленең синонимиясен баетуда семантик юл иң зур урынны алып тора. Бер чорда синоним итеп кулланылган сүзләр, вакытлар үтү белән, синонимлыкларын югалта, шулай ук, синоним парлары булмаганнары синонимлашырга, яңа синоним парлар барлыкка килергә мөмкин. Семантик юл белән барлыкка килгән синонимнарның күбесе я төшеп калган, я бик сирәк кулланыла (бикаръ, наүмидъ, ядкашъ, дагулъ, икекатъ, ювокъ, ахшам, назар, тилдакъ, анышлы, дана, нейзя һ.б). Ләкин шактый гына өлеше бүген дә татар телендә яки диалектларда яшәвен дәвам итә (эшсез, өметсез, байлык, дәү, олы, зур, гидай, лагун, исән, сау, аман, бөртек, үрә, бакрач ) һ.б.

2. Синонимик рәтне тулыландыруда фонетик юл мөһим роль уйный. Фонетик үзгәрешләргә күбрәк алынмалар дучар була. Алар

телнең үз закончалыкларына яраклаштырылып әйтеләләр: шуть, патнусъ, кызау, груп, эзбись, словар, титрад, богол, сүнгү, сөчөк. Шулай ук, тартык авазларның күчешен дә күрергә мөмкин: сөян — сөял, каравъ — карау, ботак — ботагъ, хатерсез — катерсез, мичкя — пичкя һ.б.

3. Морфологик юл белән барлыкка килгән синонимнар сүзлекләрдә чагыштырмача азрак табылды. Шуңа да карамастан, алар килеп чыгышлары, барлыкка килү юллары белән игътибарга лаек. Әлеге синоним сүзләр хәзерге татар әдәби телендә кулланылмый: бүярзадя, яхшызадя, анъ, алчюпряк, булдык, булмыш, булу, гябчуни, аурулар өе, чирлеләр өе, тор-лакъ, турушъ, турлавъ һ.б. Кайберләре исә, бүген дә татар телендә һәм диалектларда очрый: берьюлы, хайван, алъябкыч, дурчмак, айбагар, кардәш һ.б.

Телебезнең сүзлек составы — зур тарихи үсеш нәтиҗәсе. Хәзерге телдәге сүзләр үзләренең барлыкка килүләре, килеп чыгышлары ягыннан төрле чорларга карыйлар.

Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы бик борынгы чордан ук яшәп килгән, төрки халыкларның барысы өчен дә уртак булган төрки телгә барып тоташа. Бу телдәге сүзләрнең күпчелеге хәзер дә җәмгыятьтә, кеше тормышында, көнкүрешендә иң әһәмиятле, иң кирәкле төшенчәләрне белдерә. Алар телнең төп сүзлек фондын тәшкил иткәннәр, шуларга нигезләнеп, телнең сүзлек составы үсә, үзгәрә, камилләшә барган.

Татар теленең синонимик рәтләрендәге сүзләр төрле телләрдән килеп кергәннәр. Төрки-татар сүзләре белән беррәттән, алар арасында гарәп, фарсы, рус һәм европа сүзләре зур урын алып тора. Алар әүвәл башка кабиләләр белән, соңга таба төрле халыклар, дәүләтләр белән аралашу нәтиҗәсендә килеп кергән [ Сафиуллина :58 ].

Татар телендә үзенең күплеге һәм активлыгы белән аерылып торган алынмалар арасында иң беренче чиратта гарәп – фарсы һәм рус алынмаларын күрсәтергә кирәк. Без тикшергән XIX гасыр сүзлекләрендә бер сүзнең синонимнары булып төрки сүзләр дә, гарәп – фарсы һәм рус алынмалары да килә. Шуңа күрә, без аларны аерым – аерым карап китәрбез:

1) төрки сүзләр һәм гарәп – фарсы алынмалары синонимлыгы;
2) гарәп – фарсы алынмалары һәм рус теленнән кергән сүзләр арасында синонимлык;
3) төрки сүзләр синонимиясе;

## Төрки сүзләр һәм гарәп – фарсы алынмалары синонимлыгы

Сүзлекләрдә мәгънәдәш сүзләрнең күпчелеген төрки – татар сүзләре һәм гарәп - фарсы алынмаларыннан торган синонимик парлар алып тора. Бу алынмалар, Болгарда ислам дине кабул ителгәннән соң, сәүдә, дин, сәясәт, мәдәният, әдәбият-сәнгать бәйләнешләре аша килеп кергәннәр.

Ә хәзер әлеге төркемгә кергән мисалларны карап китик. Иң беренче Ш. Габделгазиз хезмәтеннән алынган үрнәкләргә игътибар итик: у**читель** "устазъ" [Г.Ш., 1893:46], "остаз, мөдәррис, мөгаллим, хәлфә" [Н., 1892: 56], "өйрәтүче, өйрәтүче катын- кыз" [В., 1894:349], "мулла" [Г., 1804: 639]. Сүзлек авторлары биргән әлеге вариантлар төрле мәгънә төсмерләрен белдерәләр. Мәсәлән, мөгаллим сүзе "укытучы, өйрәтүче кеше"не атый [ТТАС., 1979, т.2: 425]. Әмма мөгаллим берәмлеге искергән сүз төсмере белән кулланыла. Шул ук синонимик рәткә керә торган остаз атамасы исә, укытучыны гына түгел, гомумән, "берәр яхшы һөнәргә өйрәтүче кеше" не [ТТАС.,1979, т 2: 480] белдерә, ә хәлфә сүзе "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә "иске мәдрәсә укытучысы" буларак кына бирелә [ТТАС., 1981., т.3: 383]. Гарәп-фарсы алынмалары белән беррәттән А. Воскресенский "өйрәтүче, өйрәтүче катын-кыз" кебек вариантларын да китерә (остаз, мөгаллим, мөдәррис, хәлфә -өйрәтүче, өйрәтүче катын-кыз).

**Ученик** "шакердъ" [ГШ., 1893:7], "талип" [Н., 1892:214], "укучы, өйрәнүче" [В., 1894:349]. Шәкерт 1. мәдрәсәдә укучы; 2. укучы, өйрәнчек, 3. нинди дә булса тәгълиматны, кемнең дә булса өйрәтүләрен, эшен дәвам иттерүче; [ТТАС., 1979, т.2:533] дип бирелә.

Талип "укучы, студент" [ТТАС., 1979, т.2: 24] дип аңлатыла һәм иске сүз икәнлеге күрсәтелә. "Укучы, өйрәнүче" төрки сүзләр һәм алар бүгенге көндә дә кулланыла (шәкерт, талип – укучы, өйрәнүче).

**Сердце** "кунел" [ГШ., 1893: 34], "кальп, күңел" [Н., 1892: 183], "жөряк" [В., 1894: 295], "юрак" [Г., 1804: 535]. Монда күңел сүзе "йөрәк" мәгънәсендә килгән. Элегрәк шул мәгънәдә кулланылган булса, соңыннан бер мәгънәгә генә беркетелеп, хисләр, тойгылар белән бәйләнешле төшен-чәне белдерә башлый [кальп – йөрәк, күңел].

**Разносщик** сүзен М. Юнысов "асламчы" дип бирә [Ю., 1900: 12]. К. Насыйри сүзлегендә ул "күтәреп йөртеп сатучы" [Н., 1892: 170], А. Воскресенскийда "кырык тартмачы, уак тауарчы, асламчы" [В., 1894: 271] дип тәрҗемә итәлә. Асламчы сүзе аңлатмалы сүзлектә дә бар һәм ул болай аңлатылган: "төрле товарларны йөреп сатучы, кырык тартмачы" [ТТАС., 1977, т.1: 77]. ]. Сүзлекләрдә бирелгән вариантларны абсолют синонимнар дип әйтергә мөмкин. Чөнки элекке заманнарда кырык тартмачылар авылларда күтәреп йөреп вак товар белән сату иткәннәр (асламчы – күтәреп йөртеп сатучы, кырык тартмачы, вак товарчы).

М. Юнысов **человек** сүзенең "бяндя" [Ю., 1900: 22] дигән тәрҗемәсен тәкъдим итә. Ә К. Насыйри мондый вариантларын бирә: "кеше, "адәм" [Н., 1892: 220]. Бәндә –фарсы, адәм – гарәп теленнән кергән алынмалар. Кеше сүзе исә, төрки сүз булып санала. Әлеге өч вариант та бүгенге көндә актив кулланыла (бәндә, адәм – кеше).

**Пища** сүзенең сүзлекләрдә бирелгән вари-антларын карап китик: "тагам" [Ю., 1900: 38], "гыда, тәгам, аш" [Н., 1892: 126], "җим, ашамлык" [В., 1894: 202]. Әлеге сүзләр мәгънә төсмерләре белән бераз аерылалар. Мәсәлән, тәгам сүзе киң мәгънәдә кулланыла. Ул "азык, ашамлык, ризык"ны белдерә [ТТАС., 1981, т.3: 208], искергән сүз булып санала. Җим исә, киресенчә, таррак функцияне үти. Ул "кош-корт, тавыклар һәм казлар өчен махсус әзерләнгән азык: көрпә, ярма кебек нәр-сәләрне болгатып ясалган ботка сыман масса"ны һәм "балык тотканда кармакка кидерелә торган суалчан, чебен, корт кебек алдавыч"ны аңлата [ТТАС., 1981, т.3: 773]. Гыда сүзе аңлатмалы һәм

диалектологик сүзлекләрдә юк. Бүгенге көндә ул татар телендә бөтенләй кулланылмый. Ә төрек телендә актив беләмлек санала һәм, К.Насыйри күрсәткәнчә, ризык мәгънәсендә кулланыла. Аш белән ашамлык синонимнары кулланышлары ягыннан бераз аерылалар. Аш 1. эчәргә яраклы ашамлык, азык; 2. беренчегә бирелә торган шулпалы аш; 3. ашауны, ризык кабул итү; 4. кунак мәҗлесе; мәгънәләрендә йөри [ТТАС., 1977, т.1:87]. Ашамлык сүзе телебездә гомумирәк мәгънәдә: "ашый торган, ашарга яраклы, ашау өчен ярарлык хәлгә китерелгән азык" [ТТАС., 1977, т.1: 88] яши. Бүгенге көндә исә, татар телендә аш, ашамлык, җим сүзләре бик еш, ә тәгам сүзе сирәгрәк (аш, ашамлык – җим, гыда, тәгам).

**Потокъ** сүзенең, шулай ук, сүзлекләрдә синонимик парлары китерелә: "туфан" [Ю., 1900:41], "су ташу" [Н., 1892: 143], "инеш" [В., 1894: 231]. Туфан – гарәп алынмасы, ә су ташу һәм инеш – төрки-татар сүзләре. Туфан сүзе хәзерге татар телендә "бик каты яңгыр, су ташкыны, су баскыны" [ТТАС., 1981, т.3: 179] мәгънәсендә кулланыла. Инеш "кечкенә, сай һәм тар елгачык"ны белдерә [ТТАС., 1977, т.1:394]. Русча-татарча сүзлектә "ташкын, елга" [РТС.,1985: 454] дип тәрҗемә ителә (туфан — су ташу, инеш).

**Запрещение** сүзен авторлар болай тәрҗемә итәләр : "кисәтү, тыю, туктату" [В., 1894:77], ә М. Юнысов гарәп чыгышлы "манигы" [Ю., 1900: 91] сүзен өсти. Бу сүз гарәп телендә 1. тыючы, тоткарлаучы, бер эшнең үтәлмәвенә сәбәп булучы; 2. киртә мәгънәләренә ия [ГТРАС, 1993: 252]. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә манигъ сүзе иске мәгънә төсмере белән күрсәтелә [ТТАС.,1979, т.2: 365]. Хәзерге вакытта төрки вариантлар – кисәтү, тыю, туктату еш кулланыла (манигы – кисәтү, тыю, туктату).

**Покой** сүзен М. Юнысов "маза" дип тәрҗемә итә [Ю., 1900: 92], шул ук сүзне К. Насыйри "тынычлык" [Н., 1892:136], А. Воскресенский "рахят, жал" [В., 1894:219] вариантларын бирәләр. "Тынычлык" һәм "кайгы, борчу, мәшәкать" [ТТАС., 1979, т.2 :356] мәгънәләренә ия булган маза сүзе бүгенге көндә дә очрый. Тынычлык, рәхәт, ял

сүзләре дә төрле мәгънә төсмерләре белән сөйләмдә еш кулланыла (маза, рәхәт –тынычлык, ял).

**Замучивание** сүзенең автор диалекталь вариантын бирә: "маталау" [Ю., 1900:93]. Ул тау ягы, тархан сөйләшендә "бераз белү, әз – мәз сукалау" мәгънәсендә йөри [ТТДС,, 1993: 220]. К. Насыйри гарәп сүзе "газаплау" [Н., 1892: 136], А. Воскресенский "йөдәтү" дигән төрки-татар лексемасы белән тәрҗемә итә [В., 1894: 75]. Әлеге сүзләр мәгънә төсмерләре белән бер-берсеннән аерылалар. Газаплау "җәзалау, физик интектерү"не белдерсә [ТТАС., 1977, т.1: 253], йөдәтү "аптырату, әледән-әле борчып тору, тынгылык бирмәү" мәгънәләренә ия [ТТАС., 1977, т.1: 465] (газаплау- йөдәтү, маталау).

Тагын бер алынма сүзгә тукталып үтик. М. Юнысов сүзлегендә **цепь** "чибагач, чылбр" [Ю., 1900: 102] дип тәрҗемә ителә. К. Насыйри хезмәтендә бу сүз "зәнҗир" [Н., 1892: 219] дип бирелә. Ул фарсы теленнән кергән, "чылбыр, богау" дигән мәгънәне белдерә [ГТРАС., 1993: 131]. А.Воскресенский "чылбыр, кушыу (связь) " [В., 1894: 235], И. Гиганов "зиндзир" [Г., 1804: 647] вариантларын күрсәтәләр. Хәзерге татар телендә зәнҗир һәм чибагач сүзләре очрамый, бары тик чылбыр сүзе генә кулланыла (зәнҗир –чылбыр, кушыу).

**Признак** сүзен К. Насыйри "әсәр" дип бирә [Н., 1878: 15]. Ә 1892 елгы хезмәтендә "галәмәт" дип тәрҗемә ителә [Н., 1892: 151], А. Воскресенский төрки вариантын бирә: "билге" [В., 1894:242]. Әсәр, галәмәт – гарәп теленнән кергән сүзләр. Галәмәт сүзе хәзерге вакытта да актив кулланыла һәм ул түбәндәге мәгънәләргә ия: 1. нәрсәне дә булса күрсәтә, белдерә, яки алдан сиздерә, искә төшерә, хәбәр итә торган эз, билге; 2. искиткеч, гаҗәпләнерлек; [ТТАС., 1977, т.1: 258]. Әсәр сүзе өч мәгънә белдерә: 1. нинди дә булса өлкәдә берәүнең иҗади хезмәте; 2. нәрсәне дә булса билгеләргә, ачыкларга мөмкинлек бирә торган күрсәткеч, эз, билге; 3. тәэсир, йогынты; [ТТАС., 1981, т.3: 633]. Хәзерге татар телендә галәмәт, билге сүзләре бик еш, ә әсәр сүзе бераз сирәгрәк кулланыла, К.Насыйрида теркәлгән мәгънәгә эз синонимы туры килә. Мәсәлән, Монда җиләкнең әсәре дә юк (автор материалы) (галәмәт, әсәр – билге).

**Переселение** берәмлеге К. Насыйриның беренче хезмәтендә "гиджрят" [Н., 1878: 110], икенчесендә "халык күчү" дип тәрҗемә ителә [Н., 1892: 124]. А. Воскресенский "күчеп китү" дип [В., 1894: 193], ә И. Гиганов фонетик яктан үзгәртелгән вариантын бирә: "кюцюрмякликъ" [Г., 1804: 375]. Һиҗрәт (гиджрять) сүзе гарәп теленнән алынган, "күчеп китү, чит илгә китү"не белдерә [ГТРАС., 1993: 784] (һиҗрәт, халык күчү – күчеп китү).

**Гибель** сүзен К. Насыйри гарәп берәмлекләре ярдәмендә тәрҗемә итә. Ул аны "хараб" [Н., 1878: 57], "һәлакәт" [Н., 1892: 30] дип бирә. И. Гигановта "халяк булмак" [Г., 1804: 91] варианты бар. Ә А. Воскресенский бу синонимик ояны төрки-татар сүзләре белән баета: "үлү, бетү, югалу, сүнү" [В., 1894: 144]. Харап сүзе хәзерге татар телендә башка мәгънә төсмерендә кулланыла. Ул 1. куркыныч, котычкыч, бик начар; 2. бик, искиткеч; 3. үпкә катнаш гаҗәпләнүне яки искитмәүне, иронияне белдерә [ТТАС., 1981, т.3: 363]. Күбрәк телдә харап булу формасында очрый. "Һәлак булу, бәхетсезлеккә төшү, бәла-казага, берәр күңелсез хәлгә очрау" мәгънәсендә кулланыла [ТТАС., 1981, т.3: 363]. Хәзерге вакытта төрки вариантлар да, гарәп алынмасы булган һәлакәт сүзе дә актив кулланыла. Харап сүзе әлеге мәгънәдә сирәгрәк очрый (һәлакәт, харап, һәлак булу – үлү, бетү, югалу, сүнү).

К. Насыйри 1878 елгы хезмәтендә күбрәк гарәп-фарсы алынмаларына игътибар итә. Ә икенче сүзлегендә исә кайбер очракларда төрки вариантларны да бирә. Мәсәлән, **часть** сүзе беренче хезмәтендә "хисса" [Н., 1878: 57], икенчесендә "өлеш" [Н., 1892: 219] дип тәрҗемә ителә. А. Воскресенский "кисәк" вариантын да бирә [В., 1894: 357]. Хисса "өлеш, кемгә дә булса тиешле күләм, пай" мәгънәсен белдергән [ТТАС., 1981, т.3: 369]. Хәзер ул сөйләмдә кулланылмый (хисса – кисәк, өлеш).

**Воспоминание** сүзенең "зикр" [Н., 1878: 60], "искә төшерү" [Н., 1892:20], "искә алу" [В., 1894: 29] кебек синонимик вариантлары бирелә. Күргәнебезчә, беренче хезмәттә – гарәп варианты. Ул 1. искә алу; 2. телгә алу, әйтеп узуны белдерә [ГТРАС., 1993: 129]. Төрки

сүзләр – искә алу белән искә төшерү бер – берсенә абсолют туры киләләр һәм бүгенге көндә дә актив кулланылалар.

**Плохой** сүзенең сүзлекләрдә "чак." [ГШ., 1893: 40], "начар" [Н., 1892: 127], "алама" [Ю., 1900: 13], "шакшы, жараусыз" [В., 1894: 60], "ухшавсезъ" [Г., 1804: 388] кебек синонимик вариантлары теркәлгән. Әлеге сүзгә синоним булып килгән берәмлекләр мәгънә төсмерләре ягыннан бер-берсеннән аерылалар. Чак сүзенең "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә дүрт мәгънәсе бирелә: 1. кеше билгеле бер урында яшәгән, булган яисә яшь аралыгына туры килгән вакыт; 2. Көч- хәл белән, көчкә, авырлык белән, кыенлык белән; 3. киемнең берәр кешегә төгәл туры килүен, таман булуын белдерә; 4. начар, әшәке. Бу мәгънәсе бары тик диалектларда гына кулланыла [ТТАС., 1981, т.3:401]. Шакшы 1. чиста түгел, пычранган; 2. гайбәтле, кешенең абруен төшерүгә нигезләнгән сүзне белдерә [ТТАС., 1981, т.3: 486]. Яраусыз сүзе диалектларда "җитлекмәгән, булдыксыз, юньсез" мәгънәсендә кулланыла [ТТАС., 1981, т.3: 646]. Минзәлә һәм каргалы сөйләшләрендә "начар" мәгънәсендә алама сүзе кулланыла [ТТДС., 1993: 24] (чак, начар, охшаусыз – алама, шакшы, яраусыз).

**Толковый** сүзен Ш. Габделгазиз "җайлы" [ГШ., 1893: 41] дип тәрҗемә итә. К. Насыйри "гакыллы" [Н., 1892: 203], А. Воскресенский "җайлы, исябле" [В., 1894:329], И. Гиганов "тяфсир, кылгүц" [Г., 1804: 605] вариантларын бирәләр. Русча-татарча сүзлектә 1. акыллы, төпле, мәгънәле; 2. аңлаешлы, төшенерлек дип тәрҗемә ителә [РТС., 1991: 631]. Ә сүзлек авторлары бу сүзнең төрле вариантларын тәкъдим итәләр. Аларның кайберләре мәгънә төсмерләре ягыннан аерыла. Мәсәлән, исәпле сүзе "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә 1. исәпләнгән, санаулы; 2. кайгылы, хәсрәтле, сагышлы дип аңлатыла [ТТАС., 1977, т.1:429]. Тәфсир берәмлеге исә 1. берәр нәрсәнең аңлатмасы, ачыкламасы; 2. Коръән сүзләренә аңлатма дип бирелә [ТТАС., 1981, т.3:233]. Кылгүц сүзе аңлатмалы һәм диалектологик сүзлекләрдә күрсәтелми. Хәзерге вакытта К. Насыйри биргән гакыллы, акыллы, җайлы сүзләре ешрак кулланышта йөри (гакыллы, исәпле, тәфсир – җайлы, кылгыч).

М. Юнысов **свирепый** сүзенең "бумалы" [Ю., 1900: 32] дигән тәрҗемәсен бирә. "Зәһәр, каты" вариантлары [Н., 1892:181] К. Насыйри сүзлегендә күрсәтелә. А. Воскресенский "бумалы, кансыз" [В., 1894: 291], И. Гиганов "царыс" [Г., 1804: 529] дип бирәләр. Ә русча-татарча сүзлектә исә, әлеге сүз "рәхимсез, аяусыз, кансыз, мәрхәмәтсез, шәфкатьсез" [РТС.,1985: 559] дип тәрҗемә ителә. М. Юнысов һәм А. Воскресенский биргән варианты – бумалы сүзе аңлатмалы сүзлектә " бума авырулы" [ТТАС., 1977, т.1: 191] дип бирелә. Чарыс (царыс) сүзе "шәп чаба торган, елдам [ТТАС., 1981, т.3: 411] дип аңлатыла. Тау ягы, тархан һәм мәләкәс сөйләшләрендә 1. оялчан, кыргый; 2. кулга килми торган, өркәк [ТТДС., 1993: 85] мәгънәсендә кулланыла (зәһәр, чарыс –бумалы, каты).

**Сильный** берәмлегенә сүзлек авторлары түбәндәге вариантларны тәкъдим итәләр: "дарманлы" [Ю., 1900: 67], "каты, көчле, куәтле" [Н., 1892: 184], "батыр, шяб" [В., 1894: 296]. Дәрман "рухи һәм физик мөмкинлекләр, көч, хәл"не белдерә [ТТАС., 1977:т.1, 319]. Аңлатмалы сүзлектә каты сүзенең тугыз мәгънәсе бар. Ләкин кешенең физик мөмкинлекләренә карата әйтелгән мәгънәсе чагылыш тапмый. Бары тик кешенең характер үзенчәлеген белдергән "кырыс, катгый" мәгънә төсмере генә күрсәтелә [ТТАС., 1979,т.2: 73]. Көчле, куәтле берәмлекләре мәгънәләре ягыннан абсолют туры киләләр. Батыр исә, шул сыйфатларга, ягъни курыкмаучанлык, кыюлык, көчлелек, уңганлык сыйфатларына ия шәхесне белдерә [ТТАС., 1977, т.1: 134]. Эшнең үтәлү рәвешен, дәрәҗәсен шәп сүзе белән бирергә мөмкин. Ул мондый мәгънәләргә ия: 1. яхшы, әйбәт, менә дигән итеп; 2. көчле итеп, интенсив рәвештә; 3. тиз, кызу-кызу, җәһәт; [ТТАС., 1981, т.3: 534]. Әлеге синонимик оя алынма сүзләр исәбенә баетылган. Дәрманлы – фарсы, куәтле – гарәп теленнән кергән синонимнар. Ә каты, көчле, батыр, шәп берәмлекләре төрки-татар сүзләре булып санала (дәрманлы, куәтле – каты, көчле, шәп, батыр).

Мәгънә төсмерләре белән бер-берсеннән аерылган "садя" ***[глупец]*** [Н., 1878:63], "җаһил, ахмак" [Н., 1892: 30], "тиле" [Г., 1804: 94] берәмлекләре, шулай ук, чыгышлары ягыннан төрле. Җаһил, ахмак – гарәп алынмалары, ә садә – фарсы теленнән кергән синоним.

Ул "гади, катлаусыз" дигәнне аңлата [ГТРАС., 1993: 496]. Бу алынмалар белән беррәттән төрки чыгышлы тиле сүзе дә китерелә. Тиле берәмлеге акылы юк, акылга сай кешене, кат-кат әйтеп тә аңламаучыны белдерсә [ТТАС., 1981, т.3: 97], ахмак бу төсмернең иң югары дәрәҗәсен күрсәтә дип фаразлана. Җаһил "белемсез, укымаган, надан" [ГТРАС., 1993: 765] кешене характерлый. "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә садә "бик гади" дип аңлатыла [ТТАС., 1981,т.3: 614]. К. Насыйри биргән мәгънәсе күрсәтелми.

XIX гасыр русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләрендә исем һәм сыйфат сүз төркеменә караган сүзләрнең синонимлыгы киң таралган. Фигыльләр синонимлыгы бик аз чагылыш таба. 1900 елда басылып чыккан М. Юнысовның сүзлегендә **понять, понимать** сүзе "апламак" дип тәрҗемә ителә [Ю., 1900: 18]. К. Насыйри "фәһемләмәк, фәһем итмәк" дигән фарсы вариантын бирә [Н., 1878: 183]. А. Воскресенский төрки сүз белән "аңлау" дип тәрҗемә итә [В., 1894: 225]. Апламак һәм аңлау сүзләре фонетик үзгәрешләр кичерсәләр дә, бер үк тамырдан ясалганнар. Апламакъ сүзе хәзер инде кулланыштан төшеп калган.

М.Юнысов **осмелиться** сүзенең "базмак" [Ю., 1900:26] вариантын бирә. К. Насыйри гарәп чыгышлы "җөрьят кылмак" сүзе белән тәрҗемә итә [Н., 1892:111]. А. Воскресенский "кыйыулану, батырлану" сүзләре [В., 1894:178] белән синонимик рәтне баета. Сүзлек авторлары тәкъдим иткән әлеге вариантлар абсолют синонимнар булып ки-ләләр. Алар бүгенге сөйләмдә дә актив кулланышта йөриләр (җөрьят кылмак – базмак, кыюлану, батырлану).

**Сочинять** сүзе русча-татарча сүзлектә 1.иҗат итү, язу; . уйлап чыгару, үзеннән чыгару, ялган хәбәр чыгару, уйдырма кору [РТС., 1985: 596] дип тәрҗемә ителә. М. Юнысов исә, "тяснифъ итмякъ" дигән гарәби сүзн бирә [Ю., 1900:47], ә бу сүзнең төрки вариантын А. Воскресенский тәкъдим итә: "уйлап чыгару" [В., 1894: 311]. (тясниф итү – уйлап чыгару).

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин, татар теленең үз сүзләре булса да, кайбер төшенчәләр гарәп алынмалары белән төгәлрәк

белдереләләр, шуңа күрә бу сүзләрнең күбесе хәзерге татар әдәби телендә дә актив кулланылалар )остаз, адәм, бәндә, җим, туфан, куәтле), әмма төрки сүзләр дә кире кагылмый (укытучы, кеше, аш, ашамлык, су ташу, көчле).

## Гарәп – фарсы алынмалары һәм рус теленнән кергән сүзләр арасында синонимлык

XVIII – XIX йөзләрдә һәм XX йөз башында татар әдәби телендә Көнбатыш Европа телләреннән һәм рус теленнән кергән сүзләр киң кул-ланыла башлый. Аларның шактый өлеше нормалашып та китә. Рус алынмалары белән беррәттән, XIX йөз сүзлекләрендә гарәп һәм фарсы телләреннән алынган сүзләр дә зур урын алып тора. Шулай итеп, телнең лесик составы алынма синонимнар исәбенә дә баеый. Ә хәзер гарәп-фарсы һәм рус алынмаларыннан гына торган синонимик парларны карап китәрбез. Кайбер рус сүзләре элек-электән татар әдәби телендә үзләшеп китәләр. Алар, татар теленең үз фонетик закончалыкларына буйсындырылып, язма телдә дә, халык сөйләмендә дә бер үк рәвештә йөриләр.

Хәзерге вакытта татар һәм рус телләрендә тәрҗемәсез кулланылган **океан** сүзен М. Юнысов "дарья" дип тәрҗемә итә [Ю., 1900:67], К. Насыйри "океанус, җормохит" сүзләрен бирә [Н., 1892:107]. Дәрья "елга, зур су"ны аңлата [ТТАС., 1977, т.1 :320]. Җормохит сүзе бөтенләй сүзлектә күрсәтелми. Океанус берәмлеге рус теленә латин теленнән килеп кергән. Ләкин хәзерге вакытта ул телдән төшеп калган, искергән сүзләр төркеменә карый.

**Войска** сүзенә М. Юнысов "ляшкяр" тәрҗемәсен бирә [Ю., 1900: 89]. Бу сүз фарсы теленнән алынган. А. Воскресенский түбәндәге гарәп һәм рус алынмаларын тәкъдим итә: "чирү, армия, гаскәр" [В., 1894:26]. Гаскәр "дәүләтнең кораллы көчләре, армия" мәгънәсен белдерә [ТТАС., 1977, т.1: 262]. Чирү сүзе шул ук мәгънәдә,

ләкин искергән мәгънә төсмере белән кулланыла [ТТАС., 1977, т.1: 432].

Телебездә ныклап урнашкан һәм күп кешеләргә гарәп алынмасы икәнлеге билгеле булмаган китап сүзе сүзлекләрдә төрлечә тәрҗемә ителә: "рисаля" [Н., 1878:61], "дәфтәр, китап" [Н., 1892: 65], "княгя" [В., 1894: 104], "китабцик" [Г., 1804:234]. Әлеге синонимнар кенәгә сүзеннән кала, барысы да гарәп теленнән алынган һәм алар мәгънә төсмерләре белән бер-сеннән аерылалар. Китап сүзе киң мәгънәдә бергә төпләнгән язулы кәгазь битләре җыелмасын белдерә. Әгәр язылмаган кәгазь төпләнмәсе, ул нинди күләмдә булса да, дәфтәр булып калса, язылгач китапка әверелә. Рисалә аңлатмалы сүзлектә "хикәя" дип бирелгән [ТТАС., 1981, т.3: 596]. Кенәгә сүзенә Р. Әхмәтҗанов мондый аңлатма бирә: "кенәгә дигәне – эш кәгазьләре, һәртөрле исемлекләр, исап-хисаплар өчен, гадәттә, катыргы тышлы дәфтәр ул. Кайбер рәсми карарлар, законнар һ. б. теркәлгән китапларны да кенәгә дип атау дөрес. Кенәгә сүзе рус теленнән алынган булса кирәк. Әмма ул рус теленә безнең бабаларыбыз – борынгы төркиләр теленнән кергән. Борынгы уйгурча язма ядкәрләрдә күнигү, кинүгү, монгол һәм бурят язма телләрендә кинигэ, кинии китапны яисә китап урынына кулла-нылган озын кәгазь уралмасын белдергән. Күнигү борынгы кытайча күэн гу дигәннән килә: күэн борынгы шәрык телләрендә китап, язу, гу (кытайча) төргәк дигән сүз булган. Шулай итеп, кенәгә сүзендә әллә ничә телнең – борынгы культура учакларының эзе сакланган [ Әхмәтҗанов:3 ].

Алынма рус сүзләренең бер өлеше нормалаша, икенчеләре исә, әдәби телгә кермичә, стихияле рәвештә гади сөйләм үзенчәлекләре булып яшәүләрен дәвам итәләр. XIX йөз ахырында рус теле аша кергән сүзләр-нең кулланылышы нәкъ шул төп ике юнәлештән чыгып карала [ Хаков:173 ]. Рус теленнән гади сөйләү теленә үтеп кергән сүзләрне без синонимнарның фонетик юл белән барлыкка килү бүлегендә карап үткән идек. Гадәттә, сөйләү телендә рус сүзләре татар теленең үз фонетик законнарына буйсындырылып әйтелә: шутъ "счёты" [ГШ., 1893: 11], патнусъ, пуднус "подносъ" [ГШ., 1893: 18],

кызау "кузов" [В., 1894: 116], словар "словарь" [В., 1894, : 301], шпитал "больница" [В., 1894: 11], избис, эзбись "известка" [Ю., 1900: 18], шяб "шибко" [Ю., 1900: 71], кукшин "кувшин" [Н., 1892: 71], стих "стихотворение" [В., 1894: 316], карбүз, харбүз, тарбүс "арбуз" [Г., 1804: 156], жирябя [В., 1894: 66], ширябя, шебага "жеребей" [Г., 1804:156], чтип, степ "степъ" [В., 1894: 316], жалаш, чәше "шалаш" [В., 1894, 363].

Югарыда карап киткән үрнәкләр гарәп – фарсы һәм рус алынмаларыннан гына торган синонимик ояны тәшкил итәләр. Алынма синонимнар белән беррәттән, сүзлекләрдә төрки сүзләр дә бирелә. Мәсәлән, Ш. Габделгазиз **линейка** сүзен татарча да "линейка" дип бирә [ГШ., 1893: 11]. Әлеге сүз бүгенге көндә дә актив кулланыла. К. Насыйри исә, гарәп вариантын бирә: "җәдвәл" [Н., 1892: 73]. Ләкин бу сүз туры, дөрес мәгънәсендә бирелмәгән, чөнки ул гарәп телендә "таблица, расписание" дигәнне аңлата [ГТРАС., 1993:771]. И. Гиганов төрки сүз тәкъдим итә: сызгыч сүзен фонетик яктан бераз үзгәртеп, Себер татарлары сөйләшләренә хас булганча "цыйгыц" [Г., 1804: 263] дип тәрҗемә итә.

К. Насыйри сүзлекләрендә **стихотворение** сүзе "нәзым" [Н., 1878: 107] дип тәрҗемә ителә, ә икенче хезмәтендә исә ул "бәет" дип бирә [Н., 1892: 197]. А. Воскресенский исә, рус һәм төрки вариантларын китерә "әйтмеш, стих" [В., 1894:316]. Ләкин әйтмеш сүзе хәзерге татар телендә кулланылмый, кайбер төрки телләрдә аерым жанр буларак яши.

Мисаллардан күренгәнчә, алынма лексика кайбер очракларда шул телнең фонетик закончалыкларына яраклаштырылып, ә кайвакыт нигез телдә ничек бар, шулай кулланыла. Әлеге сүзләр татар теленең синонимиясен баетуда зур роль уйныйлар.

## Сүзлекләрдәге төрки сүзләр синонимиясе

Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы бик борынгы чордан ук яшәп килгән, төрки халыкларның барысы өчен дә уртак булган төрки тел-гә барып тоташа. Татар әдәби теленең лексик нормалары болгар-кыпчак телләре җирлегендә формалаша. Аерым этник төркемнәргә, кабиләләргә хас сүзләрне аерып күрсәтү мөмкин түгел. Татар милли әдәби теленең сүзлек хәзинәсендә бик күп катламнар бар. Алар арасында төп урынны, һичшиксез, борын-борыннан Идел буенда яшәгән болгар һәм кыпчак халкының лексик байлыгы ала. Бу – язма әдәби телдә дә, татар халкы-ның төрле диалектларга хас сөйләү телендә дә ачык чагыла [ Хаков:128 ].

XIX йөз сүзлекләрендә дә бары тик төрки сүзләрдән генә торган синонимнарны очратырга мөмкин. Бу, бигрәк тә, кеше органнары, төрле профессия вәкилләре, тормыш-көнкүреш, ашау- эчү төшенчәләрен белдерә торган исемнәрнең тәрҗемәләрендә чагыла.

Иң беренче кеше органнарын атаучы синонимнарга тукталыйк. **Желудок** сүзен Ш. Габделгазиз, Н. Остроумов, И. Гигановлар "карын" дип тәрҗемә итә [ГШ., 1893: 4], [О., 1892: 111], [Г., 1804:154], ә К. Насыйри "ашказаны" [Н., 1892: 44] вариантына туктала. Алар икесе дә бер үк мәгънәне бирәләр һәм бүгенге көндә дә актив кулланылалар. **Зрачок** берәмлегенең берничә төрки синонимы китерелә: "кузъ кешесе" [ГШ., 1893: 3], "күз карасы" [Н., 1892: 56], "кюз бябяге" [В., 1894: 85]. Күз карасы, күз бәбәге, шулай ук, абсолют синонимнар. Күз кешесе хәзерге сөйләм теленнән төшеп калган. К. Насыйри **почка** сүзенең ике вариантын тәкъдим итә: "бюрякъ, бөйөр" [Н., 1878: 35]. Хәзерге татар әдәби телендә бөер, ә диалектларда "бөерәк" сүзләре очрый [ТТДС., 1993: 32].

Сүзлекләрне тикшерү барышында ике профессия вәкилен атаучы, төрки сүзләрдән генә торган синонимик рәтне таптык. Алар: **фотограф** "тюсъ төшерүче" [ГШ., 1893: 7], "якты йазучы" [Н., 1892: 186]. Әлеге вариантларның берсе дә "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә бирелми. Бүген күбрәк рус алынмасы булган фотограф

сүзе генә кулланыла. **Слесарь** сүзенә "сувыкъ тимерче" [ГШ., 1893:7], "ак тимерче" [Н., 1892: 186], "жозакчы" [В., 1894: 301] кебек тәрҗемәләр бирелә. Хәзерге вакытта бу мәгънәдә күбрәк "тимерче" сүзе кулланышта йөри.

Тормыш-көнкүреш һәм ашау-эчүне белдерүче синонимнар: **колбаса** "тутрма" [Ю., 1900: 44], "ит тутыртмасы" [В., 1894: 105]. Тутыртма сүзе кыскарып тутрма барлыкка килгән. Тутырма "чапкан үпкә – бавыр һәм ярма катнашмасын юан эчәккә салып пешерелгән казылык" дип аңлатыла [ТТАС., 1981, т.3: 177]. **Полка** сүзенең "шурлекъ" [Ю., 1900: 71] һәм "киштә" [В., 1894: 221] синонимнары бирелә. Алар абсолют синонимнар. Икесе дә савыт-саба, китап һ. б. шундый әйберләр кую өчен, стенага беркетелеп так-тадан эшләнгән җайланма"ны атыйлар [ТТАС., 1981, т.3: 541]. **Винт** сүзенең "шүрүл, бүрма" [Г., 1804: 52], "бормалы кадак" [Н., 1892: 16] кебек төрки вариантлары китерелә. Хәзерге татар телендә шөреп сүзе ешрак оч-рый. Ул "агач яки металл әйберләрне бер-берсенә беркетә торган сырлы кадак" дип аңлатыла [ТТАС., 1981, т.3: 540]. **Валенки** сүзен К. Насыйри 1878 елгы хезмәтендә "ката" дип тәрҗемә итә [Н., 1878: 84]. А. Воскресенский сүзлегендә ул "киез итек" дип бирелгән [В., 1894: 326]. Нигездә, алар бер үк нәрсәне атасалар да, мәгънә төсмерләре белән аерылалар. Ката "тиз генә киеп алырга уңайлы булган сай һәм җиңелчә аяк киеме" [ТТАС., 1979: т.2, 69], ә киез итек "йоннан басылган итек" дигәнне аңлата. Ката, гомумән, аяк киемен белдерсә, киез итек аның бер төре генә булып санала. [ТТАС., 1979, т.2, 92].

**Булавка** берәмлегенең дә сүзлекләрдә мондый төрки синонимнары бар: "башлы иня" [Н., 1892: 11], "чукмарлы иня" [В., 1894: 15], "тюйрявүц, тюйрявүг" [Г., 1804:31]. Сөйләмдә ешрак булавка дигән рус сүзе кулланыла.

И. Гиганов хезмәтендә һәрбер сүзнең диярлек берничә вариантын, синонимын бирү күзәтелә. Мәсәлән, **кожа** сүзенең дә мондый вариантларын тәкъдим итә: "кунъ, тере, булгары" [Г., 1804: 236], "тире" [В., 1894: 105]. Әлеге синонимнар арасында болгарый сүзе, аеруча, кызыксыну уята. Бу сүзнең тарихы еракларга барып

тоташа. Күн эшкәртү – элек-электән үк болгарларның төп кәсепләреннән берсе булган. Моны X-XVI гасырларда табылган кулъязмалар да раслый. Болгарлар Бөек Кенәз Владимирга каршы сугышканда күн итектән булалар. Бу хәл кенәзне шаккатыра. Чөнки Русия җирлегендә мондый итекләрне бары тик югары катлау кешеләре генә кия алган. Болгарда ясалган күн әйберләре Бохара, Төркия һәм бөтен Азиядә "болгарый", ягъни болгар малы дип йөртелгән. Болгар күненең даны бөтен дөньяга тарала. Болгар иле авыл хуҗалыгы һәм һөнәрчелеге белән алга киткән ил була. Халкы да бай яшәгән, мал-туар тоткан. Патшаларга сыер, үгез тиреләрен налог итеп түләгәннәр. Бу тиреләр бик күп җыелу сәбәпле, алар аны эшкәртеп башка илләргә сату итә башлаганнар [Рәхимова:58 –69].

Шулай итеп, болгарый сүзе болгарлар тарафыннан эшкәртелгән күнне белдерә. Бу сүз аңлатмалы сүзлектә дә шул мәгънәдә очрый [ТТАС., 1977, т.1: 177]. Тире һәм күн берәмлекләренә килгәндә, алар да мәгънә төсмерләре белән бер – берсеннән аерылалар. Күн "махсус юл белән эшкәртелгән (иләнгән) хайван тиресе яки шундый тиренең бер кисәге" [ТТАС., 1979, т.2:299]. Ә тире исә, 1.кешенең һәм хайваннарның бөтен тәнен кап-лап торган тышча; 2. үтерелгән (суелган) хайваннан тунап алынган шундый тышлык [ТТАС., 1981, т.3: 103]. Димәк, тире – чимал, ә күн – эшкәртелеп ясалган әзер материал.

Чыгышы белән кызыклы булган тагын бер сүзгә тукталып китик. **Варишка** сүзе Ш. Габделгазиз сүзлегендә "тыш бияләй" [ГШ., 1893:120], "бармакча, бияләй" [Н., 1892: 177], "эч бияләй" [В., 1894: 17] дип бирелә. Болар барысы да төрки-татар синонимнары. Гап-гади генә нәрсәне белдергән гап-гади бияләй сүзе безнең бабаларыбызның тормыш рәвешләре турында матур бер информация бирә. Төрки телләрдә билгеле булган әлеге сүз (татар сөйләшләрендәге вариантлары бәйеләй, мәгәләй; уйгурча бәләй; чыгтайча бәһәләй, бәһләги ) төптә борынгы фарсыча бәһлә "лачынчыларның күн бияләе һәм иңсәсе" сүзеннән. Мәгълүм ки, лачынны һәм бүтән ерткыч кошларны ауга өйрәтәләр. Ау вакытында лачын, бөркет һ. с. башта иңдә һәм кулда тора. Ләкин бу кошларның тырнаклары бик үткен һәм каты. Алар тәнне җәрәхәтләмәсен өчен

кулга терсәккә җитеп торган тирән күн бияләй, ә иңнәргә күн иңсә кияләр. Менә шулар бәһлә, бәһләги дип аталган. Шуннан бияләй килеп чыккан [ Әхмәтҗанов:3 ].

Бу төргә караган синонимик оялар әллә ни күп булмасалар да, алар бар. Күз кешесе, суык тимерче, ит утыртмасы, чукмарлы инә, болгарый сүзләре хәзерге татар телендә очрамаса да, күз карасы, күз бәбәге, ашказаны, карын, тутырма, киштә, шүрлек, киез итек, күн, тире, бияләй сүзләре бүген дә актив кулланылуларын дәвам итәләр.

Синонимнар –з телне баетучы, аның үсеш дәрәҗәсен билгели торган күрсәткеч саналалар, шуңа күрә аларның күп булуы сөйләмнең тулы, фикернең төгәл булуын тәэмин итә. Күргәнебезчә, татар теленең синонимиясен баетуда төрле алынмалар катнаша. Мондый синонимик парларны өйрәнү түбәндәге нәтиҗәләргә китерде:

1. Бер генә халык та аерым, изоляцияләнеп яши алмаган. Әүвәл башка кабиләләр белән, соңга таба төрле халыклар, дәүләтләр белән аралашу нәтиҗәсендә татар теленә теге яки бу телдән алынмалар килеп кер-гән. Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән алынмалар XVII- XIX гасырларда бик күп булган. Бу күренеш без тикшергән сүзлекләрдә дә ачык күренә. Материаллар күрсәткәнчә, XIX гасыр сүзлекләрендә синонимнар, нигездә, гарәп-фарсы алынмалары исәбенә арта (остаз, мөдәррис, мөгаллим, хәлфә; шәкерт, талип; адәм, бәндә; җөрьят кылмак; җим, тәгам; ту-фан; дәрманлы, куәтле; галәмәт, әсәр һ. б. ). Бу, бигрәк тә, К. Насыйри, И. Гиганов сүзлекләрендә ачык чагыла.

2. Гарәп-фарсы алынмалары татар теленең синонимиясен баетуда беренче чыганак булса, рус алынмалары икенче чыганак булып санала. Төрки-татар халкының борынгы бабалары славян кабиләләре белән тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр. Шуның нәтиҗәсендә татар теленә бик күп рус сүзләре кергән. Алар телнең я фонетик законнарына яраклаштырылып (шут, патнус, пуднус, шпитал, стих, чтип һ. б.), я ничек бар шулай (линейка, армия) телдә яшиләр.

3. Синонимик рәт алынмалар ярдәмендә генә түгел, ә үз төрки-татар сүзләре исәбенә дә тулылана. Аларның кайберләре телдән төшеп калган (күз кешесе, болгарый, суык тимерче, төс төшерүче, якты йазучы), ә кайберләре (киштә, ашказаны, күз карасы, бияләй, күн, тире) бүген дә сөйләмдә еш очрый. Иң күп төрки вариантлар тормыш- көнкүреш һәм ашау-эчүне атаган исемнәрдә күзәтелә.

4. Сүзлекләрдән тупланган синонимик ояларда әдәби тел сүзләре белән беррәттән диалекталь сүзләр һәм гади сөйләм сүзләре дә бар. Моңа ачык мисал булып И. Гиганов, К.Насыйри сүзлекләре тора. Авторлар үз хезмәтендә җирле сөйләм теленнән алынган бик күп мисаллар бирәләр. Мәсәлән, үрә, бакрач, бирәчәк, үтеч, яфрак, уба, аман, кюзь, ту һ.б. шундый берәмлекләр булып саналалар.

## Сүзлекләрдә объективлык һәм субъективлык

XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрне тикшереп, өйрәнеп чыкканнан соң, бу хезмәтләрдәге объективлык һәм субъктивлык турында да фикер йөтергә була.

Объектив сәбәпләр һәр сүзлек өчен бердәй, алар шул чорның сәясәте, тормыш шартлары, икътисады белән бәйле.

XIX гасырда Россиянең эчке тормышында татарларның роле гаять зур була. Татарлар сан ягыннан икенче урында торалар һәм аеруча икътисад өлкәсендә танылалар. Россия сәнәгатендә татар тырышып хезмәт итәләр. Идел буе, Урал төбәгендә зур бай завод-фабрикаларның хуҗалары татарлар була һәм XIX гасырның 50 нче елларының ахырына төбәк сәнәгатенең 90%ка якыны татар эшмәкәрләре кулында булганлыгы билгеле. Бу оешмаларда хезмәт итүче эшчеләр арасында да татарлар төп көч булыа саналалар.

Россия территориясендәге сәүдәнең төп өлеше татар сәүдәгәрләрендә була. Зур сәүдә үзәкләрендә татар сәүдәгәрләре эшли, вак сәүдә белән дә татарлар шөгыльләнә.

Сәяси, икътисади шартлар татарларның рус теле белүен таләп итә. Укымышлы татарлар мәдрәсә белеме белән генә чикләнеп калмыйча, рус телен өйрәнә башлыйлар. Кайбер дөньяви мәдрәсәләрдә рус теле фән буларак та укытыла. 1876 елда Казанда татар укытучылар мәктәбе ачыла һәм татар халкының күп кенә күренекле вәкилләре бу мәктәптә белем алалар. Рус телен камил белү татар халкы өчен рус халкы белән элемтәләрне саклау һәм ныгыту өчен кирәк була. Рус телен белү татарларга Россиядә күләмендә үз ролен билгеләү, үз урынын табу өчен дә мөһим була.

Объективлыкның тагын бер ягы – татар зыялыларының Россиядә мәгърифәт таратуы. Бу чорда татар укытучылары Россиядәге төрки халыкларга аң-белем бирүдә зур эш башкаралар. Илнең төрле мәдрәсәләрдә, мәктәпләрдә татар мөгалимнәре халыкларны укырга һәм язырга өйрәтәләр, мәгърифәт нуры чәчәләр.

XIX гасырда татар галимнәре фән аренасына чыга. Ш.Мәрҗани, Г.Баруди, Ш.Әхмәров, К.Насыйри кебек галимнәрнең исеме татар, рус фәнни даирәсендә генә түгел, Көнчыгыш дәүләтләрендә, хәтта Европада да таныш була.

XIX гасырда татар матбугаты да зур роль уйный. Казанда, Россиянең төрле шәһәрләрендә бик күп төрле татар вакытлы матбугаты басыла. Масса күләм матбугат чаралары татар телен, мәгърифәтен, мәдәниятен һәм, гомумән, татар сүзен илнең төрле почмакларына җиткерүдә гаять кирәкле эш башкаралар.

Бу чорда яшәгән һәм татар дөньясына рухи һәм материаль ярдәм күрсәткән татар байларының эшчәнлеген дә объектив сәбәп итеп күрсәтеп мөмкин. Рәмиевләр, Акчуриннар, Хөсәеновлар, Юнысовлар, Аитовлар кебек бай гаиләләр шәхесләр мәктәпләр ачуга, китаплар бастыруга, матбугатка, галимнәргә, укымышлы кешеләргә ярдәм күрсәтүдә үзләренең байлыкларын кызганмыйлар.

Объектив сәбәпләр арасында тышкы сәбәпләр дә бар. Россиянең Көнчыгыш сәясәтендә татарларның роле һәрберебезгә билгеле. Бигрәк тә тәрҗемәчеләр сыйфатында татарлар зур эш башкаралар. Татарларның гарәп һәм фарсы телләрен белүе, төрки халыклар белән аралашуда татар телен куллanулары Россия хөкүмәте өчен бик файдалы була. Госман империясе, Иран һәм башка гарәп илләренә сәфәрдә рус патшалары тәрҗемәче итеп татарларны алганнар. Бу өлкәдә дан-шөһрәт казанган шәхесләребез дә була.

Югарыда санадган объектив сәбәпләр XIX гасырда татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр барлыкка киләдә төп шарт булып торалар. Илнең сәясәте, икътисады, мәдәнияте, халыкның тормыш-көнкүреше – һәрбер як үзенчә сүзлекләрдә чагылыш таба.

XIX гасырда дөнья күргән һәр татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрдә авторларның шәхеси үзенчәлеге дә чагылыш таба. Шуннан чыгып, без бу сүзлекләрдәге субъектив якларны күрсәтә алабыз.

Беренче субъектив як итеп, һәр авторның яшәү урыны, яшәү шартларын, әйләнә-тирә мохитен әйтергә була. Авторлар А.Троянский, К.Насыйри, А.Воскресенский Казанда яшәгән һәм эшләгән, И.Гиганов – Себердә, С.Кукляшев – Оренбургта, Н.Остроумов – Ташкентта,Төркстанда гомер иткән, Ш.Габделгазиз авылда ( хәзер Татарстанның Кайбыч районы Чукры Олан авылы) тормыш сөргән, М.Юнысов Чистай шәһәрендә торган. Авторларның яшәү урыннары сүзлеккә теркәлгән сүзләр составына һичшиксез тәэсир иткән.

Икенче субъектив як – авторларның белеме. Сүзлек авторларыннан С.Кукляшев классик университетта белем алганнар. Ул Казан Император университетының филология факультетын тәмамлаганнар.

Шул чорның зыялы татарларына хас булганча, К.Насыйри, Ш.Габделгазиз мәдрәсә белеме алганнар. К.Насыйри Казанның атаклы “Касыймия” мәдрәсәсендә укыган, Казан университетында ирекле тыңлаучы булган, Ш.Габделгазиз Казанда Апанай мәдрәсәсендә укый.

А.Троянский Н.Остроумов, А.Воскресенский – Казан рухани академиясен тәмамлыйлар, мөселманнарга каршы көрәш факультетында белем алалар.

И.Гиганов һәм М. Юнысов турында мәгълүматлар юк.

Өченче як итеп, сүзлек авторларының профессиясен күрсәтергә була. Авторлар арасында укытучылар күп. И.Гиганов Тобол халык училищесында, А.Троянский Казан рухани академиясендә, С.Кукляшев Оренбургтагы Неплюев кадет корпусында, М.Юнысов Чистай шәһәр мәдрәсәсендә, К.Насыйри Казан укытучылар мәктәбендә укытканнар. Алар, нигездә, русларга татар теле һәм татарларга рус теле өйрәтү белән шөгыльләнгәннәр.

Н.Остроумов, А.Воскресенский Миссионерлар җәмгыятенең актив әгъзалары булганнар һәм үзләренең эшчәнлекләрен шул юнәлештә алып барганнар. Мәсәлән, Н.Остроумов Казан рухани академиясендә укыткан, Төркестандагы халык училищеларында инспектор булган, Ташкентта ирләр гимназиясендә директор вазифаларын башкарган, газета мөхәррире булып эшләгән, ә А.Воскресенский Казан керәшен-татар мәктәбендә дин белеме укыткан, “кыргыз” мәктәпләрендә инспектор булган, укытучылар семинариясендә директор булып эшләгән.

Авторланың дини инанулары да субъектив як булып тора. Фамилияләрдән күренгәнчә, авторларның күбесе – христиан дине вәкилләре. Аларның сүзлек төзү эшчәнлеге миссионерлык юнәлешендә башкарылган. Алар төрки халыкларны телләрен өйрәнеп, христианлыкка өндәгәннәр, үз укучыларына да бу телләрне, безнең очракта, татар телен өйрәткәннәр.

Сүзләне теркәгәндә, авторларның филологик якын килүн дә искәртеп үтәргә кирәк. Сүзләрнең бирелеше, аңлатмасы, чыганагын күрсәтү, тамырдаш сүзләрне бергә туплау, башка төрки телләр белән чагыштыру, кулланылыш даирәсен күрсәтү – авторларның тирән филологик белеме, күп телләр белүе, мәсләге дә чагылыш таба.

Иң гади төзелешле сүзлек итеп Миссионерлар җәмгыяте чыгарган сүзлекләрне күрсәтергә була. Бу сүзлекләрдә сүзләгә турыдан туры тәрҗемә бирелә, бернинди өстәмә мәгълүмат күрсәтелми.

XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрдә алда без санаган объектив һәм субъектив яклар ачык күренә. Бу сүзлекләр әдәби тел материалына нигезләнеп төзелгәннәр. Сүзлекләрдә татар телендә актив кулланылышта булган, халыкка яхшы аңлашылган, китап теле лексикасыннан шактый арынган, нигездә, уртак фонетик нормаларга буйсынган, татар теленең җанлы сөйләм берәмлекләре теркәлгән. Шул ук вакытта, авторларга мөнәсәбәтле рәвештә, сүзләр составында диалекталь берәмлекләрне, авыр-авыр гарәп-фарсы алынмаларын, ислам һәм христиан диненә хас сүзләрне, гарәп-фарсы алынмаларыннан качу өчен теркәлгән рус-европа сүзләрен, теге яки бу төбәккә хас фонетик үзенчәлекләрне дә күрергә мөмкин.

## Йомгак

Татар лексикографиясе тарихында күпсанлы кульъязма сүзлекләр барлыгы мәгълүм. Бу сүзлекләр Мәскәү һәм Санкт Петербург архивларында сакланганнар һәм татар теле тарихына һәм лексикографиясенә зур өлеш кертәләр. 1801 елдан башлап басма сүзлекләр дөнья күрә башлый. Беренче сүзлекләр Санкт-Петербург типографиясендә басылалар һәм алар татарларга рус, ә русларга татар теле өйрәтү максатыннан чыгып барлыкка киләләр.

Иң беренче ике телле басма сүзлек итеп танылган тюрколог И.Гигановның "Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе учителем татарского языка, Софийского собора священником Иосифом Гигановым и юртовскими муллами свидетельствованная" (СПб.,1801) һәм "Словарь российско-татарский, собранный Тобольском главном народном училище учителем татарского языка И.Гигановым и муллами Юртовскими" (СПб.,1804) сүзлекләрен күрсәтергә мөмкин.

Ике телле сүзлекләр төзү традициясе алга табан да дәвам итә. А.Тоянский (1833; 1835), С.Кукляшев (1859), Н.Остроумов (1876, 1892), К.Насыйри (1878, 1892), Миссионерлар җәмгыяте сүзлеге (1880, 1882, 1886, 1888, 1891), Ш.Габделгазиз (1893), А.Воскресенский (1894), М.Юнусов (1900) сүзлекләре дөнья күрә.

Бу ике телле сүзлекләрнең авторлары төрле һөнәр ияләре, профессия вәкилләре булалар. Алар арасында галимнәр, укытучылар, миссионерлар бар һәм, мәгълүм булганча, бу авторларның күбесе Казан тюркологлар мәктәбенең актив әгъзалары булып саналар. Шул мәктәп традицияләрен дәвам итеп, алар халыкны агарту, мәгърифәтле итү өлкәсендә зур эш башкаралар. Төрле уку йортларында дәрес бирәләр, фәнни хезмәтләр

язалар, халык телен өйрәнәләр. Аларның педагогик эшчәнлекләренең бер нәтиҗәсе булып татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр дөнья күрә. Бу сүзлекләр татар теленең лексик байлыгы булган сүзләр хәзинәсен безнең көннәргә кадәр китереп җиткергән дәлилле чыганак булып торалар.

XIX гасырда татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрнең даими рәвештә басылып чыгуы һәм таралып бетүе бу чорда татар теленә булган зур ихтыяҗ турында сөйли. Бу хәлне Россиядәге вәзгыять, илнең көнчыгыш сәясәте, патша самодержавиясенең христианлаштыру хәрәкәте белән дә аңлатырга була. XIX гасырда бер генә башка милләтнең дә шул кадәр ике телле сүзлеге булмаган.

XIX гасыр татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләре хәзерге лексикография өчен җирлек булып торалар. Сүзлекләрнең ныклап уйланылган структурасы һәм композициясе авторларның сүзлек төзү методикасын яхшы белүләре турында сөйли.

Без тикшергән сүзлекләр – бер берсенә охшаш хезмәтләр. Сүзләрнең төп лексик өлеше кабатлана. Алар алфавит тәртибендә төзелгәннәр. Татарча-русча сүзлекләрдә сүзләр гарәп алфавиты тәртибендә урнаштырылган, ә русча-татарча сүзлекләр кирилл алфавитына нигезләнеп корылган. Миссионерлар төзегән сүзлекләрдә ( Н.Остроумов, Миссионерлар җәмгыяте) татар сүзләре дә кирилл хәрефдәре, ягъни миссионерлар төзегән алфавит белән бирелә. М.Юнысов сүзлеге дә шул алфавитта дөнья күргән.

И.Гиганов (1801), Ш.Габделгазиз (1893), Миссионерлар җәмгыяте сүзлекләре тематик принципка нигезләнеп төзелгәннәр. Бу сүзлекләр XIX гасырда дөнья күргән русларга татар теле өйрәтү максатыннан төзелгән үзөйрәткечләргә бик якын торала.

XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрдә телнең теоретик ягына бөтенләй игътибар ителми. Күп сүзлекләр алфавит бирү һәм кыскача искәрмәләр белән чикләнәләр. Хәтта сүзлекләрнең төзелеше, сүзләрнең бирелеше хакында кыскача информация дә бирелми. Бу сүзлекләрнең әчтәлеген беркадәр ярлыландыра.

Бары тик Н.Остроумов, К.Насыйри (1892), Миссионерлар җәмгыяте сүзлекләрендә генә татар теленең фонетикасы һәм морфологиясенә караган назари мәгълүмат урын алган.

Ике телле сүзлекләрдә лексик берәмлекләрнең теркәләүе белән бергә аларны тәрҗемә итү ысуллары да игътибарга лаек. XIX гасыр сүзлекләрендә төп урынны эквивалент тәрҗемә алып тора; шулай ук сүзнең ике, өч синонимын күрсәтеп тәрҗемә итү дә киң таралган. Бу алым өйрәнә торган телне яхшырак үзләштерергә мөмкинлек бирә. Сүзлекләрдә аңлатма бирү юлы белән тәрҗемә итү дә чагылыш таба. Тәрҗемәнең бу төре икенче тел вәкиле өчен авыр очракларны аңлатканда кулланыла һәм бу юл белән күбрәк этнографик лексика, чит сүзләр, милли традицияләрне аңлаткан берәмлекләр тәрҗемә ителә.

Сүзлекләрнең охшаш ягы күп булса да, һәр хезмәтнең үзенә генә хас үзенчәлеге бар.

Беренчедән, XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча сүзлекләр бер-берсеннән сүз күләме белән аерылып торалар. И. Гигановта (1801) барлыгы 1700 сүз, 1804 елда чыккан сүзлектә 11114 берәмлек, Н. Остроумова (1876), сүзлегендә 5040 сүз, ә 1892 елда дөнья күргән сүзлектә 1708 сүз, К.Насыйри (1878) 2970 якын берәмлек, 1892 елда чыккан сүзлектә 19500, А.Троянскийның ике томлы сүзлегендә 10 000 якын берәмлек, Ш.Габделгазиз хезмәтендә 1781 сүз, А. Воскресенский сүзлегендә 12950 сүз, Миссионерлар җәмгыяте төзегән сүзлекләрдә 1000 якын сүз, С.Кукляшев сүзлегендә 3546, М. Юнусов сүзлегендә 4448 сүз теркәргән.

